# ШУРА

№ 28

2020



## КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕ

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

## ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . 5

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . 11

Шәгъбан ае . . . . . . 12

Рамазан аен каршы алабыз . . . . . . 20

Рамазан – Аллаһы Тәгаләнең бүләге . . . . . . 27

Малдан зәкят чыгару . . . . . . 33

Рамазан – Коръән ае . . . . . . 42

Рамазан – уттан котылу ае . . . . . . 47

Рамазан аен озату . . . . . . 51

Ураза Гаете вәгазе . . . . . . 57

Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . . 63

Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . . . . 65

Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . . 67

Әбү Хәнифә мәзһәбе . . . . . . 69

Күркәм әхлак – яшәү рәвеше . . . . . . 74

Тәсаввуф . . . . . . 81

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать юлы . . . . . . 85

Хәләллек ризыкка гына кагылмый . . . . . . 91

Туганлык җепләре . . . . . . 99

ФӘТВАЛАР . . . . . . 105

Ислам динендә пластика операцияләре рөхсәт ителәме? . . . . . . 106

Мосафирмы, юкмы? . . . . . . 107

Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы? . . . . . . 108

Хатын-кызга кагылу тәһарәтне бозамы? . . . . . . 111

Келәм чистарту . . . . . . 112

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . 114

Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат . . . . . . 115

ФӘН . . . . . . 124

Суфичылык – рухи яктан камилләшү юлы . . . . . . 125

Малдан зәкят чыгару . . . . . . 129

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Ватан вә милләт тарихы хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Япониянең беренче мөселманнары: Нагоя шәһәре татар җәмәгатьчелегенең тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Япониянең беренче мөселман мәктәбе – «Исламия Мәктәбе»нең тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
И, ТУГАН ТЕЛ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Тел саклау хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Нух галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
УРАЗА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Уразага кагылышлы мәсьәләләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Үлем куркынычы һәм катылыгы бәяны . . . . . . . . . . . . . 183
Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Бәхетеңә киртә корма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Коронавирус таралуга бәйле рәвештә, Нәзарәт үз тәкъдимнәрен җиткерә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205

**«ШУРА» дини альманах, №28**

*апрель – июнь 2020*
*шәгъбан – зөлкагъдә1441*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Ильшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 14.04.2020
Чыгу көне: 28.04.2020

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا
اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ
بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞
شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا
إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ
الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ
عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى
بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ
أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا
وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

____________________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгене сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلَّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ

إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاتِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләẓии һәдәәнә лиһәәẓәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләẓии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйẓү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаẓәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләẓиинәт-тәкау, вәл-ләẓиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйẓу билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

____________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхааmәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибраһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибраһиимә вә галәә әәли Ибраһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

# Вәгазьләр

*10 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Шәгъбан ае

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифләрен бирсә иде.

Шәгъбан ае – мөбарәк айлардан санала. Һәр мөселман өчен изге булган Рамазан аеннан алда килә торган шәгъбан ае фазыйләтле һәм шәрәфле, Аллаһы Тәгаләнең бүләгенә лаек була торган ай. Бу ай күп кенә мөһим вакыйгаларга да бай. Ислам тарихында иң мөһимнәренең берсе – «Тәхвили кыйбла», ягъни кыйбланың үзгәртелүе нәкъ менә шушы шәгъбан аенда булганы турында да әйтеп үтәргә кирәк.

Шәгъбан аеның унбишенче көнендә, Мәдинәи Мөнәүвәрәнең «Бәни Сәләмә» мәчетендә Расүлуллаһ галәйһиссәлам өйлә намазы фарызының ике рәкәгатен укып торган вакытында вәхи иңгән: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазда торган хәлендә киремгә Кәгъбә тарафына борылган. Бу хәлтне күргән сәхабәләр дә аңа ияреп намазны дәвам иттергәннәр.

Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә:

قَدْ نَرَىٰ تَقَلُّبَ وَجْهِكَ فِي السَّمَاءِ ۖ فَلَنُوَلِّيَنَّكَ قِبْلَةً تَرْضَاهَا ۚ فَوَلِّ وَجْهَكَ
شَطْرَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ ۚ وَحَيْثُ مَا كُنتُمْ فَوَلُّوا وُجُوهَكُمْ شَطْرَهُ ۗ وَإِنَّ الَّذِينَ

أُوتُوا الْكِتَابَ لَيَعْلَمُونَ أَنَّهُ الْحَقُّ مِن رَّبِّهِمْ ۗ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا يَعْمَلُونَ ﴿١٤٤﴾

**«(И, Расүлем!) Без (кыйбланың Кәгъбәгә кайтарылуы хакында вәхи иңгәнен көтеп) синең йөзеңнең күккә юнәлгәнен күрәбез. Инде хәзер сине, һичшиксез, үзең риза булган кыйблага борабыз. (Моннан соң намаз укыганда) Син йөзеңне Харам мәчете тарафына юнәлт! (И, кешеләр!) Кайда гына булсагыз да, йөзләрегезне шул тарафка юнәлтегез. Һичшиксез, китап әһелләре (булган яһүдиләр һәм насаралар) моның Раббыларыннан (килгән) бер хак икәнен бик яхшы беләләр. Аллаһы аларның ни кылганнарыннан гафил түгел (Шул сәбәпле, Ул аларны үзләре лаек булган җәзага тартачак)».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:144

Расүлебез галәйһиссәлам: «Раҗәб ае – Аллаһы Тәгаләнеке, шәгъбан – минем ай, Рамазан ае – минем өммәтемнеке. Шәгъбан – гөнаһларга кәффарәт була торган ай, ә Рамазан ае – гөнаһлардан пакьләнә торган ай», – дип әйткән.

Бу айда шәфкать капкалары ачыла, һәрнәрсәнең дә бәрәкәте арта, безнең көндәлек тормышыбызда белеп яки белмичә ясала торган хаталар кими, гөнаһлар гафу ителә. Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә күп салаватлар әйтелә торган ай.

Шулай итеп, мөселманнарга тәүбәгә килеп, гөнаһлардан арынып һәм дә инде гафиллектән уянып, Рамазан аена хәзерләнү кирәк. Бу ай – Пәйгамбәрез галәйһиссәламнең ае булу сәбәпле, Аллаһы Тәгаләдән белеп һәм белмичә эшләгән гөнаһлар өчен гафу-истигъфар сорап, Аңа якынлашу хәерле гамәлләрдән санала.

Мөселман булган бәндә бу файдалы эшләрне кичектерергә яисә иң куркынычы, бөтенләй дә калдырырга тиеш түгел, чөнки адәм баласының тормышы өч көннән тора: беренчесе – узган, гыйбрәт алыначак көн; икенчесе – бүгенге көн, ганимәт көне. Өченчесе – иртәгә яки киләчәк. Адәм баласы ул көнне күрә аламы? Анысы Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм. Бу айга керә алабызмы, юкмы – моны безгә кем әйтә ала? Билгеле, беркем дә хәбәр бирә алмый. Раҗәб ае узып китте, киредән кайтмый, Рамазан ае киләчәктә, аны күрү-күрмәвебез билгесез, ә шәгъбан ае исә бу ике ай арасында бер күпер булып тора. Шуңа күрә дә бу айда гыйбадәттә булу, адәм баласы өчен иң мөһим эшләрдән булып тора.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَرَبُّكَ يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ وَيَخْتَارُ ۗ مَا كَانَ لَهُمُ الْخِيَرَةُ ۚ سُبْحَانَ اللَّهِ وَتَعَالَىٰ عَمَّا يُشْرِكُونَ ﴿٦٨﴾

**«Синең Раббың теләгәнен бар кыла һәм (теләгәнен) сайлый. Аларда исә сайлау (хакы) юк. Аллаһы (һәртөрле кимчелекләрдән) пакь! Ул алар Аңа ширек кушкан нәрсәләрдән өстен».**

«Касас / Хикәя», 28:68

Раббыбыз Үзенең коллары өчен бары тик иң изге, яхшы, файдалы һәм гүзәл нигъмәтләрне генә сайлап алып бирә.

Ул һәрнәрсәдән дә дүртне сайлап алып, соңыннан шулар арасыннан берсен якынайтып, дәрәҗәсен күтәрә. Мәсәлән: фәрештәләрдән – Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраилне сайлап алып, Җәбраил галәйһиссәламне иң олугы итеп куя. Мөхәммәд галәйһиссәләмгә пәйгамбәрлек вазифасын үтәү вакыты җиткәч, Үз сүзләрен җиткерер өчен Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештәне арадашчы итеп сайлый. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам аять-аять егерме өч ел дәверендә Раббыбыз сүзләрен җиткереп тора.

Пәйгамбәрләрдән – Ибраһим галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сайлап алып, безгә аларның дәрәҗәле икәнлекләрен күрсәтә. Алар арасыннан безнең сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламне иң сөеклесе булган ахырзаман пәйгамбәре итеп билгеләп куя.

Шулай ук, сәхабәләрдән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, Гомәр радыяллаһу ганһе, Госман радыяллаһу ганһе һәм Гали радыяллаһу ганһене аерып алып, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең дәрәҗәсен югары күтәрә.

Көннәрдән – Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Гарәфә көне һәм Гашурә көннәрен сайлап ала. Шулардан Гарәфәт көне мөселманнар өчен бөегрәк һәм хәерлерәк булып санала.

Кичәләрдән – Бәраәт, Гарәфә, Җомга һәм Бәйрәм кичәләрен аерып ала. Аллаһы Тәгалә каршында Кадер кичәсе башкаларга караганда югары урын алып тора.

Таулардан – Өхед, Сина, Зәйтүн һәм Любнан таулары арасыннан Сина тавы дәрәҗәлерәк.

Изге урыннардан – Мәккә, Мәдинә, Бәйт Әл-Мокаддәс һәм Мәшгәрул Харам (Гарәфә белән Мина таулары арасындагы урын) мөселманнар өчен бик кадерле. Ләкин шулардан инде Мәккәи Мөкәррәмә җирлеген Раббыбыз аеруча кадерле итеп күрсәтә.

Мәчетләрдән – Харам, Мәдинә, Әкъса һәм Сина тавы мәчетен аерып алып, Харам мәчетенең дәрәҗәсе бүтән мәчетләргә караганда югарырак булып санала.

Елгалардан – Сырдәрья, Амударья, Фөрат һәм Нилны сайлап алып, Фөратны дәрәҗәлерәк иткән.

Айларга килгәндә, алар да дүртәү: раҗәб, шәгъбан, Рамазан һәм мөхәррам. Аллаһы Тәгалә барысына караганда да шәгъбанны аерып алып, аны Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ае итеп билгели. Шулай

итеп Мөхәммәд галәйһиссәлам башка пәйгамбәрләргә караганда өстен булган кебек, шәгъбан ае да башка айларга караганда өстенрәк.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең хәдисендә болай дип әйтә: «Раҗәб аеның өстенлеге, Коръән Кәримнең башка китапларга карата булган өстенлеге кебек. Шәгъбанның башка айлардан өстенлеге: минем җир өстенә килеп киткән барлык пәйгамбәрләр белән чагыштыргандагы өстенлегем кебек. Ә Рамазан аеның өстенлеге: Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкатларына карата булган өстенлеге кебек».

Шәгъбан ае бәрәкәтле ай. Бу айда Аллаһы Тәгалә нигъмәт капкаларын ача һәм колларына чиксез рәхмәтен ирештерә. Шуңа күрә дә бу айда ваемсызлыктан аерылып, вакытны күбрәк догада һәм зикердә үткәрү хәерле булыр.

Раббыбызның рәхмәтенә һәм нигъмәтләренә ирешү өчен сәбәпче һәм дә бәрәкәткә бай булган айны гыйбадәттә уздыру хәерле эш булып тора. Бу айда башкарылган барлык яхшы эшләр 70 тапкыр арта һәм берниндн каршылыкларсыз күккә күтәрелә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шәгъбан аенда бик күп ураза тоткан. Бервакыт бер сәхабә Аллаһының Илчесе галәйһиссәламнән: «Әй Пәйгамбәр, мин синең шәгъбаннан да күбрәк ураза тотканыңны күргәнем юк (Рамазан ае уразасы – фарыз, ә шәгъбан аенда ураза фарыз түгел һәм ул һәркемнең үз ихтыярында, бу очракта Рамазаннан кала башка айлар да күздә тотыла). Моның сәбәбе нәрсәдә?» – дип сораган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Бу айда барлык гамәлләр дә Аллаһының хозурына ирешә. Мин гамәлләремнең үзем уразалы вакытта ашуын телим», – дип җавап биргән.

Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Шәгъбән аена шундый исемнең бирелү сәбәбе шундадыр, бу вакытта ураза тотучыларга Раббылары тарафыннан күп изгелек була, чөнки тоткан уразаның әҗере агач ботаклары кебек

тармаклана, ишәя. Бу инде җәннәткә керергә сәбәпче була», – дип безгә бу айның фазыйләтен аңлатып биргән.

Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мин Расүлуллаһның Рамазан аеннан башка бүтән айда ураза тотуын һәм башка айларда шәгъбан аеннан да уразаны күп тоткан вакытны күрмәдем», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Гайшә радыяллаһу ганһәгә: «Шәгъбан аенда тотылган ураза иң сөеклесе», шуннан соң дәвам итеп «И Гайшә! Бу шундый айдыр, ел дәверендә дөньядан Ахирәткә китүчеләрнең исемлеге Үлем фәрештәсенә биреләчәк. Мин дә исемемнең уразада вакытта тапшырылуын телим», – дип әйткән.

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә: «Расүлуллаһ Рамазаннан тыш, бер айда да шәгъбан аенда тоткан кадәр ураза тотмады», – дип әйткән.

Тагын хәдистә болай дип килә: «Рамазан аеның уразасыннан соң иң фазыйләтлесе, Рамазанга хөрмәт йөзеннән, шәгъбан аенда тоткан ураза. Иң фазыйләтле садака – Рамазан аенда бирелгәне».

Шәгъбан ае бик тә кыйммәтле һәм дәрәҗәле ай. Безнең сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ае булу сәбәпле, мөселман бәндәсенең теле һәм яшәгән һәр көне салаватлар белән зиннәтләнергә тиеш. Салаватлар әйтү, ул беренчедән – Аллаһы Раббыбызның әмерен үтәү булса, икенчедән – Пәйгамбәребез галәйһиссәлам каршында булган хакны үтәү була. Салават ул, Аллаһыдан – рәхмәт, фәрештәләрдән – истигъфар һәм мөэминнәрдән – дога, дигән сүз. Салаватның иң кыскасы: Әллаһүммә салли галә Мүхәммәдин вә галә әәли Мүхәммәд.

Йә Раббым, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дөньяда ихтирамга лаек, исеме бөек һәм мәшһүр. Гүзәл динебезне дәвамлы, Ахирәттә савапларны чиксез кылып, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмне шәфәгатьче итеп, җәннәт бакчаларында бергә-бергә җыелып, күрешүләребезне насыйп ит.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең хәдисендә: «Кыямәт көнендә, бер җирдә дә күләгә булмаган вакытта, өч төркем кеше Гареш күләгәсе

астында булырлар. Берләре – минем өммәтемә авыр вакытта ярдәм кулы сузучылар, икенчеләре – минем сөннәтемне үтәүчеләр, ә өченчеләре – миңа күп итеп салават әйтүчеләр», – дип әйткән. Шулай ук тагын бер хәдисендә: «Кем миңа җомга көнне йөз тапкыр салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең йөз ихтыяҗын, кайгы-хәсрәтен юкка чыгарыр. Утызын дөньяда, җитмешен Ахирәттә. Исән вакытымда миңа салават әйтүчеләрне белгән кебек, үлемемнән соң да мин аларны белермен», – дип әйткән.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедән китерелә: «Расүлуллаһка салават әйтү – су утны сүндергән кебек, гөнаһларны бетерә. Аңа сәлам бирү – колны азат итүдән дә саваплырак. Аны әти-әниеңнән, балаларыңнан да күбрәк ярату, Аллаһы Тәгалә юлында җиһад кылганнан да өстенрәк».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күп кенә хәдисләрендә салават турында мәгълүмат бирә. «Кем миңа салават әйтә, мин аңарга Кыямәт көнендә шәфәгатьче булырмын».

«Аллаһы Тәгалә әмере буенча бер фәрештә Кыямәт көне җиткәнчегә кадәр минем каберем янында торыр. Әгәр минем өммәтемнән берәү салават укыса, «Фәлән улы фәлән яки фәлән кызы фәлән сиңа салават укыды», – дип әйтер. Бер салаватка Аллаһы Тәгалә ун әҗер бирер, кем дә кем күп тапкырлар укыса, әҗере дә чиксез булыр».

«Аллаһы Тәгаләнең җир өстендә йөри торган фәрештәләре бар, алар миңа сәлам бирәләр».

Сәһел бине Сәид Әс-Сәгыйдидән риваять ителә: «Аллаһының расүле Мөхәммәд галәйһиссәлам өйдән чыкты һәм аны Әбү Талхә күреп алды. Әбү Талхә Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килеп: «Ий Аллаһының Расүле, синең йөзеңдә шатлык һәм канәгатьлек билгеләрен күрәм», – дип әйтте. Мөхәммәд галәйһиссәләм аңа: «Ничек инде мин шатланмыйм? Җәбраил минем янда булды һәм болай дип әйтте: «Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам! Өммәтеңнән берәү сиңа салават әйтсә, Аллаһы аңа ун изге гамәл язар, ун гөнаһын гафу итеп, ун тапкыр дәрәҗәсен күтәрер. Кыямәт

көне җиткәнчегә кадәр сиңа салават укыган бәндәгә, Аллаһы Тәгаләнең бер фәрештәсе: «Сиңа да Аллаһының рәхмәте ирешсен», – дип кайтарыр. Ий, Әбү Талхә, Аллаһы Тәгалә белән ант итеп әйтәмен, Кыямәт көнендә миңа иң якын кешеләр – күп салават укучылар», – дип җавап кайтарды».

Шушы мөбарәк шәгъбан аен бушка түгел, ә булдыра алганча гыйбадәттә үткәрсәк файдасы чиксез булыр. Шәгъбан ае изге Рамазан аена исән-имин керергә сәбәпче булса иде. Әзерлекне алдан ук башларга кирәк. Галимнәр болай дип әйткәннәр: «Сәхабәләр изге айга алты ай кала әзерләнә башлаганнар. Аллаһыдан: «Ий, Раббым, шәгъбан аен изгелектә уздырып, Рамазан айларын күрергә насыйп кылсаң иде. Гыйбадәт кылудан мәхрүм кылмасаң, тәүбәләребезне кабул итсәң иде, дип сораганнар». Сәхабәләр безгә үрнәк булып торалар.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*17 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рамазан аен каршы алабыз

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне акыл нигъмәте белән бүләкләп, барлык мәхлүкълардан өстен кылган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Рухи яктан пакьләнеп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Аллаһы Раббыбыз барчабызга Үзенең чиксез сәламен, рәхмәтен һәм бәрәкәтен насыйп итсә иде!

Ике гаеттән олуграк булган изге җомга бәйрәмебез, айларның солтаны булган – Рамазан ае барчабызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, Аллаһы ризалыгы өчен ниятләгән уразаларыбызны, кылган эшләребезне риясыз гамәлләрдән кабул итсен иде!

Әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин, берничә көннән Рамазан аен да каршы алачакбыз, Аллаһы боерса.

Изге китабыбыз Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَى وَالْفُرْقَانِ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ وَمَن كَانَ مَرِيضًا أَوْ عَلَى سَفَرٍ فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُوا الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Рамазан ае – кешеләргә туры юл һәм дөреслекне ялганнан аера торган дәлилләре булган Коръән иңгән ай. Сезнең кайсыгыз шул айда әзер булса, әлбәттә, ураза тотсын. Әгәр берәү авыру яки сәфәрдә булса, аңа башка көннәрдә шул ук санда ураза тотарга кирәк. Аллаһы җиңеллек тели, авырлык теләми. Боларны, санны төгәлләү өчен, туры юлга салу өчен, Аллаһыга шөкерана итүегез өчен эшләдек».**

«Әл-Бәкара», 2:183

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифендә:

«Һәрнәрсәнең зәкяте, ягъни пакьләүчесе була. Тәннең зәкяте – ураза», – дип әйткән. Рамазан аенда, таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр, балигъ һәм акылы булган һәрбер мөэмин кешегә ашамыйча, эчмичә һәм якынлык кылмыйча тору – фарыз.

Ураза тотуның фарызлары өчәү:

1. ният кылу;

2. ашау-эчүдән тыелу;

3. якынлык кылудан тыелу.

Мөселманнар Рамазан аен изге ай буларак хөрмәт итәләр. Нәкъ менә шушы айда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек иңдерелгән һәм шуның белән Ислам диненең яңарышы башланган. Мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсе Рамазанга туры килә.

Әлеге айда мөэминнәр ниятләгән уразаларын тоталар. Ураза кешеләрне гөнаһлардан арындыра, явыз уй-фикерләрдән, яман теләк-гамәлләрдән тыеп кала. Аллаһы Раббыбыз:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

**«Әй, иман китергәннәр! Ураза элеккегеләргә фарыз ителгән кебек, сезгә дә фарыз булды. Бәлки куркырсыз инде»,** – дип әмер иткән бит.

«Әл-Бәкара», 2:185

Ураза тоту, иң әһәмиятле гыйбадәт төрләренең берсе булып тора. Дөньялыкта ул безне яман эшләрдән саклый. Ә Кыямәт көнендә Аллаһының гөнаһларыбызны ярлыкавына сәбәпче була, җәһәннәм утыннан коткара, ин шә Аллаһ!

Ураза тотар алдыннан ниятебез дә дөрес булырга тиеш. Сәхәрдән соң, түбәндәге сүзләрне укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

«Нәүәйтү ән әсу́мә саумә шәһри рамәда́нә минәл-фәҗри иләл-мәгърибы ха́лисан лилләһи Тәгалә».

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ихласлык белән, таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр, Рамазан ае уразасын тотарга ният кылдым».

Уразада булучы көн дәвамында ашау-эчүдән, якынлык кылудан һәм дә золым гамәлләрдән тыелырга тиеш була.

Берәү карт бер абзый кешедән: «Бабай, җәй көнне Рамазан ае уразасын тота алмасам, нишләргә?» – дип сорый икән. Карт исә: «Әгәр җәй тота

алмасаң, кыш тотарга була. Анда көннәр кыска, артык эше дә юк», – дип җавап бирә. Әлбәттә, аның болай дип җавап бирүе кешегә фарыз гамәлне авырайтып күрсәтергә теләмәгәннән шулай дип әйтелгән.

Җәмәгать, хәзер барыбызның да акылыбыз, белемебез җитәрлек. Әмма ялгыш киңәшләр биреп, фарыз гамәлләрне кичектерергә безнең хакыбыз юк. Аллаһы Тәгаләбез безгә билгеле бер вакытта үтәлә торган гамәлләрне (мәсәлән, намазны үз вакытында уку, фарыз уразасын Рамазан аенда тоту) кушкан икән, дөрес итеп үтәргә тиешлебез. Калдырсаң, өстебездә бурыч булып кала түгелме соң?! Үкенергә калмасын, Аллаһы Үзе сакласын! Каза кылып булса да – үтик!

Кояш баткач, ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу (авыз ачу) – сөннәт гамәл. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу мөстәхәб булып тора.

Ифтардан соң түбәндәге дога укыла:

اَللّٰهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِى يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

«Аллаһуммә ләкә сумтү вә бикәә́мәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галә́ ризкыйкә-фтартү фәгъфирлии йәә гаффа́ру мә́ каддәмтү вә мәә әххартү».

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым һәм Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Һәм Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй, гөнаһларны гафу Итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләр сөннәт булып санала:

1) таң атканчы, төнлә торып сәхәр ашау;

2) ураза тотып, нәфесне гөнаһлы эшләрдән тыюны ният кылу;

3) кәсептән бушаган вакытларда дини китаплар уку;

4) кояш баегач, ахшам намазын укыганчы авыз ачу.

Ураза вакытында көндезен түбәндәге 10 төрле эшне кылу мәкруһ санала:

1) файдасыз сүзләр сөйләү;

2) әдәпсез сүзләр сөйләү;

3) мунчага кереп, озак утыру;

4) суга чумып коену;

5) ризык һәм сагыз чәйнәү;

6) берәр азыкка телне тидереп татып карау;

7) ирнең хатынын, хатынның ирен үбүе;

8) ифтар кылмыйча, ике көн рәттән ураза тоту;

9) нинди дә булса бер гөнаһлы гамәл кылу;

10) авыруының артачагын белә торып ураза тоту.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге 6 төрле эшне башкару дөрес санала:

1) Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаганда);

2) күзгә сөрмә тарту;

3) тәһарәт вакытында мисвәк белән тешләрне пакьләү, әмма чистарткан вакытта бүленеп чыккан төкерекне һәм мисвәкнең кисәкләрен йотарга ярамый;

4) кан алдыру;

5) сөлек салдыру;

6) госел коену.

Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1) борчак кадәр генә булса да, берәр ризык яки дару йоту;

2) бер тамчы кадәр генә булса да, су яки дару йоту;

3) якынлык кылу;

4) авыз тутырып косу.

Әгәр адәм баласы Рамазан аенда белә торып берничә тапкыр уразасын бозса, бөтен очраклар өчен бер кәффарәт (гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш) кылса, җитә. Яисә, үзе тота алмаса яки тотмаса, үзеннән фәкыйрьрәк кешене ай дәвамында ашатырга тиеш була.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә болай дип әйтелә: «Бервакыт без Пәйгамбәребез белән бергә утырганда, аның янына ниндидер бер кеше килеп болай дип әйтте:

– Әй Аллаһының Расүле! Мин һәлак булдым!

Пәйгамбәр галәйһиссәлам:

– Ни булды сиңа? – дип сорады.

– Мин ураза вакытында хатыным белән якынлык кылдым.

– Азатлыкка чыгарыр өчен колларың бармы синең?

– Юк.

– Ике ай буе рәттән ураза тота аласыңмы?

– Юк.

– Алтмыш фәкыйрьнең тамагын туйдыра аласыңмы?

– Юк, – дип җавап кайтарды».

Әбү Һөрайра хәдисне дәвам итеп болай дип әйтте: «Шуннан соң Расүлебез галәйһиссәлам бераз вакыт тын калды. Без шул хәлдә булган чакта, Пәйгамбәргә бер кәрзин хөрмә китерделәр. Ул: «Сорау биргән кеше кайда?» – дип сорады. Теге кеше:

– Мин монда, – дип җавап бирде.

Шуннан соң Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Боларны ал һәм садака итеп тарат, – дип әйтте.

– Әй Аллаһының Расүле! Мин боларны үземнән фәкыйрьрәк кешеләргә өләшергә тиешме? Аллаһы белән ант итәмен, Мәдинә шәһәрендә минем гаиләмнән дә фәкыйрьрәк гаилә юк, – дип әйткән.

Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тешләре күренерлек итеп елмайды да, соңыннан болай диде:

– Бар, бу хөрмәләр белән үз гаиләңне туендыр».

Йә Раббым! Һәрбарчабызга да ураза тотуларыбызда җиңеллек бирсәң иде. Илләребезгә иминлек, тәннәребезгә сихәтлек биреп, ярдәмеңнән ташламасаң иде. Әәмин!

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Низамов*

*Аксубай районы, Яңа Дума авылы имам-хатыйбы*

*24 апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рамазан – Аллаһы Тәгаләнең бүләге

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә, күңелләребез түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмде-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез. Һәрбарчабызга да шушы Рамазан аенда ураза тоту, тәравихларны уку, изгелекләр кылу, Раббыбызның шәфәгатенә ирешү насыйп булса иде.

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, безгә шушы Рамазан аен күрү насыйп булды. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Раббыбызга шөкер кылып, Аңа итагать итеп, уразага кердек. Тоткан уразаларыбыз кабул булсын. Рамазан аеның ахырына кадәр һәр көнне уразаны камил рәвештә тоту, Аллаһы Тәгаләнең шушы зур бүләге – Рамазан-шәрифнең нигъмәтләрен күңелебезгә сеңдерү насыйп булсын.

Әйе, шушы шәрәфле ай – Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән чиксез бүләге. Дөньяви бер мисалны күз алдыбызга китерик әле: кардәшебезгә бүләк сайлыйбыз ди. Коръән китабын бүләк итәргә булдык. Әйе, хәерле, матур бүләк булганга күрә Изге Китапны сайладык, әмма сәбәбе ул гына түгел. Шушы Коръән китабын бүләк итеп биргәндә без сүзсез генә нәсыйхәт ясыйбыз: «Кардәшем, туганым, синең, әлбәттә, бу дөньяда бөтен нәрсәң дә бар. Әмма уйланып кара әле: шушы уңышларга сине кем китерде?» – дип искәртәбез. Шул рәвешле, бүләк иясенә Раббысын искә төшерергә ярдәм итәргә тырышабыз. Рамазан ае белән дә шулай. Рамазан – ул искәртү бүләге. Ел әйләнәсе дөнья куып, Раббыбызны онытмадыкмы? Барысын да үзем булдырам, дип масаймадыкмы? Өстебездән хисап кылынганчы, үз-үзебезгә хисап ясадыкмы? Аллаһы Тәгаләнең биргән бүләкләренә шөкер кылдыкмы?

Асылда Раббыбызның безгә биргән нигъмәтләре бихисап. Әмма без аларны йә күрмибез, йә белмәмешкә салышабыз. «Әр-Рәхман» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә безгә күп тапкыр менә болай дип искәртә:

فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿١٣﴾

**«Ий кеше һәм җен! Раббыгызның кайсы нигъмәтен Аныкы түгел диярсез?»**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:13

Берәр төрле уңышка үзебез ирештекме? Иблис ләгъНәтуллаһның: «Мин», – дип масаюын кабатлыйбызмы? Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен инкяр итәбезме? Чынлыкта, хәтта сулыш алуны да Аның рәхмәте белән башкарабыз. Гомеребез бетте икән – байлыгыбыз да, дәрәҗәбез дә, көчебез

дә ярдәм итмәячәк, артык бер йотым һава да үпкәләребезгә кермәячәк. Шушы булдымы адәм баласының мин-минлегенә сәбәп?!

Сулаган һавабыз, эчкән суыбыз, ашаган ризыгыбыз – Раббыбызның рәхмәте. Без көн дәвамында боларга бер дә игътибар итмибез. Сулыйбыз да, ашыйбыз да, эчәбез дә – Аллаһы Тәгаләгә шулар өчен шөкер кылабызмы? Рамазан аеның Раббыбыздан бүләк буларак бер сыйфаты – шуны искәртү. Аллаһы Тәгалә Рамазанда ашау-эчүне, якынлык кылуны тыйды – буйсына алабызмы? Әллә нәфесебезгә иярәбезме? Рамазанда да нәфесне буйсындыра алмасак, башка вакытта булдырырбызмы?

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазанның беренче киче җитү белән Җәбраил галәйһиссәлам шәйтанны тотып, богаулы көе суга ташлый», – дип әйткән. Шуңа күрә Рамазан ае дәвамында безнең яныбызда вәсвәсә салып торучы шәйтан юк. Ул безне котыртмый, адаштырмый, начар юлга кереп китәргә өндәми. Начарлык кылабыз икән – үзебез генә гаепле. Шәйтаннарның богауда булуының бер ягы – гыйбадәт кылуның җиңеллегендә булса, икенчесе – алдан әйткәнчә, үз-үзебезгә бәя биреп карауда. Шәйтан юк икән – хаталарыбызга сылтап калдырып булмый.

Расүлебезнең тагын бер хәдисе бар: «Кем дә кем Рамазан аен иман һәм изгелек белән, гыйбадәттә уздырса, ул гаеткә гөнаһсыз булып килер», – дип әйткән. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләнең икенче бүләге – Аның Рамазан аенда безне гафу итүе, гөнаһларыбызны кичерүе, тәүбәләребезне кабул кылуы.

Әлбәттә, Рамазан аеның бүләкләре чиксез. Хәзерге заман табиблары Рамазанның сәламәтлек өчен (физиологик яктан) дә зур файда китерүе турында искәртеп тора. Ураза тоту ашказаны-эчәк авыруларыннан, артык авырлыктан, тагын бик күп башка чирләрдән арынырга ярдәм итә. Әйе, бу да нигъмәт. Сәламәтлегебез – әманәт. Әмма ураза тотуның нияте андый була алмый. Ураза тотуның максаты – Раббыбыз ризалыгын алу.

Уразаны ябыгу өчен тотмыйбыз. Вәгазь башында укылган аятьтә Аллаһы Тәгалә боерганга итагать итәбез. Бу мәсьәләдә игътибарлы булсак иде. Рамазан аеның безнең өчен зур бәрәкәт булуын онытмыйк, ялгышып яки ваемсызлыгыбыз сәбәпле Аллаһы Тәгаләнең бүләкләреннән баш тартмыйк.

Елдан-ел ураза тотучылар күбәя. Бу бик шатлыклы, сөенечле күренеш. Әмма әле үзен мөселман санаган кардәшләребез арасында да Рамазан аенда ураза тотмаучылар аз түгел. Кояш байый, Рамазан ае керә – әле бер көн ураза да тотмадык, ә Аллаһы Тәгаләнең күпме бәрәкәте, бүләкләре мөселманнарга инде ирешә дә башлый. Шушы мөмкинлектән файдаланмау бер дә дөрес гамәл булмас, чөнки Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә: «Кем дә кем Рамазан аен күреп тә, ураза тотмаса, ул кеше хәсрәттә, кайгыда булыр». Әгәр дә без Аллаһы Тәгаләнең Рамазанда ирештергән бүләкләрен кабул итеп, Аның ризалыгы өчен ураза тотмасак, гыйбадәт кылмасак, без хәсрәттә булырбыз.

Еш кына әти-әниләр мәчеткә килеп: «Хәзрәт, балабызның бәхете юк, гаиләләр таркала, бәрәкәт юк!» – дип зарланалар. Бәлки, бу зарларның тамырында Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешә белмәү, Ул биргән бүләкләрне кабул итә алмау ятадыр.

«Ник ураза тотмыйсыз?» – дип сораганда, «Хәзрәт, мин эшлим бит!» – дип җавап бирәләр. Сөбеханәллаһ, безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз да эшләгән. Эссе җәйләрдә, басуда кызу эш барган вакытта да уразаны калдырмаганнар. Ул вакытта хәзерге кебек уңайлы эш урыннары да, кондиционерлар да булмаган. Ләкин берсе дә «Уф!» – дип тә әйтмәгән. Алар өчен Аллаһы Тәгаләнең әмере, бүләге өстенрәк булган. Ә без, төрле сәбәпләр табып, бу нигъмәтләрдән баш тартабыз. Аннан соң, нишләп авырыйбыз, нишләп бәхетсез, нишләп бәрәкәт юк дип баш

ватабыз. Җәмәгать, без башта Аллаһы Тәгалә биргәнне алырга өйрәник. Белә торып баш тартмыйк!

Янә бер хәдисне искә алыйк: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кешенең тәнендә бер әгъза бар. Әгәр ул чиста булса, кешенең бөтен гамәлләре чиста булыр, әгәр дә ул чиста булмаса, кешенең гамәлләре пычрак булыр», – дип әйткән. Шуңа күрә без Рамазан аенда тагын бер әйберне истән чыгармыйк – ул күңел чисталыгы, ихласлык. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә без Рамазан аенда ачуланабыз, кемнедер рәнҗетәбез, гайбәт сөйлибез, ягъни холык ягыннан ураза тотмыйбыз икән, шушы ач тору Аллаһы Тәгаләгә кирәкми!» – дип әйткән. Шуңа күрә уразабыз ач тору гына булып калмасын өчен уйлансак иде. Уйларыбызны, гамәлләребезне, телебезне, күзебезне дә контрольгә алып, күңелебез белән дә уразада булсак иде. Монысы Рамазанның күзгә күренми торган, әмма бик тә мөһим бер өлеше. Тамак уразасына караганда, калеб уразасы күпкә кыенрак бирелә, күбрәк көч таләп итә торган әйбер.

Еш кына кардәшләребез «Уразаның беренче көннәрен тиешле дәрәҗәдә уздыра алдыммы икән, гамәлләрем дөресме икән?» – дип шикшөбһәгә биреләләр. Бу уңайдан бер хәдисне онытмыйк: «Аллаһы Тәгалә кечкенә генә савапны да күрә, бер генә уңай гамәл дә игътибарсыз калмый». Шуңа күрә без беренче чиратта үз-үзебез белән ихлас булыйк, үз-үзебез алдында хисап тотыйк. Аллаһы Тәгалә безгә һәрвакыт дөрес җавапларны, тиешле гыйлемнәрне ирештереп тора. Сорагыз! «Рамазанны күркәм итеп үткәрсәм иде, уразаларым кабул булса иде», – дип догалар кылыгыз.

Әгәр дә әле ураза тотмыйсыз икән, соң түгел – башлагыз. Аллаһы Тәгалә һәрвакыт ярдәм итә, җаен бирә. Тота алырмынмы дип куркып тормагыз, Аллаһы Тәгаләдән өмет өзмәгез. Ул кабул Итүче, ярдәм Итүче. Шуңа күрә мәчетләргә килегез, хәзрәтләр белән киңәшләшегез, аларга

сорауларыгызны бирегез. Аллаһы Тәгалә сезгә тиешле гыйлемнәрне җибәрер, бер соравыгыз да җавапсыз калмас.

Безнең халык төрле дәверләрне күргән. Әбиләребез-әниләребез: «Рамазан вакытында эштә, мәктәптә су белән каршы алалар, авызыбызны ачтыра, уразабызны боза торган иделәр», – дип сөйлиләр иде. Болай эшләүчеләр, кеше ураза тотмасын, дип тырышканнар. Мондый вакытлар да булган. Ул дәверләр инде кире кайта күрмәсен.

Рамазанда өч көн генә булса да ураза тотарга кирәк, башында бер көн, уртасында бер көн, ахырында бер көн, дигән гыйбарәләр шул вакыттан калган ул. Бүген безнең ураза тоту өчен бөтен мөмкинлекләребез дә бар. Өстәлләребез тулып тора, эш урыннарыбыз уңайлы, ураза тотарга ярамый дигән законнар юк. Шуңа күрә без уразаны башында ун көн, уртасында ун, ахырында ун көн тотыйк. Уразаны үз ихтыярыгыз белән калдырмагыз. Аллаһы Тәгаләнең бүләген рәхмәт белән кабул итегез.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догамбарлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*1 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Малдан зәкят чыгару

Раббыбыз Аллаһы кешеләргә малны төрлечә бүлгән: кемгәдер байлык биргән, кемнедер фәкыйрьлек белән сынаган. Аллаһы Тәгалә хикмәт иясе һәм Ул кемне нинди сынау белән имтихан кыласын яхшырак белә. Маллары әз булган фәкыйрьләрне, сабыр итәрләрме икән, дип сынаса, байлыклары мул булган кешеләрне, шөкер итеп, малларыннан бер өлешне мохтаҗларга бүлеп бирерләрме, саранлык чиреннән арына алырлармы икән, дип сынап карый. Күбебез, малы булмаган фәкыйрьләр генә сынала, алар гына сабыр итәргә мәҗбүр, дип уйлый. Әмма байлык белән кеше ныграк сынала икән, чөнки мал күплеге аларга төрле гөнаһлар кылу юлларын ача, кешенең мөмкинлекләре тагын да арта. Бу байлар саранлык чире белән авырый башласалар, җәмгыятькә аларның зыяны үтә дә зур була. Әйе, мал һәм акча эшләү өчен ул нинди генә юллар эзләми, җәбер-золым кылып, кешенең малын тартып алу да аның өчен гадәти хәлгә әверелә. Шуңа күрә Раббыбыз Аллаһы динебезнең бер нигезе итеп юмартлыкны билгеләгән. Әгәр динебезнең биш нигезе хакында фикер йөртсәк, аның өченче әркәне – зәкят, ягъни бездә юмартлык сыйфатын тәрбияли торган нигез. Без байлыгыбызның бер өлешен мохтаҗларга бүлеп биреп, күп афәтләрдән котылабыз, ә бигрәк тә ул саранлык чиреннән саклый һәм юмартлык сыйфатына ия булырга ярдәм итә торган сәбәпләрнең берсе булып тора.

Ә нәрсә соң ул зәкят? «Зәкят» сүзе «пакьлек», «арту», «бәрәкәт» мәгънәләрен белдерә. Ул малны пакьләндергәне һәм бәрәкәтле кылганы өчен шул гыйбарә белән аталган. Ислам шәригатендә балигълык яшенә җиткән, үз акылында һәм ирекле, шулай ук билгеле бер мөлкәткә ия

булган мөселманнар, әлеге мөлкәтнең нисабы һәм елы тулган очракта, малларыннан кырыктан бер өлешне, билгеле бер кешеләргә зәкят итеп түләргә тиешләр. Әйе, чыннан да, зәкят малыбызны чистарта торган һәм малыбызга бәрәкәт бирә торган гыйбадәтләрнең берсе. Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا تُنفِقُوا مِن شَيْءٍ فِي سَبِيلِ اللَّهِ يُوَفَّ إِلَيْكُمْ وَأَنتُمْ لَا تُظْلَمُونَ ﴿٦٠﴾

**«Аллаһы юлында нәрсә генә сарыф итсәгез дә, сезгә тулысынча кайтарылыр һәм сез (гамәлегез юк ителеп яки савабыгыз киметелеп) золым күрмәячәксез».**

«Әнфәл / Табыш», 8:60

Зәкят – ислам диненең мөһим нигезе булып санала, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ислам биш рөкенгә нигезләнгән: «Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк һәм Мөхәммәд Аның илчесе», – дип шәһадәт кәлимәсен әйтү, намаз уку, зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту, мөмкинчелеге булган кешегә Аллаһы йортына хаҗ кылу»[1].

Хәдистән күренгәнчә, зәкят фарыз булган садака һәм ул безне юмартлыкка өйрәтә. Ә кеше нәфесе шундый: ул алырга бик яратса да, биргәндә «дер» калтырый. Коръән аятьләренә күз салыйк, алар арасында зәкятнең әһәмиятен ассызыклаганнары шактый:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ وَارْكَعُوا مَعَ الرَّاكِعِينَ ﴿٤٣﴾

**«Намазларыгызны торгызыгыз һәм зәкятегезне бирегез, рәкәгать кылучылар белән рәкәгать кылыгыз»,**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:43

1 Әл-Бохари риваяте.

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ ﴿٨٣﴾

**«Намазларыгызны торгызыгыз һәм зәкят садакаларын биреgез»,**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:83

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٥٦﴾

**«Намазларыгызны торгызыгыз һәм зәкятегезне бирегез һәм Расүлгә буйсыныгыз, мөгаен, рәхмәт кылынганнардан булырсыз».**

«Нур», 24:56

Зәкятнең шул рәвешле олуг фазыйләтле гыйбадәтләрнең берсе булган намаз белән бергә килүе Коръәндә 27 тапкыр кабатлана. Бу инде зәкятнең әһәмиятен көчәйтә торган тагын бер күрсәткеч булып тора. Әлбәттә, зәкятнең үзе хакында гына әйтелгән аятьләр дә бар. Тик алар Аллаһыга һәм Кыямәт көненә иман китереп, үзен мөселман санаган кешенең малы нисабка җитеп, бер ел вакыт үтсә, бу мөһим гыйбадәтне үтәргә тиешлеге хакында.

Шулай ук зәкят җәннәткә керүебезгә дә мөһим бер сәбәп булып тора һәм, зәкятен чыгарган кешенең, Кыямәт көнендә куркуы да, көенүе дә булмас. Моңа дәлил итеп бер аять һәм сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерик:

إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَأَقَامُوا الصَّلَاةَ وَآتَوُا الزَّكَاةَ لَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿٢٧٧﴾

**«Иман китереп, изге гамәлләр кылучы, намазларын укып, зәкятләрен бирүче мөэминнәрнең әҗере Раббылары хозурында. Аларга Ахирәттә курку һәм көенү дә булмас»,**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:277

«Бер кеше пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнән: «Миңа җәннәткә керергә нинди эшләр ярдәм итүен әйтче», – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Аллаһыга тиңдәшлек кылмыйча, Аның бер Үзенә генә гыйбадәт кыл, намаз укы, зәкятеңне түлә, туганлык җепләрен сакла», – дип җавап биргән»[1].

Зәкятне түләмәүдән куркырга кирәк, чөнки бу зур гөнаһлардан санала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә бу хакта хәбәр биргән һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә безне болай дип кисәткән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّ كَثِيرًا مِّنَ الْأَحْبَارِ وَالرُّهْبَانِ لَيَأْكُلُونَ أَمْوَالَ النَّاسِ بِالْبَاطِلِ وَيَصُدُّونَ عَن سَبِيلِ اللَّهِ ۗ وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللَّهِ فَبَشِّرْهُم بِعَذَابٍ أَلِيمٍ ﴿٣٤﴾ يَوْمَ يُحْمَىٰ عَلَيْهَا فِي نَارِ جَهَنَّمَ فَتُكْوَىٰ بِهَا جِبَاهُهُمْ وَجُنُوبُهُمْ وَظُهُورُهُمْ ۖ هَٰذَا مَا كَنَزْتُمْ لِأَنفُسِكُمْ فَذُوقُوا مَا كُنتُمْ تَكْنِزُونَ ﴿٣٥﴾

**«Шундый кешеләр бар, алар алтын һәм көмешне җыярлар, Аллаһы юлына (зәкятләрен) һич бирмәсләр. Аларга рәнҗетүче газап киләчәге турында хәбәр бир. Җыйган ул алтын-көмешләре ахырзаманда тәмуг утында кыздырылып, маңгайларына, кабыргаларына, аркаларына басылыр һәм: «Болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын һәм көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малларыгызның газабын татыгыз, дип әйтелер».**

«Тәүбә», 9:34-35

[1] Әл-Бохари риваяте.

Галимнәр шушы аятькә нигезләнеп, алтын-көмешләрен җыеп, алардан зәкяткә тиешле өлешләрен бирмәгән кешеләрне каты газап көтәчәге хакында әйттеләр.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйтте:

«Аллаһы бүләк иткән малдан зәкят бирмәгән кешенең җыйган байлыгы, Кыямәт көнендә, аның алдына башында ак таплары, ә күз астында кара таплары булган елан рәвешендә киләчәк. Бу көнне ул елан шундый кешенең муенына чорналып, теш казнасыннан тотып: «Мин – синең байлыгың, мин – синең зиннәтләрең», – дип әйтәчәк», – дигән һәм әлеге аятьне укыган:[1]

وَمَن يَبْخَلْ فَإِنَّمَا يَبْخَلُ عَن نَّفْسِهِۦ ۚ ﴿٣٨﴾

**«Кем дә кем саранланса (һәм Аллаһы Тәгалә әмер иткән юлда сарыф итәсен киметсә), ул үзенә карата гына саранлык күрсәтә».**

«Кыйтал / Мухәммәд», 47:38

Шушы бөек гыйбадәтне үтәү кемнәргә тиешле? Без алда телгә алган идек: билгеле бер мөлкәткә ия булган мөселманнар, әлеге мөлкәтнең нисабы һәм елы тулган очракта, малларының кырыктан бер өлешен, билгеле бер кешеләргә, зәкят итеп түләргә тиешләр. Зәкят түләү өчен ике шарт үтәлү мөһим: байлыкның нисабка җитүе һәм бер ел дәвамында саклануы. Нисаб алтын һәм көмеш белән исәпләнә. Көмеш белән исәпләгәндә, ул 200 көмеш дирһәм, ягъни авырлык берәмлегенә күчерсәк, 595 грамм тирәсе була. Алтын белән исәпләгәндә исә 20 мискал, ягъни 85 грамм була. Елның үтүе һиҗри ай календаре буенча санала. Әгәр синең көмеш яки алтын бизәнү әйберләрең яки чиста акча саклар өчен алынган алтын-көмешләрең булса, көмеш 595 граммнан, ә алтын 85 граммнан артса, аларның кырыктан бер өлешен, ягъни 100 дән 2,5 өлеш итеп, акчалата түләргә тиешсең. Акча да алтын-көмеш нисабыннан санала. Бүгенге көндә

[1] Әл-Бохари риваяте.

бер грамм алтын якынча 3500 сум тора. 3500*85=297 500 сум була. Әгәр, мәсәлән, Рамазан аенда, кешенең шушы суммада акчасы булып, икенче Рамазан ае җиткәнче әлеге күләмдәге акчасы кимемичә сакланды икән, ул әлеге сумманың 2,5 процентын зәкят итеп чыгарырга бурычлы була. Бу якынча 7500 сум дигән сүз.

Кайбер кешеләр зәкятне мөбарәк Рамазан аенда гына бирергә кирәк дип уйлыйлар. Һичшиксез, Рамазан аенда изгелекләр кылу, садакалар бирү бик саваплы гамәл. Әмма зәкят түләү өчен Рамазан ае җитү шарт булып тормый. Байлыгың нисабка раҗәб аенда тулды икән – раҗәб аенда, шәүвәл аенда тулды икән – аның зәкятен шәүвәл аенда чыгарырга кирәк.

Шулай ук, галимнәр әйтүе буенча, әгәр суммалары нисабка тулса, зәкят акцияләрдән, кыйммәтле кәгазьләрдән, сатарга алынган товарлардан да түләнә.

Ә кемнәргә зәкят түләнә соң, әлеге акчаларны кемнәргә түләргә тиешбез? Моның хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә бәян итә:

إِنَّمَا الصَّدَقَاتُ لِلْفُقَرَاءِ وَالْمَسَاكِينِ وَالْعَامِلِينَ عَلَيْهَا وَالْمُؤَلَّفَةِ قُلُوبُهُمْ وَفِي الرِّقَابِ وَالْغَارِمِينَ وَفِي سَبِيلِ اللَّهِ وَابْنِ السَّبِيلِ ۖ فَرِيضَةً مِّنَ اللَّهِ ۗ وَاللَّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ ﴿٦٠﴾

> **«Садакалар – фәкыйрьләргә, мескеннәргә, зәкят җыючыларга, күңелләре (ислам диненә) тартылганнарга, колларга, бурычлыларга, Аллаһы юлында булучыларга һәм малсыз калган мосафирларгадыр. Күрсәтелгән шул урыннарга бирмәк Аллаһы тарафыннан фарыз ителде. Аллаһы Белүче һәм хөкем Итүче».**

«Тәүбә», 9:60

Аллаһы Тәгалә бу аятьтә сигез төрле кешегә зәкят бирелергә тиешлеген хәбәр итә:

- фәкыйрьләргә;
- мескеннәргә;
- зәкят җыючыларга;
- күңелләре (ислам диненә) тартылганнарга;
- колларга;
- бурычлыларга;
- Аллаһы юлында булучыларга;
- мосафирларга (юлда калганнарга).

Фәкыйрь – бернинди малы һәм кәсеп итү мөмкинлеге булмаган мөселман кешесе, мескен – берникадәр малы һәм кәсеп итү юлы булса да, яшәү өчен бу гына җитәрлек булмаган мөселман кешесе. Зәкят җыючылар – имам тарафыннан мөселманнардан зәкят җыю өчен билгеләп куелган кешеләр һәм әлеге эшләре өчен имам аларга эш хакын шушы зәкят акчасыннан түли. Күңелләре ислам диненә тартылганнар – әлегә ислам диненә кермәгән, әмма динебез белән бик нык кызыксынган, исламга бик якын булган кешеләр. Колларга исә зәкят, хуҗаларына түләп, үзләрен коллыктан  азат итсеннәр өчен бирелә. Бурычлылар – ул бурычлы булып, әҗәтен түләргә мөмкинчелеге булмаган мөселман кешеләре. Аллаһы юлында булучылар исә – Аллаһы юлына чыгып, матди ярдәмгә мохтаҗ булучы кешеләр, мәсәлән, хаҗ һәм гыйлем юлына баскан мохтаҗлар. Мосафирлар исә – туган якларында бай булсалар да, ниндидер сәбәпләр аркасында, юлда, мохтаҗлыкта калган мөселман кешеләре, аларга, зәкят, әйтик, поездга, самолётка, автобуска билет, юлга ризык алыр өчен бирелә. Безгә менә шушы төр кешеләргә, Аллаһы ризалыгы өчен, садакаларыбызны кызганмыйча, зәкятләребезне бирү фарыз. Ләкин бу барлык сигез төр кешегә дә тигез итеп бүлеп бирергә кирәк, дигән сүз түгел, әлеге төр кешеләрнең берсенә генә бирсәң дә, дөрес була.

Кайберәүләр, болай да түләүләрем күп инде, монда тагын зәкят тә бирсәм, күпме акчам кими, дип уйларга мөмкин. Мондый фикердән арынып, нәфесне бу чирдән дәвалар өчен Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер хәдисен китерү бик урынлы булыр Ул:

«Мал садака аркасында кимемәс»[1], – дип әйткән.

Бу хәдис фарыз садакага да (зәкят) һәм нәфел садакасына да кагыла. Аллаһы юлында тотылган мал һичкайчан юкка чыкмый, киресенчә, икеләтә кайта һәм мал да бәрәкәтле генә була. Һәм, гомумән, мөселман кешесенә саран булу ярамый, ул юмартлык күрсәтеп, Аллаһы ризалыгы өчен, ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ярдәм итәргә омтылып яшәргә тиеш. Коръәни Кәримдә:

وَلَا يَحْسَبَنَّ الَّذِينَ يَبْخَلُونَ بِمَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ هُوَ خَيْرًا لَّهُم ۖ بَلْ هُوَ شَرٌّ لَّهُمْ ۖ سَيُطَوَّقُونَ مَا بَخِلُوا بِهِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۗ وَلِلَّهِ مِيرَاثُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ ۗ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ ﴿١٨٠﴾

**«Аллаһы биргән нигъмәтләрдә саран булучылар – моны үзләре өчен хәерле, дип уйламасыннар. Юк, ул аларга явызлыктыр. Саранланган нәрсәләре ахырзаманда аларга муенса итеп кидерелер. Күкләрдә һәм җирдә булган нәрсәләр – Аллаһының мирасы. Аллаһы – сез эшләгән нәрсәләрдән хәбәрдар»,** – дип әйтелгән.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:180

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догамбарлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

[1] Әл-Мөслим риваяте.

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Раил хәзрәт Фәйзрахманов,*

*Балык Бистәсе районының*

*Тәберде Чаллы авылы мәчете мөгаллиме*

*8 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рамазан – Коръән ае

Барча галәмнәрне Яратучы, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булсын! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, ныклы сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясына күп төрле бүләкләр биргән. Шулар арасында, әлбәттә, – Рамазан ае. Аллаһының расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер вәгазендә мондый сүзләр әйтә: «Әй кешеләр, сезгә изге ай килде. Бу айда мең төннән дә хәерлерәк булган Кадер киче бар. Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны фарыз, ә төннәрен намаз белән үткәрүне сөннәт итеп кылды. Кем дә кем Аллаһыга бер нәфел гамәл эшләп якынайса, калган айларда фарыз гамәлне кылган кебек булыр, ә фарыз гамәл кылган кеше – 700 фарыз гамәл кылган кебек булыр…» Аллаһы Тәгалә каршында айларның саны унике. Әмма Рамазан алар ара-

сында аерым бер урынны били. Айлар күп, һәм һәрберсе дә аларда булган ниндидер вакыйгага белән истә калган. Берсендә – Рәгаиб, Мигъраҗ кичәсе, икенчесендә – Гарәфәт көне һ.б. Шундый көннәр аркасында да кайбер айларны югары бәялибез. Әмма Рамазан ае – үзе дә мөбарәк ай, анда булган кичәләр дә мөбарәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ ﴿١٨٥﴾

**«Рамазан ае бик шәрифле ай, ул айда Аллаһыдан кешеләргә туры юлны күрсәтә торган һәм һидаятьне ачык бәян кыла торган Коръән иңдерелде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Аллаһының Илчесе, сәхабәләр һәм алардан соң килгән мөселманнар да Рамазан аеның кичләрен Коръән укып үткәрергә тырыша иделәр. Имам Әл-Бохари һәм Имам Әл-Мөслим хәдис җыентыкларындагы Ибне Габбастан килгән хәдистә, Җәбраил галәйһиссәламнең Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Рамазанның һәр төнендә очрашып, аның белән Коръән өйрәнгәнлеге турында әйтелгән. Уйлап кына карагыз: әгәр сез көндезләрен уразада булып, кичләрен Коръән укып үткәрәсез икән, Кыямәт көнендә сезнең гафу ителүегезне, ут газабыннан саклауны сорап торачак ике яклаучыгыз булыр – Ураза һәм Коръән.

Олуг галимнәребез дә бу ай җитүгә үзләренең эшләрен читкә куеп, кулларына Коръән ала торган булганнар. Имам Мәлик, Суфьян Әс-Сәүри кебек галимнәребез фән эшләрен дә читкә куйганнар. Имам Әл-Бохари авыз ачар вакыт җиткәнче Коръән укый торган булган. Шулай ук ул: «Коръәнне тулысы белән укыганнан соң кылынган дога җавапсыз калмый», – дип әйткән. Шуңа күрә «Кыям әл-ләйл»дә галимнәребезнең бер

төркеме Коръәнне тулысы белән һәр 3 көн эчендә, кайберләре – 7, бер төркеме – һәр 10 көн эчендә укып чыкканнар.

Ничек бер ай эчендә Коръәнне укып чыгып була? Тәравих намазларында хәтем чыгучы имамнар бар. Алар, гадәттә, бер көнгә бер җөз укыйлар. Бу иң кулай ысул булып тора. Азрак укысак, Рамазан ахырына кадәр өлгермәскә мөмкинбез, күбрәк булса, тиз арып, гомумән, туктап калу куркынычы бар. Шуңа да, урталыкны сайлыйк. Коръән Рамазан аенда гына түгел, башка айларда да укылырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзегезнең йортларыгызны каберлекләргә әйләндермәгез (җансыз, кипкән әйбергә әйләндермәгез). Дөреслектә, шәйтан «Әл-Бакара» сүрәсе укыла торган йорттан кача», – дип әйткән. Бу хәдис исә Коръәнне Рамазаннан соң да бик күп тапкыр укырга кирәклеген исебезгә төшерә, чөнки шәйтаннар Рамазан аеннан кала башка айларда богауга куелмыйлар.

Нәрсә соң ул Коръән? Ни өчен аны еш укырга кирәк? Мәгънәләрен аңламасак та, укырга ярыймы? Бер кыйссаны исегезгә төшереп үтәм. Тауларда үзенең оныгы белән бер карт кына бабай яшәгән, ди. Ул мөселман булган, шуңа да һәр иртәсен Коръән укуга багышлаган. Оныгы аңа охшарга тырышкан, бабасы ни эшләсә, шуны кабатлап барган. Бервакыт бу бала: «Бабай, мин Коръән китабын синең кебек укып барырга тырышам, әмма мин аның мәгънәсен аңламыйм. Мин китапны ябу белән, ятлаган әйберләрем башымнан чыга. Шулай булгач, Коръәни Кәрим китабын укудан нинди файда бар соң?» – дип сорый. Мичкә ташкүмер сала башлаган бабасы, туктап: «Бар, улым, ташкүмер кәрзинен ал да, елгага төшеп, су алып мен», – дип әйтә. Оныгы шулай эшли дә, кәрзинне алып, су алырга төшеп китә. Әмма ул тау башына менеп җиткәнче, су кәрзиннән агып бетә. Моны күреп, бабасы елмаеп куя һәм: «Син тизрәк атлап кара», – дип әйтеп, оныгын кабаттан су алырга төшереп җибәрә. Монысында инде малай тизрәк атларга тырыша. Әмма тау башына йөгереп менеп җиткәнче,

кәрзин буш була. Бабасына суны кәрзиндә алып менеп булмаганлыгын хәбәр итеп, малай чиләк артыннан китә. Бабасы моны күреп: «Әмма миңа бер кәрзин су кирәк, миңа бер чиләк су кирәкми. Син бар көчеңне куеп эшләргә теләмисең генә», – дип каршы төшә. Оныгы бу хәлнең мөмкин түгеллеген исбатлар өчен, кабаттан елга буена төшеп китә. Ул кәрзине белән су тутырып ала да, бар көченә бабасы янына чаба башлый. Әмма менеп җиткәнче, су агып беткән була. Хәленнән тайган малай: «Менә, бабай, әйттем бит мин сиңа – болай булмый», – дип нәтиҗә ясап куя. «Син моны мәгънәсез дип уйлыйсыңмы?» – дип сорый бабасы, – «Кәрзингә кара әле». Оныгы кәрзингә караса, ташкүмердән каралып беткән кәрзиннең эчтән дә, тышкы яктан да чистарганын күреп ала. Бабасы: «Балам, Коръән укыган вакытта менә ниләр була. Син аны укыган вакытта аңламаска да, истә дә калдырмаска мөмкинсең. Әмма ул сине эчке яктан да, тышкы яктан да үзгәртергә сәләтле. Менә шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызны да үзгәртә», – дип әйтә.

Кадерле җәмәгать, Коръәни Кәрим – тормышыбызның яшәү күрсәтмәсе, тәнебезгә дәва, күңелебезгә тынычлык булып тора. Рамазан аенда изге гамәлләргә әҗер-саваплар арттырылып бирелә дидек. Шуңа да бу айда күбрәк изгелекләр кылырга, бер-беребезгә мөмкин кадәр ярдәм итәргә, ә инде кичләрен (мөмкинлекләре булганнар – көндезләрен дә) Коръән укып уздырсак иде. Рамазан аеның саваплары бик күп дистә еллар кылган савапларга тиң, әмма ул үзе озак дәвам итми. Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

أَيَّامًا مَّعْدُودَاتٍ ۚ ﴿١٨٤﴾

**«Ураза саналмыш көннәр»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:184

Шуңа күрә, һәр көнне кадерләп үткәрсәк идек. Ә инде: «Хәзрәт, мин Коръәнне тулысынча укый алмыйм, әмма савабына ирешәсем килә»,

– дигән кешеләр булса, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт сәхабәләренә әйткән сүзләрен исегезгә төшерәм. Ул: «Төнлә Коръәннең өчтән берен укый алырсызмы?» – дип сорады. Бу аларга авыр булып тоелды һәм алар: «Ий, Аллаһының Илчесе, төне буе укый алырлык кем бар?» – дигәннәр. Шунда Аллаһының Илчесе: «Ихлас» сүрәсе – Коръәннең өчтән бере», – дип әйткән.

Һәрберебез дә боларны аңлап, белгәннәребез белән гамәл кыла һәм Аллаһы ризалыгына ирешә алсак иде.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*15 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рамазан – уттан котылу ае

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләндергән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, сәламе вә бәрәкәте булсын.

Бүгенге вәгазебезнең темасы – «Рамазан – уттан котылу ае». Аллаһы Тәгалә «Әр-Рахмән», «Әр-Рәхим» – «Рәхимле, Шәфкатьле», ягъни Ул Үзенең колларына карата бик мәрхәмәтле. Ә мәрхәмәтлелек нәрсәдә чагыла соң? Гадәти тормышта моңа бик күп мисаллар табып булыр иде. Шуларның иң бөекләренең берсе – Коръәнне өйрәнә алуыбыз. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

الرَّحْمَٰنُ ﴿١﴾ عَلَّمَ الْقُرْآنَ ﴿٢﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ ﴿٣﴾

**«Рәхман. (Дөньяда мөэминне, кяферне аермыйча, һәр мәхлукатын соң дәрәҗәдә кызганган һәм чын мәгънәсендә нигъмәт биргән Зат). (Дини һәм дөньяви бөтен бәхетләрнең чы-**

**ганагы булган) Коръәнне (кешегә) өйрәтте (һәм шуның белән аңа иң зур нигъмәтне бирде)».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:1-2

Шундый нигъмәт-бүләкләрнең иге-чиге юк. Без аларны саный башласак, һич санап бетерә алмаячакбыз: җир, су, ризыгыбыз, сулар һавабыз, космос, Кояш, динебез һ.б. Әйдәгез, Рамазан ае баргач, аның кысаларында гына карыйк: саваплар арттырылып языла торган Рамазан ае, мең айдан да хәерлерәк бер кич – Кадер киче, зур әҗерләргә ия ураза гыйбадәте, бәрәкәтле сәхәрләр, шатлыклы ифтарлар – болар барысы да бер ай нигъмәте генә. Әмма Рамазан аеның бүләкләре бу гына түгел. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Рамазан ае килү белән җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, ә шәйтаннар богауланып куела», – дип әйтә. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазанның беренче төне җитү белән шәйтаннар һәм тыңлаусыз җеннәр богауланып куелалар. Җәһәннәмнең ишекләре ябыла һәм аларның берсе дә ачылмый. Җәннәт ишекләре ачыла һәм аларның берсе дә ябылмый. Соңыннан бер кычкыручы: «Йә, яхшылык теләүче, монда кил. Йә, начарлык теләүче, тукта», – дип кычкырыр. Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип әйтте.

Бу хәдискә шәрех бирүче галимнәр «җәннәт ишекләре ачыла», дигән гыйбарәне, Аллаһы Тәгаләнең җиргә бик күп нигъмәтләре иңә, дип аңлаттылар. Шулай ук бу айда шәйтаннар богаугa куела. Рамазан ае – гамәлләр өчен бик күп саваплар языла торган һәм шулай ук начарлыклар өчен дә гөнаһ дәрәҗәсе арта торган ай. Шәйтаннарның булмавы кешегә изгелекләрне күбрәк кылырга, явызлыклардан читләшергә булыша.

Ә иң мөһиме: «Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип тәмамлады. Кайбер галимнәребез моны һәр кичтә дип, ә кайберләре авыз ачкан вакытта була дип әйттеләр. Әмма, ничек кенә булмасын, Аллаһы Тәгалә Рамазан аена тагын бер бүләк биргән,

ул да булса – җәһәннәмгә керергә лаеклы кешеләрне дә Аллаһы Тәгалә бу ай хакы-хөрмәтенә уттан азат итә икән. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазанның башы – мәрхәмәт, уртасы – гафу итү, ахыры – җәһәннәм утыннан котылу», – дип әйткән. Бу көннәрдә гафу итү капкалары тулысынча ачыла. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазанның соңгы ун көне турында болай дип әйтә: «Бу – Рәхимле Аллаһыга хөрмәт күрсәтүче коллар өчен җәһәннәм утыннан котылу вакыты».

Хәдистән күренгәнчә, шулай ук Рамазан ае – гафу итү ае. Гафу итү – сиңа начарлык кылган кешеләргә карата киң күңелле була белү. Чын мөселман һәрвакытта да кешеләрне, бигрәк тә үзенең мөселман кардәшләрен, кичерергә әзерлеге белән аерылып тора. Коръәни Кәримдә:

وَجَزَاءُ سَيِّئَةٍ سَيِّئَةٌ مِّثْلُهَا ۖ فَمَنْ عَفَا وَأَصْلَحَ فَأَجْرُهُ عَلَى اللَّهِ ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الظَّالِمِينَ ﴿٤٠﴾

**«Әгәр мәзлум кеше золым кылган кешене гафу итсә һәм араларын якынайтса, бу эшнең әҗере Аллаһы хозурында сакланыр»,** – дип әйтелә.

«Шура / Киңәш», 42:40

Үзегездә булган кичерү сыйфатын һәркем өчен ачыгыз: ул кеше сезне сүз белән рәнҗеттеме, әллә берәр төрле эш-гамәле белән үпкәләттеме – аларны гафу итә белегез. Золымияләрен кичереп, сез аларны алда кылачак начарлыкларыннан саклап кала аласыз, шулай ук, үзегездә булган рәхимлелек сыйфатын да арттыруга китерәсез. Ә Кыямәт көнендә гафу итүче кешеләр, үзләренә золым салган кешеләрне гафу итмәүчеләрдән югарырак та булачаклар.

Рамазан ае уттан котылу ае дип әйттек. Әмма: «Мин уттан котылучылар санына керермен әле», – дип, берни дә эшләмәү дә дөрес түгел.

Кешелек дөньясы зәгыйфь итеп яратылган: ул гөнаһ кылучан зат. Әмма Аллаһы Тәгалә аңа тәүбәгә килү нигъмәтен биргән. Әлбәттә, тәүбәләр Рамазанда да, Рамазаннан тыш та кылынырга тиеш. Пәйгамбәребез Гайшә радыяллаһу ганһәгә өйрәткән доганы кылып, шушы изге айны бәрәкәтле итеп үткәрергә насыйп булсын иде:

اللَّهُمَّ اِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

Әллаһуммә иннәкә гәфүввун түхиббуль гәфвә фәәгфугәнни

«Йә Аллаһы! Син – гафу Итүче һәм (гөнаһлы бәндәләреңне) гафу итәргә яратасың. Гафу итче мине![1]»

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

1 Ибне Мәҗе, Дога: 5, №3850, 2/1265

*22 май вәгазе,*

*Рамазан аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рамазан аен озату

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле булган, галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Илчесе, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның Мостафасы, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Хөрмәтле җәмәгать, кадерле дин кардәшләрем, җомга көне һәм Рамазан аеның ахыргы ункөнлеге мөбарәк булсын, кылган гамәлләребездән Аллаһы Тәгалә риза булсын, әҗер савабын күреп сөенергә язсын! Чыннан да, бу вакытлар безнең өчен бик бәрәкәтле вакытлар, кадерен белик. Бу вакытны дөньябызда да, Ахирәтебездә дә бәхетле булырдай итеп үткәрик.

Беренчедән, җомга көненең фазыйләте һәм башка көннәрдән аерылып торган дәрәҗәсе бар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

**«И, иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен (азан әйтелеп) чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу – (сәүдәнең вакытлы файдасыннан) сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде (мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез)».**

«Җомга», 62:9

Икенчедән, Рамазан ае һәм ахыргы ункөнлеге. Рамазан аеның фазыйләтләре турында күп әйтелсә дә, яңартып әйткәндә, Рамазан ае – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, кичерүенә һәм ут газабыннан котылып, иксез-чиксез әҗер савапларга ирештерә торган ай икәнен истән чыгармыйк. Рамазан аеның ахыргы ун көне дә, бигрәк тә мең айдан да хәерлерәк Кадер киче безнең өчен бәрәкәтле, файдалы вакытлар. Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында: «Аллаһының Илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк гыйбадәттә тырышлык күрсәтә иде», – дип әйткән.

Айларның иң хәерлесе – Рамазан аедыр, көннәрнең иң хәерлесе – җомга көнедер, төннәрнең иң хәерлесе – Кадер кичедер.

Сагынып көтеп алган, көндезләрен уразада, кичләрен ифтарда, тәравихта, догада уздырган аебыз – Рамазан ае үтеп тә бара. Санаулы көннәр генә калды. Һәрбер эшнең башы булган кебек, ахыры да була. Ничек ихласлык белән, тырышып башлаган булсак, шулай ук гыйбадәттә, тәкъвалыкта тәмам кылу кирәк була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гамәлләрнең дәрәҗәсе ничек тәмамлануы белән билгеләнә», – дип әйткән. Ягъни, ай буе үзеңне гамәл-гыйбадәт белән тәрбияләп, шушы тәрбияне, яхшы гамәлне үзеңә сеңдерү, тормышыңда куллану динебезнең олуг бер максаты. Күпләр өчен Ислам диненә керешү ураза тотудан, нәфесен тәрбияләүдән башланды. Үзенең Аллаһы Тәгаләнең бәндәсе булуын аңлап, кешенең нәфесе тәрбияләнә, башкаларга мөнәсәбәте яхшыра. Әмма, бу мәдрәсәне узганнан соң, аннан алган гыйлемне, тәрбияне дәвам итү кирәк була. Рамазан аенда гына гыйбадәт кылып, изге ай тәмамлангач гыйбадәтләрне кылдыру, мәчеттән һәм җәмәгатьтән ерагаю – начар күренеш. Чөнки мөселман булу бер Рамазан ае белән генә бәйле түгел. Мөселман кешесе гомере буе Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алуда тырышлык куярга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاعْبُدْ رَبَّكَ حَتَّىٰ يَأْتِيَكَ الْيَقِينُ ﴿٩٩﴾

**«Киләчәгенә һич шик булмаган (үлем дигән) нәрсә сиңа ирешкәнче, (бер мизгелне дә бушка уздырмыйча) Раббыңа (һәрдаим) гыйбадәт кыл».**

«Хиҗер», 15:99

Күп тырышлыклар куеп, ихласлылык белән уздырган Рамазан аеның, тырышып, күңелне биреп әзерләгән ризык кебек күңелдә бер гамәл белән дә алып булмый торган тәме һәм ләззәте кала. Читтән караганда ураза тоту, тәравих намазларын уку, сәхәргә тору авыр кебек тоелса да, аның ләззәтен татыган бәндәгә Рамазан ае бары тик күңел тынычлыгы һәм бәрәкәт алып килә.

مَنْ عَمِلَ صَالِحًا مِّن ذَكَرٍ أَوْ أُنثَىٰ وَهُوَ مُؤْمِنٌ فَلَنُحْيِيَنَّهُ حَيَاةً طَيِّبَةً ۖ وَلَنَجْزِيَنَّهُمْ أَجْرَهُم بِأَحْسَنِ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿٩٧﴾

**«Һәр мөэмин ир яки мөэминә хатын (иман шартларына шөбһәсез иман китереп) изге гамәл кылса, Без аңа (дөньяда да, кабердә дә, җәннәттә дә) бик күркәм тормыш бирәчәкбез. (Моннан соң алар үлемсез бер тормышка, фәкыйрьлек куркынычы булмаган бер байлыкка, саулыкка, югалмаячак милеккә һәм мәңгелек бер бәхеткә ирешәчәкләр). Һичшиксез, алар кылган нәрсәләрнең әҗерләрен иң күркәме белән бирәчәкбез».**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:97

Хөрмәтле газиз дин кардәшләрем! Рамазан ае тәмамланып, Ураза гаетен бәйрәм итәргә дә күп калмады. Без аеруча шушы изге бәйрәм көннәрендә яхшылык эшләүдән тыелмаска, аны эшләргә ашыгырга ти-

ешбез. Бәйрәм рухын башкалар белән дә уртаклашу, башкаларны да сөендерү – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең матур, күркәм сөннәте.

Быел җөмһүриятебездә Ураза гаете 24 нче майда, якшәмбе көнне булачак. Һәрбарчаларыбызга да шушы көнне бәйрәм итеп, тоткан уразаларыбызга, укыган намазларыбызга, Коръәни Кәримгә, кылган гыйбадәтләребезгә дөньялыкта һәм Ахирәттә сөенергә язсын.

Бәйрәм намазына кадәр Рамазан аенның тагын бер фазыйләтле гамәле – ул фитыр садакасы. Аның хөкеме – вәҗиб. Ягъни эшләү тиешле, калдырырга ярамый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Фитыр садакасы биргәнче бәндәнең уразасы күк белән җир арасында эленеп торыр, фитыр садакасын биргәч, күккә иңәр», – дип әйткән. Ягъни, галимнәр аңлатуынча фитыр садакасы уразада булган кимчелекләрне, хаталарны пакьли торган гамәл. Шулай ук, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Бу көнне мохтаҗларны кул сузып (теләнеп) йөрүдән коткарыгыз», – дип әйткән. Димәк, Рамазан аенда, бигрәк тә шушы бәйрәм көнендә, гает намазына кадәр мохтаҗларны сөендерү һәм аларның ихтыяҗларын үтәү хәерле гамәлләрдән санала.

Кемнәргә бирелә дигәндә, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّمَا الصَّدَقَاتُ لِلْفُقَرَاءِ وَالْمَسَاكِينِ وَالْعَامِلِينَ عَلَيْهَا وَالْمُؤَلَّفَةِ قُلُوبُهُمْ وَفِي الرِّقَابِ وَالْغَارِمِينَ وَفِي سَبِيلِ اللَّهِ وَابْنِ السَّبِيلِ ۖ فَرِيضَةً مِّنَ اللَّهِ ۗ وَاللَّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ ﴿٦٠﴾

**«Садакаларны (зәкятләр) бары тик (бернинди малы һәм кәсеп итү мөмкинлеге булмаган) фәкыйрьләргә, (берникадәр малы һәм кәсеп итү юлы булса да, бу гына җитәрлек булмаган) мескеннәргә, (бай булса да, зәкят җыю белән) вазифалыларга, күңелләре (Ислам диненә) тартылганнарга, (иреккә чыгарга**

**теләгән) колларга, бурычлыларга, Аллаһы юлында (яу, хаҗ һәм гыйлем юлына чыккан мохтаҗларга) һәм (туган якларында бай булсалар да, ниндидер сәбәпләр аркасында мохтаҗ булып) юлда калганнарга бирү Аллаһы тарафыннан фарыз кылынды[1]. Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе».**

«Тәүбә», 9:60

Һәм халык арасында күпме бирергә дигән сорау туа. Моңа җавап итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен җиткерик: Пәйгамбәребез гәләйһиссәлам бәйрәм көнне гает намазына чаклы бер сагъ күләмендә кол йә ирекле мөселманга хөрмә йә арпаны садака итеп бирергә кушкан[2]. Ягъни, күләмен Аллаһының Илчесе үзе билгеләгән һәм, иң аз дигәндә, шушы күләмдә әйтелгән рәвештә яки мохтаҗ кешенең ихтыяҗына карап ризыклата, акчалата бирү дөрес була. Һәм бу мәсьәләне җиңеләйтү йөзеннән, гыйлемсез булып, ялгышып китмәс өчен мөфтиятебез бу күләмне акчалата тиңенә (эквивалентка) күчереп фәтва бирә. Безгә үтәү генә кала. Фитыр садакасын гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән бирә ала.

Шулай ук, сүземнең ахырында, гает намазының үткәрелү тәртибен, вакытын алдан җирле имамнардан белешү, сорауны киңәш итәм.

Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, укыган тәравих намазларыбызны, кылган изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны кабул

---

[1] Монафикълар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ганимәт бүлүен гаепләгәч, Аллаһы Тәгалә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмерен хуплау сыйфатында шушы аяте кәримәне иңдергән. Зәййәд бине Харс радыяллаһу ганһе болай дип хәбәр иткән: «Мин Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып бәйгать бирдем. Шул вакытта бер кеше килеп, зәкяттән бер өлеш сорагач, Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә зәкят һәм аның таратылуы хакында ни бер пәйгамбәрнең, ни башка бер кешенең хөкеменә разый булмыйча, алар хакында шәхсән Үзе хөкемен чыгарды һәм аларны сигез өлешкә бүлде. Әгәр син ул сигез өлешкә керүчеләрдән булсаң, сиңа хакыңны бирермен», – дип әйтте» (Әбү Давыд, Зәкәт: 24, № 1630, 1/512).

[2] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

итсен, хата-кимчелекләребезне кичерсен, күңелләребездә нинди изге теләкләребез, уй-ниятләребез булса – шуларга ирешергә, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә лаек булырга насыйп итеп, барыбыздан да разый булса иде.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

# Ураза Гаете вәгазе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, хәмде-сәналәребез галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә һәм дә салават шәрифләребез Аның сөекле хәбибе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән, мөселманнарга һидаять юлын күрсәткән Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә, табигыйн һәм тәбге-табигыйннарга, галим-голәмәләргә, имамнарга, остазларга, шәехләргә, ислам юлында булган бәндәләргә Аллаһының рәхмәте һәм мәгъфирәте иңсен. Безгә тәүфыйк-истикамәттә булып, шөкерана кылучылардан булырга насыйп итсен.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүген бөтен ислам дөньясы, барлык мөселман республикалары мәчетләрендә Гыйдуль Фитр – ураза бәйрәме көне билгеләп үтелә. Ураза бәйрәме – мөбарәк һәм данлы көн, бер тарафтан ул шатлык көне, ә икенчесеннән – кайгыру, чөнки бу Рамазан аен озату көне. Без 2021 елның Рамазанына ирешә алырбызмы икән? Анысы да бер Аллаһыга гына мәгълүм. Унбер ай эчендә көтеп алынган кунак безне яңадан бер елга калдырды, үзе белән төрле-төрле бүләкләр алып килгән, безнең тышкы ягыбызны тигезләп, эчке рухи халәтебезне дөресли торган гадел бер мөбарәк ай узып китте.

Гыйбадәт кылгандагы ләззәтне саклап, кылган догаларыбыз һәм изгелекләребез аркылы ихласлыгыбызны бер елга шундый халәттә саклый алсак иде. Раббыбыз, барыбызга да ел дәвамында Коръәни Кәримгә тиешле игътибар бирергә, аны укып, тыңлап, үзебездә Изге Китапның нурын йөртергә насыйп итсен. Фани дөньяга сокланмыйча, дөньяның

бизәкләренә алданмыйча, хак мөселманнар булып, әхлакый яктан үзебезне бизәп, әти-әниләребезнең хакын хаклап, күркәм мирасыбыз булган динебезне саклаучылардан булсак идек. Дога кылып, киләсе елның бәрәкәтенә, тынычлык-иминлегенә, эшләребезнең уңышлы нәтиҗәсенә ирешүне Раббыбыздан сорасак иде.

Хикмәт Иясе булган Раббыбыз Үзенең гыйлеме белән тәкъдирләрне урнаштыручы, безне төрле имтиханнар белән сынаучы Зат. 2020 ел коронавирус чире белән бөтен дөньяны куркыткан, күп кешеләрнең сабырлыкларын сынаган ел булды. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ وَالثَّمَرَاتِ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ

> **“Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, (бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп) уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. (Расүлем!) (Сынауларга) Сабыр итүчеләрне (җәннәт белән) сөендер!”**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

Шушы аятьтә Аллаһы Тәгалә Үзенең колларын сынауларга дучар итүен хәбәр итте. Шуның аркасында үзебезнең нинди кешеләр булуыбызны, сабырмы, юкмы икәнлегебезне аңлый алабыз. Аллаһы Тәгалә коллары белән һәрчак шулай эш итә, чөнки кешеләр озак вакытлар сынауларга дучар ителмәсә, аларның хаталанып, гөнаһларга төшү ихтималы бар, ә бу начар нәтиҗәләргә китерәчәк. Менә шуңа күрә дә илаһи зирәклек гадел кешеләрне явызлардан аера. Бу очракта сынаулар бик зур файдага ия булып тора.

Сынау дигәндә, кешеләрнең балаларын, туганнарын, дусларын һәм, гомумән, якын кешеләрен югалтуы, аларның һәлак булуы, шулай ук

кешенең үзенә яки аңа кадерле кешеләренә килгән авырулар күздә тотыла. Бу очракта кешеләр сабыр һәм түземсезгә бүленә.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе югарыда истә алынган аятькә нигезләнеп, болай дип әйтте: “Аллаһы мөэминнәргә бу дөньяның “Бәла дөньясы” булуын хәбәр итте. Ул мөэминнәрне сыный, әмма мөэминнәр сабырлык күрсәтергә тиеш. Аллаһы Тәгалә сабыр колларын Үзенең җәннәте белән шатландырыр”.

Әгәр адәм баласы сынау вакытында тиешле сабырлык күрсәтә, сүздән һәм эштән канәгатьлек белдерә икән, бу кешегә моның өчен Аллаһы зур әҗерләрен бирәчәк. Һәм әлеге бәла-казаларга сабырлык күрсәтү аның өчен Аллаһы мәрхәмәтенә әйләнәчәк. Кыенлыкларга сабыр булган кеше, Аллаһы ихтыярына буйсынып, зур әҗерләргә лаек була һәм, шул рәвешле, аның Аллаһы алдында дәрәҗәсе күтәрелә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُم مُّصِيبَةٌ قَالُوا إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ

**“Берәр бәлагә юлыкканнар: “Һичшиксез, без – Аллаһынықылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!” – дип әйтәләр.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:156-157

Без 2020 елда, ислам принципларына таянып, шулай ук республикадагы санитар-эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып, яңадан бергәләп шул имтиханнарга түземлек күрсәтәбез һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы тарафыннан тәкъдим ителгән җомга, җеназа, һәм тәравих намазларын уздыру тәртибе хакындагы карарны мәчетләргә җиткердек.

Бу катлаулы заманнарда якын кешеләребезне: ата-аналарыбызны, туганнарыбызны онытмыйк, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

**“(И, коллар!) Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, (бертуганнар һәм агалар кебек) якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, (нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән) якын күршегә, (нәселдәшлеге яки өе) ерак күршегә, (ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек) янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә (коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә) игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер (булганы өчен туганкардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган) һәм (өстенлекләрен санаган) мактанчык кешеләрне сөйми”.**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Бәйрәм көннәрендә электән килгән күркәм гадәт аерым урын алган, ул – әти-әниләребезнең хәлен белү, аларны кунак итү, гаиләбез белән бергәлектә олуг бәйрәмебезне каршы алу. Хөрмәтле мөселман кардәшләребез! Кешеләргә Аллаһының рәхмәте белән иңдерелгән Коръәни Кәрим китабы белән яшәргә һәм аның белән гамәл кылырга өйрәнсәк иде! Коръән белән гамәл кылу җыйган малдан хәерлерәк. Югарыда искә алынган аятьтә үк ятимнәргә, мохтаҗларга һәм мескеннәргә ярдәм күрсәтүнең дә безнең өстә булуы ассызыкланды. Әйтик, Рамазан аенда ярдәм күрсәтүче волонтерлар эшли. Бу күркәм гадәт алга таба да шулай дәвам итсә иде. Ә Рамазанда ярдәм күрсәтә алмаганнар исә бүген яки бәйрәм көннәрендә садаканың фарыз төре булган зәкятне һәм вәҗиб

булган фитыр садакасын бирә ала. Шулай ук сәламәтлеге какшаган һәм уразаны Рамазаннан соң да тота алмаучылар, уразаның тотылмый калган һәрбер көне өчен 200 сум күләмендә фидия садакасы түләргә тиешле була.

Өстәмә күркәм гадәт, сөннәт гамәл – кардәшләребезнең, дусларыбызның хәлен белергә бару, аларга изге теләктә булу, мәрхүмнәребезнең каберен зиярәт итеп, Раббыбызга дога кылу:

«روى البيهقي في السنن الكبرى عن عليّ رضي الله عنه أنه قال الجهر في صلاة العيدين من السنّة، والخروج في العيدين إلى الجبّانة(المقبرة) من السنّة»

Гали радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Ике бәйрәм намазы (Ураза һәм Корбан) вакытында чыгу – сөннәт булып санала һәм бәйрәм көннәрендә каберне зиярат кылу сөннәттән».

Без Шәүвәл аена аяк бастык. Бу айда өстәмә алты  көн ураза тоту күркәм сөннәт гамәл булып санала.

«مَنْ صَامَ رَمَضَانَ، ثُمَّ أَتْبَعَهُ سِتًّا مِنْ شَوَّالٍ كَانَ كَصِيَامِ الدَّهْرِ»

Әбү Әюб Әл-Әнсари Расүлебез галәйһиссәламнең бу сүзләрен риваять иткән. Аллаһы Тәгаләнең Илчесе галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Рамазан аенда һәм аннан соң Шәүвәл аенда алты көн дәвамында ураза тотучылар бер ел ураза тоткан әҗерләр алыр»[1].

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләренә Шәүвәл аенда ураза тотарга кушкан. Бер хәдистә: «Әгәр дә кол Аллаһы юлында бер генә көн ураза тотса да, Аллаһы Тәгалә аны җәһәннәмнән җитмеш елга ераклаштырыр», – дип әйтелгән.

[1] Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Раббыбыз тоткан уразаларыбызны, биргән садакаларыбызны, укыган намазларыбызны кабул кылсын, безне, якыннарыбызны төрле бәла-казалардан, авыру-чирләрдән сакласын. Йортларыбызда өлфәт-мәхәббәттә авылыбызда, бистәбездә, шәһәребездә, җөмһүриятебездә, дәүләтебездә тынычлыкта һәм татулыкта яшәүләребезне һәм барыбызга да сабырлыклар биреп, авыручыларга саулык-сәламәтлекләр насыйп кылса иде.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللَّهُ وَاللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلاَّ الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اَللَّهُ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الْأَئِمَّةِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلاَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа’имиинә әбүәәбән-нииираани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-райййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа’имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гуҫмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыйинә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләҙиинәт-тәкау

вәлләҙиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаҙыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәҙҙикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-гаҙыйимү сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә нуʼминү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәәʼи вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләәʼикәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмүʼминиинә вәл-мүʼминәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*29 май вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Әбү Хәнифә мәзһәбе

Әгуузу билләһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Ислам дине белән таныш булмаган кешеләр динне бертөрле дип кабул итәләр. Бер мөселман үзенең гыйбадәте башка кешенекеннән аерылса гаҗәпләнер. Чыннан да, Ислам диненең нигезе бер: Аллаһыга ышану, Расүлебезгә иярү, намаз, ураза, зәкят, хаҗ кылу тәртипләре дә җирнең бөтен төбәкләрендә мөселманнар тарафыннан бертөрле башкарыла. Тик кайчагында алар кайбер мәсьәләләрдә төрлечә була. Гадәттә бу аерылу диннең нигезләренә түгел, ә аның икенчел мәсьәләләренә кагыла. Диннең шәригать мәсьәләләрендә аерылуы мәзһәбләрнең төрлелеге белән аңлатыла. Мең елдан артык мөселманнар шулай яшәгәннәр, бер-берсен мөселман дип санаганнар. Тик соңгы елларда, без намазны дөрес укыйбыз, ә сез дөрес укымыйсыз, дигән кешеләр барлыкка килде. Хәтта, мәзһәбләргә иярү дөрес түгел, ул мәзһәбләрнең имамнары ялгышкан, дияләр. Андый гаепләүләр Әбү Хәнифә мәзһәбенә карата еш яңгырый. Шул сәбәпле Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча намаз укыган олы кешеләрне хатада гаепләү дә сирәк түгел. Бу, үз чиратында, җәмәгатьнең аерылуына, бер-береңә нәфрәт хисе тудыруга китерә. Шуңа да бу мәсьәләдә ачыклык кертергә кирәк.

Мәзһәбләр Ислам диненең башлангыч чорында ук барлыкка киләләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чагында мөселманнар бөтен кызыксынган мәсьәләләре турында турыдан-туры

аннан сорый алганнар. Ул аларга аңлата торган иде һәм монда башка уй-фикергә урын калмаган. Тик Пәйгамбәребез галәйһиссәлам вафатыннан соң да сораулар туган. Аларга җавап табарга теләүчеләр сәхабәләр янна-рына барганнар. Күпләре хәтта сорауларга җавап бирүдән баш тарткан, чөнки ялгышып, дингә хата кертүдән курыкканнар. Сәхабәләр арасын-да динне, шәригатьне яхшы аңлаучылар да булган. Алар: Гомәр бине Әл-Хаттаб, Гали бине Әбү Талиб, Ибне Габбас, Ибне Гомәр, Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһүм һәм башкалар. Тик бу сәхабәләр дә кайчагында бер үк сорауга төрле җавап биргәннәр. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки кеше, урын, вакыт, шартлар үзгәрү белән сорауга җавап та үзгәрергә мөмкин. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә бер үк сорауга төрле очракта төрле җавап биргән, чөнки сәхабәләрнең бер сәфәрдә бер-се, икенчесендә икенчесе булган. Шулай итеп фикерләр дә төрле булып киткән, ләкин алар төрле булсалар да, Ислам дине шәригать кысаларын-нан чыкмаган. Аңлавыбызча, сәхабәләр вакытында ук төрлелекләр бар-лыкка килә. Бүгенге көндә без шуларны күрәбез. Бу төрлелек шәригатькә, фикһ хөкемнәренә карый, әмма иман мәсьәләсендә һәрвакытта да кат-гый бердәмлек саклана. Әгәр иман өлкәсендә берәрсе башка төрле әйбер сөйләсә, бу инде аерым мәзһәб дип түгел, ә фирка, секта дип аталган. Иманда бөтен сәхабәләр бер фикердә булган.

Сәхабәләрдән соң килгән мөселманнарны табигыйннар (иярүчеләр) дип атыйлар. Алар да, үз чиратында, нинди сәхабәгә иярүләренә карап, фикһ мәсьәләләрендә төрле фикердә булганнар. Мәзһәбләрнең килеп чы-гуы нәкъ алар вакытыннан башлана, чөнки сәхабәләрнең вафат булуы һәм мөселманнарның күбәюе сәбәпле хәдисләр белән генә динне тотып бул-мый башлый. Хәдисләргә һәм, әлбәттә, аятьләргә, сәхабәләрнең сүзләренә таянып, бердәм кагыйдә чыгару ихтыяҗы туа. Шул кагыйдәләр җыентыгы мәзһәб дип атала. Әгәр шул вакытта мәзһәбләр барлыкка килмәгән бул-са, динне бүгенге көнгә кадәр үзгәртмичә саклау мөмкин булмас иде,

чөнки мәзһәбләр ярдәмендә дин наданнар, фетнәчеләр тарафыннан бозылудан саклана. Без белгән дүрт мәзһәб: Әбү Хәнифә, Имам Мәлик, Имам Шәфигый, Имам Хәнбәли рахмәтуллаһи галәйһим мәзһәбләре шул чорда барлыкка килгән. Бу чор өч буынны үз эченә ала: сәхабәләр, табигыйннар һәм тәбге-табигыйннар (табигыйннарга иярүчеләр) вакыты. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу өч буын турында: «Иң яхшы кешеләр минем гасырда, миннән соң килүчеләр гасырында һәм алардан соң килүчеләр гасырында булыр», – дип әйтә[1]. Шул рәвешле мәзһәбләр һәм мәзһәб галимнәре иң яхшы гасыр һәм кешеләр вакытына туры киләләр. Югарыда искә алынган дүрт мәзһәбтән тыш, башка мәзһәбләр дә була, ләкин алар киң таралыш тапмыйлар һәм бүгенге көнгә кадәр сакланмаган диярлек.

Дүрт мәзһәб арасында иң киң таралганы: хәзрәти Әбү Хәнифә мәзһәбе булып тора. Моның сәбәбе: Госманлы солтаннар заманынында хәнәфи мәзһәбенең дәүләт мәзһәбе булуында һәм аның укучыларының күплегендә. Тарихи сәбәпләр аркасында безнең Урта Рәсәй, Себер җирлегендә хәнәфи мәзһәбе төп мәзһәб булып санала. Мәзһәбләр арасында кайбер аермалар булса да, нигездә алар бер-берсенә каршы килми. Шуңа да галимнәр бу мәзһәбләрне тигез дип карыйлар. Иң хәтәре – бу мәзһәбләрнең берсен дә танымау. Бу очракта кеше диндә адашырга мөмкин. Кешенең берәр нәрсә өйрәнәсе килсә, аны кешедән өйрәнергә тиеш. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Дин – ул тән һәм каннан тора (кеше дигән сүз), аны кемнән алганыңны кара». Шуңа да динне өйрәнүнең үз тәртибе бар. Аны Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән яки аны күргән кешедән өйрәнү дөрес. Шулай итеп дин буыннан-буынга тапшырыла. Әйткәнебезчә, 4 мәзһәб галимнәре иң яхшы гасырда, иң яхшы кешеләр арасында яшәгәннәр, үзләре дә шулардан булганнар. Димәк, алар динне өйрәнү өчен иң лаеклы кешеләр.

[1] Имам Әл-Бохари, Имам Әл-Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

Әйтеп үткәнчә, безнең җирлектә хәзрәти Әбү Хәнифә мәзһәбе таралган. Әбү Хәнифә һиҗри белән 80 нче елны Гыйракта туа. Ул туган чорда илнең күпчелек өлкәләрендә төп галимнәр фарсы халкыннан иде. Аның гарәп булмавы дин галиме булуына комачауламый. Кайберәүләр, Әбү Хәнифә Мәккә яки Мәдинәдә тумагач гыйлем ала алмаган, диләр. Бу да дөреслеккә туры килми, чөнки күпчелек сәхабәләр хәлифәт буенча таралалар, Гыйракта да алар күп була. Әбү Хәнифә туган Куфа шәһәре илнең башкаласы булып тора. Шул сәбәпле, Әбү Хәнифә күп хәдисләрне белмәгән дигән сүз дә хаклыкка туры килми. Әйткәнебезчә, галимнәр, сәхабәләр Гыйракта җитәрлек булган. Мәсәлән, Әбү Хәнифәнең галимнәре: Габдулла бине Мәсгуд, Галкамә бине Кайс, Ибраһим Нәхагый, Хәммәд бине Әбү Сөләйман. Шулай ук Әбү Хәнифә – Әнәс бине Мәлик, Габдулла бине Әбү Гавеф, Сәһел бине Сәгыйди, Гамир бине Вәсилә һ.б. радыяллаһу ганһүм кебек сәхабәләрдән гыйлем ала. Димәк, ул үзе табигыйннардан була. Әбү Хәнифәнең укучылары имам Шәфигыйны укыталар. Аның галим булуында ул чордагы галимнәрнең дә, аннан соңгыларының да шиге юк. Әбү Хәнифә кеше буларак та үз эченә иң яхшы сыйфатларны җыйган. Аның юмартлыгы, тәкъвалыгы һәр мөселманны сокландыра. Шиксез, ул иярүгә лаеклы галим. Әгәр аңа ияреге теләмәсәң, ким дигәндә, аның кебек булырга, йә гыйлем һәм тәкъвалык ягыннан аны узып китәргә тырыш. Бүгенге көндә безнең җирлектә Әбү Хәнифә мәзһәбе таралган икән, аңа иярү хәерле, чөнки мәзһәбтән чыгу адашуга, ә Әбү Хәнифә мәзһәбен башка мәзһәбкә алыштыру фетнәгә китерә (бөтен мәзһәбләр асылда бер икән, бөтенесе дөрес икән, безгә башкасына күчүдән, фетнәдән гайре, нинди мәгънә). Мәзһәбкә ияреп без тормышыбызны күпкә җиңеләйтәбез. Безгә дәлилләр эзләргә, ярты гомеребезне бәхәсле мәсьәләләргә багышларга кирәк түгел. Тыныч кына гыйбадәт кылырга, рухи яктан камилләшергә мөмкинлек туа, чөнки Әбү Хәнифә Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә якынрак булган. Әбү Хәнифә мәзһәбен сайлаган бабаларыбыз да Расүлебез

галәйһиссәламгә якынрак булганнар. Алар белән бәхәсләшү гадел булмас иде. Аллаһы Тәгалә хикмәттән, туры юлдан аермасын.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин,*

*«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы*

*5 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Күркәм әхлак – яшәү рәвеше

Галәмнәрне юктан бар итүче, безгә җан, тән, ризык бирүче Аллаһы Тәгаләгә дан-мактаулар булсын. Бөтен галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Раббыбыз адәм баласына олы нигъмәт биргән, ул нигъмәт – акылдыр. Без нәрсәнең яхшы вә нәрсәнең начар икәнен аңлап, яхшылары белән исә гәмәл кылып, ә начарларыннан ерак тора алабыз. Безне бизи торган иң зиннәтле сыйфат – ул әдәп вә әхлак. Ул –иманның дәрәҗәсе югары булуның бер билгесе. Әхлакны төрлечә кулланып була, ягъни кеше никадәр ихласлы булса, шуның кадәр әхлагын камилләштерә. Аллаһының Илчесе бер хәдисендә: «Мин бу дөньяга әхлакны камил дәрәҗәгә ирештерер өчен килдем», – дип әйткән. Ягъни, Расүлебез галәйһиссәламнең шушы дөньяга килүенең төп сәбәбе булып, кешеләр арасында мәрхәмәтлелекне арттыру, бер-береңә ярату хисен тарату тора.

Без бүген пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә күп игътибар бирергә тырышабыз. Тышкы сөннәтләрен үтибез дә кебек, әмма иң зур сөннәт булган яхшы мөнәсәбәт кылуга аз игътибар юнәлтәбез. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

**«(Расүлем!) Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – (гөнаһларны күпләп) Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Әхлаклы булу – ул бөтен пәйгамбәрләрнең сөннәте булып тора. Әхлакның күп төрләре бар. Аларны карап үтик:

Аллаһы Тәгаләгә карата булган әхлак, ягъни Аллаһы Тәгаләдән ояла белү, Аның мәхлүкъларына яхшы мөнәсәбәттә булу.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата әхлак күрсәтү, аның хакында сөйләшкәндә матур сүзләр кулланып сөйләү, исемен әйтүгә салават әйтү.

Әти-әнигә карата әхлак күрсәтү. Алар белән матур, яхшы итеп сөйләшү. Аларның гөнаһлы булмаган хаҗәтләрен үтәү, аларны рәнҗетмәү, борчымау. Аларны күп сөендерергә тырышу. Шунысын белү мөһим: ата-анага әхлаксызлык күрсәтүченең үзенә дә картлык көнендә әхлаксыз бала булыр.

Күршеләр, туганнар, дуслар, кардәшләр белән дә әхлаклы булырга кирәк. Дорфа вә әхлаксыз булсаң, синең янында якын кешеләр калмаячак. Әгәр дә үрнәк алырдай кеше эзлисең икән, иң беренче итеп әхлакка бай булган кешедән үрнәк алырга кирәк, чөнки бүгенге көндә сүз белән зур эшләр кылучылар күп, әмма гәмәлдә, үзенең яшәү рәвешендә күркәмлекне күрсәтүчеләр аз. Әхлак – ул яшәү рәвеше. Ул мәчеттә генә яки үзеңә кирәк кеше янында гына бик тәрбияле булып, бүтән кешеләр янында «битлек кию» булырга тиеш түгел. Синең әхлагың, синең нинди җәмгыятьтә булуыңа карап үзгәрергә тиеш түгел. Әгәр дә бу алай түгел икән, син берәүләр янында бер төрле, икенчеләр янында икенче төрле икән, димәк, әле үзеңнең әхлагыңны камилләштерергә кирәк. Бер генә мизгелгә үз-үзебезгә ихластан сорау биреп карыйк әле: «Кем мин?» «Әхлагым нинди дәрәҗәдә?»

Бервакыт хастаханәдә табибка чиратта торганда, ике кеше чират бүлешә алмадылар, бер-берсенә нинди генә сүзләр әйтеп бетермәделәр. Ә бит сүзләрне әйтү җиңел, әмма әйткәннән соң гафу үтенеп бетерү генә бик авыр мәсьәлә. Әхлак безнең холыкның иң күркәм ягы булырга тиеш. Ата-ана баласына бирә ала торган иң зур бүләк – ул тәрбия. Димәк, кешенең әхлак ягы да бик югары булырга тиеш. Әмма соңгы вакытларда без балалар, яшьләр арасында бу төшенчәнең бик «аксаганын» сизә алабыз. Бүгенге көндә тәртипле бала хәзинәгә тиң. Кызганыч, бүген балалар өчен төп тәрбияче булып смартфон, планшет һәм интернет тора. Мәгънәсез фильм, видео, блоглар – болар яшь буын өчен бик начар үрнәк. Чын үрнәк алыр өчен безгә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрне, галимнәрне, акыл ияләрен бирде. Хикмәт белән эш итүче, үзләренең гамәлләре белән дингә өндәүче остазларны үрнәк итте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына күз салсак, Аллаһының Илчесе әхлак һәм тәрбиясе булмаган халыкка кыска вакыт эчендә әдәплелекне, тәрбиялелекне җиткерә. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Сезнең өчен (бигрәк тә) Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм (курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә) Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүлендә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) күркәм үрнәк бар».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Әхлакның бер ботагы – ул дин кардәшләргә карата яхшы мөнәсәбәт. Рамазан ае буе без уразалар тотып, бергәләшеп тәравих намазлары

укыдык. Әмма кайвакыт без туганнарга, дусларга карата әхлаксызлык күрсәтәбез. Шуларның берсе – ул сәлам бирмәү яки сәламгә җавап кайтармау. Ислам дине «сәлам» сүзе белән тамырдаш булган иминлек, тынычлык сүзләре белән бәйле.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Мөселманнар бер-берсенә сәлам биреп, кулга-кул тотынышып торганда гөнаһлары коелыр», – дип әйткән. Бер мөселман икенче мөселманга кардәш, аларның бер-берсе өстендә хаклары бар. Берәү кардәшенә сәлам бирсә, ул аның сәламенә җавап кайтарырга тиеш. Без кардәшлекне калдырырга тиеш түгел, Аллаһының бәрәкәте шушы кардәшлек булуда. Без кардәшләребезнең, нинди булуларына карамастан, аларга хөрмәт, Аллаһы ризалыгы өчен ярату һәм мәрхәмәт белән карарга бурычлы. Коръәндә Раббыбыз болай дип әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ ﴿١٠٣﴾

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына (Китабына һәм диненә) ныклап ябышыгыз һәм (әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән) аерылмагыз. Аллаһының сезгә биргән (игелек һәм) нигъмәтен истә тотыгыз. Сез (җаһилият чорында бик озак еллар буена бер-берсе белән сугышкан) дошманнар булган чакта, Ул (сезне Ислам дине белән шәрәфләндереп) күңелләрегез арасында (татулык һәм бер-берегезгә карата җылылык яратып) өлфәт бердәмлек**

**барлыкка китерде, һәм сез Аның (бу) нигъмәте белән[1] (бер-берләрен бик якын күргән) кардәшләр булдыгыз. Янә сез (кяферлегегез сәбәпле) Ут упкыны ярында чакта, (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәреп) Ул сезне аннан коткарды. Аллаһы аятьләрен сезгә шулай бәян итә, – бәлки, сез һидаять табарсыз».**

«Әли Гыйимран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Шулай ук Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә болай дип әйтә:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ فَأَصْلِحُوا بَيْنَ أَخَوَيْكُمْ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٠﴾

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр. Шуңа күрә кардәшләрегезне татулаштырыгыз. (Һәр эштә булганы кебек, дин кардәшләрегезнең араларын якынайтуны да җиңелгә алуда) Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, рәхмәт ителерсез».**

«Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:10

---

[1] Мәдинә халкының күпчелеген тәшкил иткән Әүс һәм Хәзрәҗ кабиләләре арасында йөз дә егерме елга сузылган күптәнге дошманлык һәм бәрелешләр була. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һиҗрәте белән Ислам шәрәфенә ирешкән бу кешеләр бөтен дошманлыкларны бер читкә ташлап кардәш булалар. Берникадәр вакыттан соң беркөн бу ике кабиләнең ике кешесе, үз кабиләләреннән чыккан кайбер дәрәҗәле сәхабәләрнең сыйфатларын санап, бер-берләренә мактанышалар һәм сүз иярә сүз чыгып, берсен-берсе өстенрәк чыгара башлый. Мөселманнарга карата бик зур дошманлык хисләре кичерүче карт кына бер яһүди, бу форсаттан файдаланып, янында утырган яшь кенә бер егеткә: «Бар, шуларның яннарына барып утыр да, аларга элекке дошманлыкларын исләренә төшерәчәк шушы шигырьне укы!» – дип, аңа җаһилият дәверендә узган сугышларда җиңгән тарафны данлап язылган шигырьләрне укырга куша. Шулай итеп, бер-берләренә карата ачулана башлаган бу кешеләр, үз кабиләләренә дә хәбәр итеп, эшне зурга җибәрәләр һәм, нәтиҗәдә, ике зур кабилә кораллланып, бер-берсе каршына киләләр. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хәлдән хәбәр алыр-алмас алар янына ашыга, киеренкелекне тәмам юк итә, эшне җайга сала. Менә 100-103 нче аяте кәримәләр бу вакыйга сәбәпле иңгәннәр.

Сәламне бирү, сәламне кайтару мөселманнар арасында бик саваплы эш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер бәдәви гарәбе килеп берничә сорау биргән. Иман дәрәҗәсенең иң камил рәвешенә ирешү юлын да сораган. Расүлебез галәйһиссәлам: «Син үз холкыңны яхшырт һәм иман дәрәҗәсенең, ягъни тәкъвалыкның иң олы дәрәҗәсенә ирешерсең», – дип әйткән. Күркәм холыкка ирешер өчен бердәм булып, Аллаһы яраткан затларны ярату зарурдыр. Кызганыч ки, әллә дөнья малына алданып, әллә сәлам бирүнең мөһимлеген аңламыйча, намаз тәмамлануга мәчетләрдән чыгып чабарга тырышабыз. Кардәшләргә сәлам биреп чыксак, аларның хәл-әхвәлләрен сорашсак, үзебезнең күңелдә мәхәббәт булдырыр, өстәвенә кардәшебезнең кәефен күтәрер идек, ә бу инде үзе бер зур әҗер. Якын кешеләргә берничә минут вакытны багышлаудан зарар булмый. Бәлки шушы кешеләрнең берсе белән арабызда салкын мөнәсәбәт булып, аның белән бу дөньяда соңгы тапкыр күрешүдер. Ә безнең арадагы салкынлык исә Кыямәт көненә кала, Аллаһы Үзе сакласын. Бергә кылынган догалар, бирелгән сәламнәр сәбәпле Аллаһы Раббыбыз безгә җәннәт әҗерләрен бирер. Инде мәчетләрдә исәнләшмибез икән, бүтән җирдә ничек сәламләшәбез инде без? Аллаһы Тәгаләне ярату хакында тәкърарлыйбыз, ә үзебез сәламгә дә җавап кайтармыйбыз. Үзебез мөэмин-мөселман саныннан булырга телибез, ә гади генә сыйфатларны булдырырга теләмибез. Алай була алмый! Без Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сөннәтен торгызып, арабызда мәхәббәт булдырырга тиешбез. Аллаһы юлында күп көч куючы гына олы дәрәҗәгә ия була. Җәннәтле булу өчен безнең бөтен мөмкинчелек бар, тик без боларны аз кулланабыз. Аллаһы коллары икәнебезне таныдык икән, әзрәк кенә булса да үзеңне төзәтү зарурдыр. Аллаһыны, Аның Расүлен яратып, алар яраткан эшләрне эшләмәү, бу яратуның никадәр зәгыйфь икәнен күрсәтә. Аллаһы Раббыбыз безгә бу дөньяда да һәм Ахирәттә дә кардәшлек, мәрхәмәтлелек сый-

фатларын бирсә иде, ике дөньяда да җәннәт әһелләре санынннан булуны насыйп кылса иде. Әәмин.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмче,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*12 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Тәсаввуф

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, сәламе вә бәрәкәте булсын!

Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: «Бервакыт без Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында утырганда, көтмәгәндә, безнең янга күз явын алырдай ак киемле, кап-кара чәчле кеше килде. Аның кыяфәтенә караганда, мосафир дип әйтеп булмый иде, без беребез дә аны танымадык. Ул, тезләре Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнекенә тиеп торырлык итеп, аның каршына утырды, кулларын үз тезләренә куйды һәм: «Әй Мөхәммәд, миңа Ислам турында сөйлә!» – диде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ислам – «Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның Илчесе» дип әйтү, намаз уку, зәкят түләү, Рамазанда ураза тоту, булдыра алсаң Йортка хаж кылу ул», – дип җавап бирде. Әлеге кеше: «Син дөрес әйттең», – диде. Без аның Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сорау бирүенә һәм үзе аның сүзләрен раславына аптырадык. Аннары ул: «Хәзер миңа иман

турында сөйлә!» – дип әйтте. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иман – Аллаһыга, Аның фәрештәләренә, Аның язуларына, Аның пәйгамбәрләренә, соңгы Көнгә, яхшының да, начарның да алдан билгеләнүенә ышануың ул», – диде. Теге кеше тагын: «Син дөрес әйттең», – диде. Аннары: «Миңа ихсан турында сөйлә!» – диде. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ихсан – Аллаһыны күрмәсәң дә, Аны күргән кебек гыйбадәт кылу ул. Син Аны күрмәсәң дә, Ул һичшиксез сине күрә», – дип җавап бирде.

Хәдис шәрифтән билгеле булганча, динебез өч өлештән тора. Беренчесе – иман, икенчесе – ислам, өченчесе – ихсан. Иман – ул Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китаплары, расүлләренә, Кыямәт көненә, кадәргә (тәкъдиргә) ышанудан гыйбарәт. Ислам – ул бер сүз белән әйткәндә, Аллаһы Тәгаләдән килгән әмерләрне җиренә җиткереп башкару: намаз уку, зәкят түләү, Рамазан уразасын тоту, мөмкинлек булса, хаҗ кылу. Ихсан исә – ул бу гамәлләрне эчкерсез, чын күңелдән башкару. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихсан турында соралганда, ул: «Ихсан – ул Аллаһы Тәгаләне күргән төсле Аңа гыйбадәт кылу. Син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә», – дип җавап биргән.

Аллаһы Тәгалә безне бу дөньяда сынау өчен – кайсыбызның гамәлләре яхшырак булуын үзебез үк күрсен өчен җибәрде. Раббыбыз баштан Үзенә һәм Расүленә ышануны әмер итте. Аннары гыйбадәтләр йөкләде. Һәм шул гыйбадәтләрне ихласлылык белән башкаруыбызны әмер итте. Мәкальдә әйтелгәнчә: «Һәрбер урынның үзенә лаеклы сүзе бар (бөтен җирдә дә бер төрле сөйләшергә ярамый – олы кеше белән, яшь кеше белән, гаилә эчендә, чит ят кешеләр белән, һ.б.), һәм һәрбер фәннең дә үз галимнәре бар».

Ышану белән бәйле фән – ул «гакыйдә» фәне. Аллаһы Тәгаләгә, Аның расүлләренә, һәм башка нәрсәләргә ышанырга кирәк, ә нәрсәгә ышану ярамый икәнлеген гакыйдә фәне галимнәреннән өйрәнәбез.

Намаз, һәм башка гыйбадәтләр белән бәйле булган мәгълүматны фикһ галимнәреннән алабыз. Ихласлылык, эчкерсезлек, һәм күңел белән бәйле башка нәрсәләрне исә без Ихсан фәне, яки Тәсаввуф гыйлеме белән шөгыльләнүчеләрдән алырга тиешбез. Бу темага тулырак тукталып алыйк.

Тәсаввуф – ул Аллаһының Илчесе чорыннан ук башланган рухи гореф-гадәт. Тәсаввуф – йөрәкне һәлакәтле булган көнчелек, саранлык, күрсәтү кебек сыйфатлардан чистарту, шулай ук бер Аллаһыга табынуда эчкерсезлекне белдерү ул. Суфыйлар дип, шушы Ислам фәне ярдәмендә Аллаһыдан куркып, һәрдаим гыйбадәттә булучы кешеләрне атыйлар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә ихласлылык белән гыйбадәт кылуны әмер итте:

إِنَّا أَنزَلْنَا إِلَيْكَ الْكِتَابَ بِالْحَقِّ فَاعْبُدِ اللَّهَ مُخْلِصًا لَّهُ الدِّينَ ﴿٢﴾

**«Ий, Мөхәммәд, Без сиңа Коръәнне хаклык белән иңдердек, динне ширек вә риядан пакьләп, Аллаһының Үзенә генә ихлас гыйбадәт кыл».**

«Зөмәра / Халык төркеме», 39:2

Аллаһы Тәгаләгә шөкер, безнең җирлегебездә дә үз тормышларын бу фәнгә бирүчеләр булган. Революциягә хәтле яшәгән күп кенә ишаннарыбыз билгеле. Аларның иң абруйлыларыннан берсе – Зәйнулла Расулев (1833—1917). Галимҗан Баруди хәзрәтләре аны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылышына да чакыра. Күренекле татар галимнәре барысы да диярлек ишаннарга мөрәҗәгать итеп, ихласлыкларын арттырганнар.

Халкыбыз тарихында хәтта суфыйчылык әдәбияты дигән ара да бар. Шагыйрь, дин гыйлеме белгече Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), мәгърифәтче, ислам галиме Габденнасыйр Курсави (1776-1812), олуг галимебез, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани – суфыйчылыкның күренекле вәкилләре булып торалар.

Әнәс радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «(Бервакыт) Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре турында (аңа ошамаган) нәрсәдер белгәч, аларга вәгазь белән мөрәҗәгать итеп: «Миңа җәһәннәм һәм җәннәт күрсәтелде, аңарчы беркайчан да ул көндәгедән дә яхшырак һәм яманрак әйбер күргәнем булмады! Әгәр дә сез мин белгәнне белсәгез, әлбәттә, аз көләр һәм күп елар идегез!» Бу – Аллаһы Илчесенең сәхабәләре өчен иң авыр көн булды, алар башларын каплап, авызларын да ача алмыйча еларга тотындылар.

Кадерле җәмәгать, без сезнең белән соңгы тапкыр кайчан еладык соң? Коръән укыганда елыйбызмы? Намаз вакытында елыйбызмы? Зикер кылганда күңелләр туламы? Аллаһы Тәгалә һәрберебезне дә ихлас коллардан кылса иде.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Булат хәзрәт Мөбарәков,*

*ТҖ МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе*

*19 июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать юлы

Барлык хәмде вә сәна, олуглау фәкать Раббыбыз бер Аллаһыга гына хастыр! Күңел түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә генә ирешеп торса иде.

Хөрмәтле кардәшләр, мәгълүм ки, бүгенге көндә Рәсәйдә мәгълүмат чаралары аша безгә еш кына «теракт», «терроризм» хакында бик еш ишетергә туры килә. Никадәр генә кызганыч яңгырамасын, бу күренеш безнең мохиттә дә еш очрый башлады. Аның никадәр коточкыч кайгы-хәсрәт алып килүен бөтен илебез халкы тоя. Бөек Ватаныбызның һәр кешесе бу явызлык корбаннары һәм аларның туганнары белән бергә кайгыра. Ниндидер тышкы яки эчке көчләр бөтен галәмдәге кансызлык һәм ерткычлык аша халкыбызны куркытырга, шуның белән бергә үз тормыш теориясен һәм фәлсәфәсен көчләп тагарга тели.

Явызлык аша игелек кылып булмаган кебек, бу иблис-шәйтаннар белән Кыямәт көнендә котылу табып булмаячак. Һәр кешенең тормышы бәһасез һәм аңа кул сузу зур гөнаһ булып санала. Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

مَن قَتَلَ نَفْسًا بِغَيْرِ نَفْسٍ أَوْ فَسَادٍ فِي الْأَرْضِ فَكَأَنَّمَا قَتَلَ النَّاسَ جَمِيعًا
وَمَنْ أَحْيَاهَا فَكَأَنَّمَا أَحْيَا النَّاسَ جَمِيعًا ۚ ﴿٣٢﴾

**«Берхаксыз вә сәбәпсез кеше үтерүче – бөтендөнья халкын үтерүче кебек була, ә кем бер җан иясен коткарса, бөтендөнья халкын коткарган кебек була».**

«Мәидә / Аш табыны», 5:32

Бер гаепсез кешеләрне үтерү, куркыту һәм башка төрле карагруһчылык гамәлләре терроризм кабыгына төреп бирелә. Алар, бүгенге көндә иҗтимагый проблема буларак, каяндыр билгесезлектән килеп чыкмаган. Юк, алар «экстремизм» дип аталган озакка сузылган иҗтимагый процесс нәтиҗәсе булып тора. Ә ул теләсә кайсы җәмгыятьтә җиңел генә килеп чыгарга мөмкин. Ул кечкенә генә учак кебек, әмма үзе бик зур куркыныч учак та дөрләтеп җибәрә ала. Нәтиҗәдә, аннан чыккан янгын барысын да камап алып, юк итәргә мөмкин. Шуңа күрә дә мөселманнар өчен изге саналган Коръән китабында Аллаһы Тәгалә фетнә чыгаручыларны шелтәләргә кирәклеге турында болай дип әйтә:

إِنَّمَا السَّبِيلُ عَلَى الَّذِينَ يَظْلِمُونَ النَّاسَ وَيَبْغُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ ۚ أُولَٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٤٢﴾

**«Кешеләрне золымлап вә җир өстендә бер хаксыз начарлык кылып йөрүчеләрне шелтә кылыгыз. Аларга шушы эшләре өчен ачы газап булыр».**

«Шура / Киңәш», 42:42

Гади тел белән әйткәндә, экстремизм – ул кешеләрнең дин, аларның милләте, мәдәнияте арасында булган барлык ихтирам хисләрен юкка чыгара торган фетнә. Андый фетнә турында Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَالْفِتْنَةُ أَكْبَرُ مِنَ الْقَتْلِ ۗ ﴿٢١٧﴾

**«Фетнә кеше үтерүдән куркынычрак».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:217

Ягъни Аллаһы Тәгалә ачыктан-ачык фетнә чыгаручы экстремистның гөнаһлары тагын да куркынычрак хәлләргә китерергә мөмкинлеген әйтә. Вәзгыятьне катлауландыручы кешеләр кайда гына булмасын – рухи

өлкәдәме, милли өлкәдәме – шунда ук тавыш-гауга килеп чыга, фикерләр бәрелеше барлыкка килә. Аллаһы Тәгалә сакласын, сугышлар да кабынып китәргә мөмкин. Ә сугышларның никадәр коточкыч, куркыныч булуы һәм кайгы-хәсрәт алып килүе хакында артык сөйләргә дә кирәк түгел. Шуңа күрә, кеше тарафыннан китереп чыгарылган фетнәнең һәр гаиләгә кагылышы булуын аңлау тиешле.

Безгә – мөселманнарга – бигрәк тә тынычлыкны сакларга һәм бер-береңне яратырга кирәк, чөнки без «тынычлык» дип аталган динне җәмгыятькә тәкъдим итәбез. Ислам сүзенең гарәп телендәге тамыры «сәлам» сүзенә туры килә. Ул «тынычлык» дип тәрҗемә ителә. Мөселманнар, бер-берсен сәламләп, «әссәләмү галәйкүм» дип әйтә. Асылда ул «сезгә тынычлык һәм иминлек булсын» дигәнгә туры килә. Шуңа күрә безгә – дин тотучыларга, беренче чиратта, динебезнең ихласлылыгын сүз белән түгел, ә эш белән расларга кирәк. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә безгә болай дип боера:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ۚ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ ﴿٣٤﴾

**«Изгелек белән золымлык бер булмас. Начарлыкны яхшылык белән куыгыз һәм шулвакыт синең дошманың сиңа иң якын дус, туганың кебек булыр».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:34

Кадерле мөселман кардәшләребез! Экстремизмның шәйтан белән бәйле күренеш икәнлеген белеп торыгыз. Аның максаты – кешеләрне рухият юлыннан аерып алып, акылсызлык һәм сугыш юлына илтү. Иблис – күпкырлы, ул җиңел генә төрле дини фикерләр һәм доктриналар артына качарга мөмкин. Шәйтан бүгенге көндә Исламны да үз мәнфәгатьләрендә куллана, кешеләрнең күңелләренә үтеп керә. Дин тотучыларның

күңелләрендә фетнә уята, аларны экстремистик хәрәкәтләргә чакыра. Еш кына үз явызлыкларын мөселман кешесенең чакырулары аша тормышка ашыра.

Адәми шәйтаннар кешеләрне иң соңгы адымнарга этәрә. Алар үзләрен чын ислам тарафдары һәм аның идеалларын тормышка ашыру өчен көрәшүчеләр итеп күрсәтә. Мондый шартларда дөньяда Ислам дине турында һөҗүм итү (агрессия) дине буларак дөрес булмаган күзаллау барлыкка килә. Хәтта кайберәүләр, мөселманнар экстремизм һәм көч куллануны аклый, дип тә уйлый. Ә бу, үз чиратында, мөселманнарның традицион һәм тыныч мәдәниятенә яла ягу һәм ялгышлык булып тора.

Ихластан Аллаһы Тәгаләгә ышанучылар һәм Исламның барлык әркәннәрен үтәп яшәүчеләр, мөселманлык битлеге киеп, явызлык кылучыларны катгый кире кага һәм аларны кабул итми. Әгәр дә без хәзер сезнең белән экстремизмның төп төрләрен карап, аларны Коръән гореф-гадәтләре нигезендә тикшерсәк, аларның мөселман әхлагы белән бөтенләй дә капма-каршы икәнлеген һәм теләсә кайсы золымның катгый шелтәләнүен күрербез.

1. Этник экстремизм (бу очракта кешеләр үз милләтләрен генә – идеаль, ә башка милләтләрне кадерсез дип саный); Ислам моңа каршы килә, чөнки Аллаһы Тәгалә Үзе болай дип әйткән:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«И, кешеләр! Хаклыкта без сезне ир вә хатыннан бар кылдык. Сезнең арагыздан төрле халык һәм кабиләләрне бер-берсе белән танышып яшәсеннәр өчен булдырдык. Иң яхшыгыз – Раббыгыз каршында иң тәкъва булганыгыз».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

2. Дини экстремизм (бу очракта кешеләр үзләре тоткан дин кануннарын гына дөрес, ә башка диннәрне ялган дип саный); Ислам дини экстремизмга каршы чыга, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

قُولُوا آمَنَّا بِاللَّهِ وَمَا أُنزِلَ إِلَيْنَا وَمَا أُنزِلَ إِلَىٰ إِبْرَاهِيمَ وَإِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ وَالْأَسْبَاطِ وَمَا أُوتِيَ مُوسَىٰ وَعِيسَىٰ وَمَا أُوتِيَ النَّبِيُّونَ مِن رَّبِّهِمْ لَا نُفَرِّقُ بَيْنَ أَحَدٍ مِّنْهُمْ وَنَحْنُ لَهُ مُسْلِمُونَ ﴿١٣٦﴾

**«Әйт аларга: Без Аллаһыга вә безгә Аңардан ирешкән нәрсәләргә иман китердек. Шулай ук Ибраһимга, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка һәм аларның дәвамчыларына һәм шулай ук Раббылары тарафыннан Муса вә Гайсәгә ирешкәнгә ышанабыз. Алар арасында аерма кылмыйча бер Аңа гына үзебезне тапшырабыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:136

Шулай ук Ислам диненең толерантлыгын күрсәткән тагын бер аять:

لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ ۖ

**«Диндә көчләү юктыр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:256

3. Иҗтимагый (социаль) экстремизм (бу очракта кешеләр бер иҗтимагый катлау гына яшәргә хаклы, ә башкалары юк дип саный); Ислам кешеләрнең иҗтимагый катлауларга (байларга һәм ярлыларга, көчлеләргә һәм зәгыйфьләргә) бүленүенә каршы килә, чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Көчле мөселман Аллаһы каршында зәгыйфьрәгеннән хәерле вә сөеклерәктер. Әмма аларның икесенең дә яхшы яклары бар», – дип әйткән.

Бу проблемаларның барысы да бик түбәннән башланып китеп үсеш алган. Шуңа күрә без – мөселманнар – үзебезнең зур гаиләбездә бу йо-

гышлы чирне йоктырудан азат түгел. Еш кына кайбер кешеләр: «Дөньяда безнең милләт кенә иң яхшысы, ә бөтен проблемалар башка этнос кешеләре аркасында килеп чыккан, алар гаепле», – дип әйтә. Боларның барысы да кызганыч хәлләргә китерә, чөнки үз явызлыгы белән кая гына керсә дә, моның азагы яхшы булып бетми. Бу явызлыктан үзеңне һәм якыннарыңны саклар өчен, дин тотучылар гаиләләрендә, көнкүрештә, дуслары белән булганда да Коръән аятьләрен һәм Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрен аңлатырга тиешләр.

Без кешеләргә Исламның чын асылын, Пәйгамбәребезнең сүзләрен җиткерергә тиешбез. Алар һәр кеше аңларлык шушы хәдистә чагылыш таба: «Хаклыкта, Аллаһы Тәгалә барлык эштә дә изгелек кылуны гына ярата»[1].

Аллаһы Тәгалә ил-көнебезне, халкыбызны, милләттәшләребезне иблис фетнәсеннән һәм ул алып килергә мөмкин булган золымнан сакласын. Йә Раббым, без һәрвакыт бер-беребезне аңлап, дус һәм килешеп яшәсәк иде!

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Хәбир хәзрәт Ханов,*

*Ярдәм мәчете имам-хатыйбы*

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

*26 июнь вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Хәләллек ризыкка гына кагылмый

Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Хак Тәгаләгә дан-мактауларыбыз, мөэминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансызларны вә монафикъларны җәһәннәм белән кисәткән хак расүл Мөхәммәд сәлләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Бүгенге вәгазебез хәләл тормыш рәвеше хакында барыр.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешенең карынына харам керсә, 40 көн буе кылган догасы, укылган намазы кабул булмас», – дип әйткән.

Хәләл – ул рөхсәт ителгән, яраклы дигән сүз. Элек хәләл дигән сүзне ит белән генә бәйләп карыйлар иде. Хәзер исә аның мәгънәсе шактый киңәйде. Рәсәйдә бүген 20 миллионнан артык мөселман яши. Исламча яшәү рәвеше өчен тиешле шартлар кирәк. Хәләл – ул ризык кына түгел, ә эш (кәсеп), хезмәт хакы, сәламәтлек саклау (медицина ярдәме күрсәтү оешмалары), мәгариф, мөселман балалар бакчалары, сәяхәт итү, мөселманнар өчен бассейннар, матурлык салоннары, чәчтарашханәләр, кунакханәләр, косметика һәм кием-салым (мода) да. Соңгы вакытта исә «хәләл тормыш рәвеше» дигән гыйбарә дә барлыкка килде.

Коръәндә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

حُرِّمَتْ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةُ وَالدَّمُ وَلَحْمُ الْخِنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللَّهِ بِهِ وَالْمُنْخَنِقَةُ
وَالْمَوْقُوذَةُ وَالْمُتَرَدِّيَةُ وَالنَّطِيحَةُ وَمَا أَكَلَ السَّبُعُ إِلَّا مَا ذَكَّيْتُمْ وَمَا ذُبِحَ عَلَى
النُّصُبِ وَأَن تَسْتَقْسِمُوا بِالْأَزْلَامِ ۚ ذَٰلِكُمْ فِسْقٌ ۗ الْيَوْمَ يَئِسَ الَّذِينَ كَفَرُوا

مِن دِينِكُمْ فَلَا تَخْشَوْهُمْ وَاخْشَوْنِ ۚ الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ
عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا ۚ فَمَنِ اضْطُرَّ فِي مَخْمَصَةٍ غَيْرَ
مُتَجَانِفٍ لِّإِثْمٍ ۙ فَإِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣﴾

**«(Чалмыйча җаны чыккан) Үләксә, (хайванны чалган чакта агып чыккан) кан, дуңгыз ите, Аллаһыдан башкасы өчен (яисә, җаны чыкканчы өлгереп, Ислам кушканча) чалынганнардан тыш, буылган (һәм үлгән), (таш, агач кебек әйберләр белән) кыйналган (һәм үлгән), (биектән яки кое кебек бер җиргә) егылып төшкән (һәм үлгән), (башка бер хайван тарафыннан) сөзелгән (һәм үлгән), ерткыч хайван ашап, (җаны чыкканчы өлгереп) чалынганнан тыш, (табыныла торган) тораташлар (һәм потлар өчен корбан китерелә торган урыннарда) бугазланганнар һәм фал уклары белән багучылык итүегез сезгә харам кылынды. Бу – (харамнардан файдалануыгыз) бер гөнаһкярлык.**

«Мәидә / Аш табыны», 5:3

Шулай итеп, мөселманнарга үләксә, кан, дуңгыз ите, Аллаһы исеме белән суелмаган мал-туар, буып яки башка хайван тарафыннан үтерелгән хайван, югары электр көчәнеше, каты сугу яки биектән егылып төшү сәбәпле үлгән хайван, ерткыч хайваннар һәм ерткыч кошлар ите харам.

Харам дип бары тик ярамаган ит ризыклары гына түгел, ә гомумән алганда, кеше организмына зыян сала торган барлык төр ризыкларны да атарга кирәк, чөнки хәзерге заман галимнәре дуңгыз итенең һәм мөселманча чалынмаган итләрнең составында зыянлы матдәләр барлыгын фәнни яктан да ачыкладылар. Шуңа күрә хәләл дигәч тә, без кеше сәламәтлегенә зыян салмый торган барлык төр ризыкларны да күз алдында тотарга тиеш.

Бер гыйлем иясе: «Без нәрсә ашыйбыз, шуны тәшкил итәбез», – дип әйткән. Харам ризык ашап, без үзебезнең саулыкка гына түгел, балаларыбыз сәламәтлегенә дә зыян салабыз, ягъни нәселебез тамырына үзебез үк балта белән чабабыз.

Харам ризык иман дигән үсентенең тамырын кисә. Тамыры зәгыйфь үсемлек үсә алмаган кебек, әгәр балабызга харам ризыклар ашатып үстерсәк, аның да иманы зәгыйфь кала. Харам кергән карын авыру була, йөкле чакта харам ашаган ананың баласына начар тәэсир күчә. Шуның өчен дә гаилә коргач, ир кешенең иң беренче бурычы – гаиләсен хәләл ризык белән тәэмин итү. Хәләл ризык ашау – Аллаһы кушканны үтәү, ягъни гыйбадәткә тиң гамәл. Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَأَن لَّيْسَ لِلْإِنسَانِ إِلَّا مَا سَعَىٰ ﴿٣٩﴾

**«Дәхи кешегә һич нәрсә юктыр, мәгәр үзе кәсеп иткән нәрсәсе генәдер».**

«Нәҗем / Йолдыз», 53:39

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Иң яхшы кәсеп – хәләл сәүдә яки үз кулың белән эшләп тапкан мал», – дип әйткән. Мөселман буларак, акча эшләүнең хәләл ысулларын куллану һәм харамнан тыелу бик мөһим. Хәзерге дөньяда кешеләргә үзләрен харамнан саклап калу бик авыр, әмма бу мөмкин хәл. Яраткан пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам һәм аның сәхабәләре әлеге мәсьәләдә безнең өчен яхшы үрнәк булып тора. Аллаһының Илчесе болай дип әйткән: «Әгәр кеше хәләл ысул белән табыш ала икән, бу хәйрия һәм шәфкатьлелек гамәле буларак саналачак».

Үзенең гаиләсен тәэмин итүче һәркем рөхсәт ителгән чаралар гына эзләргә тиеш, чөнки нәкъ менә шул чаралар, ягъни ризыкның хәләл яки харам булуы безнең гыйбадәтебезгә һәм Аллаһы юлындагы тырышлыгыбызга тәэсир ясый. Рөхсәт ителмәгән кәсепләргә риба, ришвәт, ур-

лау, ятимнәр малын үзләштерү, сату-алуда гаделсезлек, килешүләрне (вәгъдәләрне) үтәмәү, мөселман кардәшләренә ярдәм итүдә акча эшләү, (чөнки мөселманнар бер-берләренә Аллаһы ризалыгы өчен ярдәмләшеп яшәргә тиешләр), сыра, исерткеч эчемлекләр, тәмәке сатыла торган кибетләр, бозыклыклар тарала торган оешмалар ачу өчен биналарын арендага бирү һ.б. керә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَإِن لَّمْ تَفْعَلُوا فَأْذَنُوا بِحَرْبٍ مِّنَ اللَّهِ وَرَسُولِهِ ۖ وَإِن تُبْتُمْ فَلَكُمْ رُءُوسُ أَمْوَالِكُمْ لَا تَظْلِمُونَ وَلَا تُظْلَمُونَ ﴿٢٧٩﴾

**«Аллаһы риба белән кергән малны һәлак итә, ә садакасы бирелгән малны арттыра. Рибаны хәләл диюче кәферне Аллаһы сөйми»,**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:276

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَوْفُوا بِالْعُقُودِ ۚ أُحِلَّتْ لَكُم بَهِيمَةُ الْأَنْعَامِ إِلَّا مَا يُتْلَىٰ عَلَيْكُمْ غَيْرَ مُحِلِّي الصَّيْدِ وَأَنتُمْ حُرُمٌ ۗ إِنَّ اللَّهَ يَحْكُمُ مَا يُرِيدُ ﴿١﴾

**«И, мөэминнәр! Гаһедләрегезне, вәгъдәләрегезне үтәгез! (Гаһед өч төрле: берсе – Аллаһы һәркемнән Коръән белән гамәл кылырсыз дип гаһед алды, икенчесе – Аллаһы исеме илә әйтелгән нәзерләр, антлар, өченчесе – мөэминнәрнең үзара куешкан вәгъдәләре)...»,**

«Мәидә / Аш табыны», 5:1

وَأَوْفُوا الْكَيْلَ إِذَا كِلْتُمْ وَزِنُوا بِالْقِسْطَاسِ الْمُسْتَقِيمِ ۚ ذَٰلِكَ خَيْرٌ وَأَحْسَنُ تَأْوِيلًا ﴿٣٥﴾

**«Дәхи үлчәгәндә үлчәүләрегез дөрес булсын, тигез үлчәгез вә дөрес үлчи торган гадел мизаннар белән үлчәгез! Гадел үлчәсәгез, үзегезгә хәерледер вә ахыры да күркәм булыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:35

Гөнаһлы эшләрдә арадашчы һәм катнашучы булган кешеләр, киләчәк Хисап (Кыямәт) көнендә моның өчен җавап бирергә туры киләчәклеге турында онытмасалар иде.

Хәләллек мәсьәләсе турында сөйләшкәндә тыйб (медицина) өлкәсен карап үтик. Тыюлы матдәләр (продуктлар) белән дәваланырга яки үз эчендә тыелган матдәләр булган дару чараларын кулланырга мөмкинме? Әлеге сорауга җавапны без Изге Коръәндә таба алабыз, анда Аллаһы Тәгалә болай дип боерды:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾

**«И, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһыдан башка мәхлүкъларга табыну эшләре, шулай ук ырымлау – багучылык эшләре харам, шәйтан эшләреннән булган пычрак эшләр, һәлак булудан котылу өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять котылырсыз – өстенлек табарсыз».**

«Мәидә / Аш табыны», 5:90

Бер хәдистә болай диелә: «Аллаһы Илчесе агуны һәм хәләл булмаган даруларны харам кылды»[1].

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Барысы да Аллаһы Тәгаләдән булганына шик юк. Ул авырулар (чирләр) һәм аларга шифа итеп һәрберсеннән дару иңдерде. Шуңа күрә,

[1] Имам Тирмизинең хәдисләр җыентыгыннан, 2045.

Аллаһы коллары, дәваланыгыз, тик дәвалануда тыелган әйберләрне кулланмагыз»[1].

Хәнәфи мәзһәбендә танылган «Әл-Һидәя» китабында түбәндәге юллар язылган: «Исерткеч эчемлекләрне һәм башка тыелган әйберләрне кулланудан баш тарту зарур, чөнки харам булган нәрсәләрне дәвалануда да куллану рөхсәт ителми. Тик бу аның дәвалау үзлекләре турында билгеле булмаса гына. Әгәр аның дәвалау үзлегенә ия булуы билгеле һәм шул ук вакытта башка рөхсәт ителгән чаралар юк икән, ул дәвалау максатларында файдалану өчен рөхсәт ителгән булып санала».

Кеше косметик продукцияне тире, тешләре, чәче һәм бөтен организмы сәламәтлеген һәм тән пакьлеген саклау өчен, шулай ук тышкы кыяфәтне үзгәртү өчен куллана. Моңа көнкүреш кирәк-яраклары (шампунь, гельләр, кремнар, лосьоннар, теш пасталары һ.б.) һәм шулай ук бизәнү өчен кулланыла торган башка чаралар да керә.

Косметик продукция төп чималдан һәм төрле кушылмалардан (буягычлар, ароматизаторлар, куерткычлар һ.б.) җитештерелә.

«Хәләл» стандарты буенча косметик продукциянең составы һәм сыйфаты, шулай ук аны җитештерүнең барлык ысуллары диндә рөхсәт ителгәнчә булырга тиеш.

Чисталык һәм гигиена – Ислам диненең иң мөһим шартларының берсе. Шуңа күрә косметик продукция җитештерүдә иң мөһиме – кеше сәламәтлеге өчен куркыныч янамау һәм җитештерүнең һәр этабында продукциянең гигиена нормаларына туры килүе.

Мөселманнарга бишектән ләхеткә кадәр хәләл тормыш мөмкинлекләрен тәэмин итү – мәгарифне үстерү һәм дини гыйлем алуда ярдәм күрсәтү өчен, беренче чиратта, эшне хәләл шартлары булган балалар бакчалары, мәктәпләр төзүдән башларга кирәк. Сабыйларга хәләл

---

[1] Әбү Давыд (3874), Әт-Табәрани, Әл-Кәбир (24/254, №249), Әл-Бәйһакый, Әл-Кубра (10/5).

бакчалар бар инде, әлхәмдүлилләһ, хәзер хәләл мәктәпләр төзү өстендә эшлисе бар. Дәүләт катнашыннан башка әлеге процесс, әлбәттә, мөмкин түгел.

Хәләл юл белән сәяхәт кылу һәм хәләл булган шифаханәләр калганнардан нәрсәләре белән аерылып тора соң? Әлбәттә шартлары, дарулары, ашамлыклары хәләл булуы һ.б. белән.

Кием-салымның да хәләл булуы шарт. Ни өчен дигәндә ул киемнең хәләл акчага сатып алынуы, гаурәтләрне каплавы, хәләл чималдан ясалуы (дуңгыз, яисә башка тыелган хайван тиресеннән булмавы), тыелган сурәтләр ясалган булмавы бик мөһим.

Бер хәдистә болай дип тапшырыла: «Сәгъд бине Әби Ваккас радыяллаһу ганһе берзаман Пәйгамбәребезгә: «Йә Аллаһының Илчесе! Үтенәм, Аллаһы Тәгаләдән минем барча догаларымны кабул итүен сорасаңчы», – дип мөрәҗәгать итә. Җавап итеп Расүлебез болай дип әйтә: «Догаларыгыз, мөрәҗәгатегез Аллаһыга ирешсен дисәгез, хәләл ризык белән туклангыгыз! Күпчелек харам ризык ашый, харам кием кия. Һәм шуннан соң кулларын күтәреп дога кыла. Андый догалар ничек кабул булсыннар ди?»

Тагын бер хәдистә: «Әгәр ун дирһәмлек киемнең бер генә дирһәме булса да гаделсез (харам) рәвештә табылган булса, шул киемне киеп укылган намаз кабул түгел»[1], – дип әйтелә.

Коръәндә ачык әйтелгән: «Аллаһы сезгә Үзенең тыйганнары турында төшендерде бит». Галәмне юктан бар иткән Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәү, беренче чиратта, җәмгыятьне савыктыру юлында үтәлергә тиеш. Аллаһы Тәгалә зарар китерә торган нәрсәләрне тыйган (бу турыда безне Бар кылучыдан да яхшырак белүче юк). Коръәни Кәримдә яки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтендә җавап таба алмаслык сораулар юк, шуңа күрә без һәрбер эш-гамәлләребездә, шәригать

1 Имам Әхмәднең хәдисләр җыентыгыннан.

кануннарына таянып, дөрес юлны сайлый һәм Аллаһы Тәгалә күрсәткән дөрес юлдан тайпылмыйча «хәләл»не таба алабыз.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты*

*3 июль вәгазе,*
*Зөлкагъдә аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Туганлык җепләре

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا ﴿١﴾

**«И, кешеләр! Сезне бер җаннан (Адәмнән) яраткан, аның бер кисәгеннән (булган сул кабыргасының иң астыннан Хәвва исемле) ишен яраткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халык кылып (җиһанга) тараткан Раббыгыздан, Аның исеме белән бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан (Аңа каршы баш күтәрүдән) һәм туганлык җепләреннән (аларның өзелүеннән) куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – сезне Күзәтүче».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә бу аятьтә берничә әйбергә басым ясый, аерым алганда, кеше бары Аллаһыдан гына куркырга һәм туган-

лык җепләрен сакларга тиеш. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «Ән-Нисә» сүрәсен ике төрле боерыктан башлап, туганлык җепләрен саклау әмерен бик югары күтәрде. Ни өчен? Кешенең бик көчсез зат икәнен белгәнгә күрә. Мәсәлән, мирас бүлешкәндә талашып, кычкырышып беткән туганнар азмы? Яшь бара-бара бер-берсен оныта башлаган туганнар азмы? Юк, җәмәгать! Ә бит берәр авырлык килгәндә иң беренче булып туганнарга чабабыз, ярдәмне алардан өмет итәбез. Нинди генә дуслар, танышлар булмасын, туганнар аларга караганда якынрак. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

وَأُولُو الْأَرْحَامِ بَعْضُهُمْ أَوْلَىٰ بِبَعْضٍ فِي كِتَابِ اللَّهِ ۗ ﴿٧٥﴾

**«Араларында кардәшлек якынлыгы булган кешеләр Аллаһы хөкемендә бер-берсенә варислардыр».**

«Әнфәл / Табыш», 8:75

Ягъни мөселман – мөселманга кардәш. Әмма кан кардәшең, үз туганың аларга караганда да якынрак икән. Шуңа күрә мөселман кешесенең намаз уку, ураза тоту, әти-әнигә игелекле булу кебек вазифалардан тыш тагын бер вазифасы – туганлык җепләрен саклау, аларны өзмәү. Моны Аллаһы Тәгалә Үзе боера. Шулай ук Пәйгамбәребез дә: «Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә иман китергән кеше туганлык мөнәсәбәтләрен сакласын», – дип әйтә.

Кемнәр соң безнең якын туганнарыбыз? Иң якыннары – әтиләребез, әниләребез, бабайларыбыз, әбиләребез, балаларыбыз, оныкларыбыз һәм оныкчыкларыбыз. Аннан соң якындагы туганнар, апа-сеңелләр һәм аларның балалары, аннан соң әти-әниләр буенча абыйларыбыз һәм апаларыбыз, аларның балалары, аннары абыйлары һәм апалары, аналар нәселе буенча апалары һәм аларның балалары һ.б. Моның шулай икәнен Пәйгамбәребез белән булган түбәндәге вакыйга да раслый: «Бервакыт бер кеше пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән:

«Аллаһының Илчесе, мин кемгә карата иң зур ихтирам, хөрмәт күрсәтергә тиеш?» – дип сорагач, ул: «Әниеңә», – дип җавап бирә. Мондый сорау тагын ике тапкыр кабатлана. Инде шушы кеше дүртенче тапкыр да шулай дип сорагач, Расүлебез галәйһиссәлам: «Аннары әтиеңә, аннан якынрак булганнан башлап туганнарыңа (хөрмәт күрсәтергә тиеш)»[1], – дип җавап кайтара.

Туганлык җепләрен өзгән очрак өчен кодси хәдистә болай дип әйтелә: «Мин – Аллаһы, һәм Мин – Мәрхәмәтле һәм Мин туганлык бағланышларын төзедем, аларга Иминлек исеменнән исем бирдем, һәм берәү ул араларны саклый икән, Минем белән элемтәне саклый, ә кем аларны өзә, Минем белән дә элемтәне өзә»[2].

Туганнар белән элемтә көчле булырга тиеш дидек. Әмма бүгенге көндә безнең арада коры кешеләр дә юк түгел. Алар өчен туганнар да, дуслар да, бу дөньяда табыш алу ысулы кебек кенә кабул ителәләр. Әмма туганнар белән элемтә ниндидер килешү нигезендә булырга тиеш түгел. Туганнарны якын итүнең күп ысуллары бар, мәсәлән: кеше үз туганнарын күрергә, аларга бүләкләр бирергә, аларның эшләре һәм проблемалары белән кызыксынырга, алар арасыннан ярлыларга ярдәм итәргә, ягымлы һәм мәрхәмәтле мөнәсәбәтләрне сакларга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә тиеш. Шулай ук аларны кунакка чакырырга, аларга кунакчыллык күрсәтергә, уңышларына сөенергә, кайгы-хәсрәтләренә борчылырга, алар өчен Аллаһы Тәгаләдән игелек сорарга кирәк. Кеше аларга карата көнчелек хисе тоярга тиеш түгел, аның йөрәге һәрвакыт ачык булырга һәм аларга берниндй начарлык эшләмәскә тиеш. Әгәр алар чакырсалар, чакыруга җавап бирергә һәм алар авырганда аларның хәлен белергә кирәк. Шулай ук кардәш-ыруларны Исламга чакыру һәм аларны туры юлга өндәү һәм харамнардан кисәтү зур әһәмияткә ия. Ибне Әбү Хәмзә рахимәһуллаһ:

1 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

«Кайвакыт туганлык багланышларын тоту акча ярдәмендә, ә кайвакыт ярдәм кулы сузу аша була», – дип әйткән.

Шунысы да мөһим: туганлык җепләрен саклау – сиңа карата яхшы мөгамәләдә булган туганың белән генә түгел, ә синең белән araларны өзгән туганыңа карата булган мөнәсәбәттә дә нык булырга тиеш. Әгәр берәүгә туганы шалтыратмый, аны искә алмый, хәлләрен белешми, игътибар күрсәтми икән, ул кеше үзе икесе арасында яхшы мөнәсәбәтләрне саклауда өлешен кертергә тиешле. Хәтта аңа карата явызлык кылсалар да, туганнар – мөселманнар булмаса да, Аллаһы Тәгалә хакына сабырлык сорарга һәм гафу үтенергә кирәк. Хисап тоту көнендә һәркем үзенең кылган гамәлләре өчен генә үч алыр: игелекле гамәл кылучыга әҗер чыгар, яманлык кылучыларга һәм залимнәргә җәза бирелер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам түбәндәге сүзләрне әйткән: «Сиңа яхшы мөнәсәбәттә булган туганыңа игелек белән җавап бирүең – әле аңа карата булган туганлык бурычыңны үтәми, ә синең белән мөнәсәбәтен өзүенә карамастан, ул туганыңа яхшы мөнәсәбәттә булуың – туганлык бурычыңны үтәвеңнән була».

Халкыбызда туганнар хакында мәкаль-әйтемнәр дә шактый, мәсәлән: «Тату туганнар таштан койма корганнар», «Туган бар җирдә ярдәм бар».

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَإِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَيَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ وَالْبَغْيِ ۚ ﴿٩٠﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы (һәрнәрсәне аңлатыр өчен иңдергән китабында) гадел булырга, изгелек кылырга һәм (бигрәк тә) якын туганнарга (мохтаҗ булган нәрсәләрен) бирергә (һәм туганлык җепләрен ныгытуны) әмер итә».**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:90

Мөгаен, һәркем үз гомерендә якын туганнарыннан башка берәүнең дә аңа ярдәм кулы сузмаячагына инангандыр. Шуңа күрә балаларны балалар йортларында, картларны картлар һәм инвалидлар йортларында калдыру модасын онытырга кирәк. Туганлык багланышларының өзелүе – зур гөнаһларның берсе. Изге Коръән аятьләрен һәм Пәйгамбәребез хәдисләрен түбәндәрәк китерәчәкбез.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

**«(И, коллар!) Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, (бертуганнар һәм агалар кебек) якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, (нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән) якын күршегә, (нәселдәшлеге яки өе) ерак күршегә, (ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек) янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә (коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә) игелек кылыгыз. Һичшиксез, Аллаһы тәкәббер (булганы өчен туган, кардәш һәм күршеләренә карата яхшы мөнәсәбәттә тормаган) һәм (өстенлекләрен санаган) мактанчык кешеләрне сөйми».**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Аятьтән күренгәнчә, кан кардәшләребез белән генә түгел, дин тотуларына яки тотмауларына карамыйча, туганнарыбыз, күршеләребез, дусларыбыз һәм хезмәттәшләребез белән дә мөнәсәбәтләрне ныгытырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт

үзенең сәхабәләренең хәлләре белән кызыксына, аларны кайгыртып тора иде. Элекке заманнарда кешеләр дуслары янына килү өчен чүлне кичкәннәр. Бүген исә бу мәсьәлә күпкә җиңеләйтелгән: вакыт булмаса да, кеше белән теләсә кайсы илдә, теләсә кайсы вакытта сөйләшергә мөмкин һәм сөйләшергә генә түгел, үз телефоныңның экраннары аша да күреп аралашырга була.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «И, мөселманнар! Туганлык бәйләнешләрен саклагыз, бу – тормышны озынайта һәм ризыкны арттыра», – дип әйткән. Шушы изге гамәлне барыбыз да эшләргә тырышсак иде.

* * *

Фодаил бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*
*Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

# Фәтвалар

# Ислам динендә пластика операцияләре рөхсәт ителәме?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм. Минем бер иренем икенчесенә караганда зуррак. Шул сәбәпле үземне уңайсыз хис итәм һәм, миңа калса, бу минем иремә дә ошамый, гәрчә ул бу хакта миңа ачыктан-ачык әйтмәсә дә. Башка бернәрсәгә дә кагылмыйча, миңа иренемнең формасын төзәтү өчен операция ясатырга ярыймы?

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Әйе, сез иреннәрне бер үк размерда итеп, аларның формасын төзәттерә аласыз.

Пластика операцияләре мәсьәләсендә гомуми кагыйдә түбәндәгечә: әгәр мондый операция тышкы кыяфәт җитешсезлеген (тумыштан булган яки яшәү дәверендә барлыкка килгән җитешсезлекне) бетерү өчен эшләнсә, бу рөхсәт ителә.

Әгәр дә операция болай да җитешсезлеге булмаган кыяфәтне төзәтү яки бизәү өчен эшләнсә, бу Аллаһы яраткан, бар кылган нәрсәне, ягъни кешенең табигыйлеген үзгәртү дип санала һәм моны эшләү тыела.

Бу мәсьәләдә нигез булып, тумыштан килгән җитешсезлекне бетерүнең рөхсәт ителгәнлеге турында, хәнәфи мәзһәбе фәтвасы тора. «Фәтава әл-Һиндийә» китабында болай дип әйтелгән:

«Әгәр кем дә булса артык бармагын кисеп алырга яки башка нәрсәне [тумыштан килгән җитешсезлекне төзәтергә] теләсә, Нөсәер рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Әгәр мондый гамәлләрдән соң болай эшләүчеләр еш үлсә, моны эшләргә ярамый, ә, киресенчә, ешрак уңай тәмамланса – болай эшләргә мөмкин» (5/360).

Мөфти Мөхәммәд Такый Усмани «Тәкъмилә Фәтх әл-мүлхим» китабында болай дип ачыклык кертә: «Артык бармакны һәм шуңа охшаш башка физик җитешсезлекне бетерүгә килгәндә, бу Аллаһы Тәгалә бар

кылган әйберләрне үзгәртү дип саналмый, бәлки җитешсезлекне бетерү яки авыруны дәвалау дип атала» (5/116).

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

## Мосафирмы, юкмы?

**Сорау.** Әссәләмү галәйкүм, хәзрәт. Мосафир үзен сәфәрдә 14 көннән дә азрак булам дип ниятләп чыгып китеп, сәфәре инде 17 нче көн дәвам итсә, бу кеше өч көннән өенә кайтасын төгәл белә, аңа намазларын кыскартып укыргамы?

**Җавап.** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Сезнең очракта, мосафир намазларын кыскартуын дәвам итә, чөнки ул сәфәр халәтендә 15 яки аннан да күбрәк тәүлеккә каласын белмәгән. Димәк, аның нияте тулысынча формалашып җитмәгән булган.

Мондый очракларда, мосафирның теге яки бу җирлектәге сәфәр көннәре, өйгә кайтып китү вакытын төгәл белгәннән соң санала башлый.

Югарыда телгә алынган урында, никадәр вакыт яшәвенә карамастан, ул биредә өч көнгә каласын төгәл хәл иткән – менә бу аның мосафирмы-юкмы икәнен билгеләүдә хәлиткеч фактор булып тора да инде.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм, хәзрәт. Намаз вакытында көлеп җибәрүдән тәһарәт бозыламы?

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Әлеге сорауга җавап биргәнче, төгәлрәк булу һәм аңлаешсызлыклардан котылу өчен, «көлү» төшенчәсе белән бәйле кайбер күренешләргә ачыклык кертергә кирәк.

Шартлы рәвештә, көлүне, намазга йогынты ясау күзлегеннән караганда, өч төргә бүләргә мөмкин:

1. Синең яныңда утырган күршең ишетә алырлык дәрәҗәдә кычкырып көлү.

2. Көлү тавышы яныңда утырган күршеңә ишетелми, көлгәнеңне бары үзең генә тоясың.

3. Көлүгә илтә торган йөз, ирен, күз торышы үзгәрү, әмма, асылда, бу көлү түгел. Әлеге күренеш елмаю дип атала, бу очракта бернинди дә тавыш чыкмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре намазда кычкырып көлү намазны да, тәһарәтне дә боза дигән бердәм фикердә тора. Намаз үтәлгән булып саналсын өчен, яңадан тәһарәт алырга һәм көлү сәбәпле бозылган намазны кабаттан укырга кирәк.

Көлүнең икенче категориясе бары намазны гына боза, тәһарәт бозылмый.

Намаз укыганда елмаю намазны да, тәһарәтне дә бозмый.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең хаклылыгын раслаган хәдисне китерик: Җәбир бине Габдулладан тапшырылган: «Кем дә булса намазда көлсә, намазын кабаттан укысын, әмма тәһарәтне кабат алуга ихтыяҗ юк» (Сахих Әл-Бохари, Китабүл вуду, 1/46).

Хәдистә телгә алынган «көлү» («ضحك») сүзе гомуми мәгънәгә ия һәм ул нинди дә булса сыйфат белән бирелмәгән. Димәк, бу хәдистә янында утырган кеше ишетерлек дәрәҗәдә кычкырып көлү турында әйтелгән дип аңларга кирәкми. Хәнәфи мәзһәбе галимнәре дәлилләре җыелмасында әлеге факт биредә кеше бары үзенең көлгәнен генә ишетә алуы хакында әйтелә.

Ибне Һөмәм рахмәтуллаһи галәйһи «Фәтхүл Кадир» китабында болай дип әйткән:

«Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне да бозуы хакында хәбәр иткән хәдисләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән берөзлексез иснәд (тапшыручылар чылбыры) белән дә, мөрсәл (табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасында сәхабәне телгә алмыйча) чылбыры ярдәмендә дә килә. Хәдис фәне белән шөгыльләнүче галимнәр, табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасындагы сәхабәне телгә алмыйча, Пәйгамбәр галәйһиссәламнән тапшырылган хәдис ышанычлы тапшыручыдан килсә, аны дөрес дип саныйлар. Әлеге темага мөрсәл хәдисне Әбел Галия, Хәсән Әл-Басри һәм Ибраһим Ән-Нәхагый тапшыра».

Шулай ук Ибне Һөмәм рахмәтуллаһи галәйһи: «Берөзлексез иснәд (мөснәд) белән килгән хәдисләргә килгәндә, аларны Әбү Муса Әл-Әшгарый, Әбү Һөрайра, Ибне Гомәр, Әнәс, Җәбир һәм Гыймран бине Хөсәен радыяллаһу ганһүмнәр тапшыра», – дип әйткән.

Әл-Бохари хәдисләр җыентыгының танылган «Гөмдәтүл Кари» аңлатмасында болай дип әйтелгән: «Кычкырып көлүнең намазны да, тәһарәтне дә бозуы хакында дәлил сыйфатында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 11 хәдисе бар. Аларның дүртесе мөрсәл (ул табигыйн һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам арасындагы сәхабәне телгә алмыйча тапшырыла), ә калган җидесе мөснәд булып тора (өзлексез чылбыр буенча тапшырылган хәдис) («Гөмдәтүл Кари», 3 том, 71 б.).

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кайсыгыз да булса намазда кычкырып көлсә, тәһарәтен дә, намазын да яңартсын» (Имам Мөхәммәд, «Әл-Хүҗа», 1/2014; Ибне Гади, «Кәмил», 4/101; Бәйһакый «Әл Хиләфият», 1/389, № 699).

Зәйд бине Халид радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән намаз укыган һәм шулвакытта бер сукыр кеше коега төшеп киткән, бу күренештән берничә сәхабә көлгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам намазны тәгәлләгәч, аларга таба борылып: «Кайсыгыз булса да көлсә, тәһарәтен яңартсын һәм намазын кабаттан укысын», – дип әйткән («Сүнән Дәракутни», 623).

Хәдистән аңлашылганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аларны ишеткәч, димәк, көлү тавышы ишетелгән. Һәм бу хәдисне бары шул мәгънәдә аңларга кирәк. Ә Җәбир радыяллаһу ганһедән тапшырылган хәдис аны бары тулыландыру гына булып тора.

Йомгаклап, Имам Мөхәммәд бине Әл-Хәсән Әш-Шәйбани рахмәтуллаһи галәйһинең сүзләрен китерәсе килә: «Әгәр дә хәдисләр булмаса, кыяс (аналогия буенча фикер йөртү) нигезендә, барысы да мәлики мәзһәбе галимнәре әйткәнчә булыр иде (ягъни кеше намаз укыганда көлсә тәһарәт бозылмас иде), әмма кыяс мөмкин түгел, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән килгән хәдисләр бар, һәм моңа охшаш барлык очракларда да (аерым алынган темага хәдис булганда), без бары хәдистә әйтелгәнне генә эшләргә тиешбез» (Имам Мөхәммәд, «Әл-Хуҗа», 1/204).

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Хатын-кызга кагылу тәһарәтне бозамы?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм, хәзрәт! Мин шәфигыйлар җирлегендә хәнәфи мәдрәсәсендә укыдым. Шәфигый җирлегендә ир белән хатынның кочаклашуы, үбешүе яисә бер-берләренә кагылуы нәтиҗәсендә аларның икесенең дә тәһарәте бозыла дигән фикер яши. Берәүләр «Кудури» китабы буенча гамәл кыла, икенчеләре тәннең икенче тәнгә тиюеннән тәһарәт бозыла дип санаучы шәфигыйлар белән каршылыкка кермәс өчен тырыша. Бу очракта аларга нинди дәлил китерергә?

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бу очракта бер киңәш бар: төгәл белмәгән мәсьәләләргә кермәскә. Ә фикһ буенча ышанычлы, дөрес гыйлемнәргә исә, бары остаз белән, мәзһәбнең дәрәҗәле китапларын өйрәнеп кенә ия булырга мөмкин.

Хәнәфи мәзһәбе буенча ирнең тәне хатынының тәненә тиеп китүдән тәһарәт бозылмый. Әйе, әгәр дә шәфигыйлар белән каршылыктан чыгу теләге бар икән, тәһарәтне яңартырга мөмкин, әмма ул бозылган өчен түгел, ә тәһарәтне яңарту бу очракта, имам Әш-Шурунбуләли «Нур әл-идах» хезмәтендә язганча, теләк буенча булганы (мәндүб, мөстәхәб) өчен. Тәһарәт мәндүб булган очракларны санаганда, имам Әш-Шурунбуләли шәфигый мәзһәбе буенча хатын-кызга кагылулардан тәһарәт бозылу очрагын да кертә. Хәнәфиләрдә исә «мүбәшарә фәһишә», ягъни ирләрнең җенес әгъзасы каршылыксыз, шәрә килеш хатын-кызның җенес әгъзасына тию генә тәһарәтне боза, дип әйтелә. Бу очракта җенси якынлык турында сүз бармый, ә шәһвәтлек турында гына сүз бара («Нур әл-идах»).

Ә үбешүләргә килгәндә, сак булу сорала, чөнки бу очракта хисләнүдән мәзи чыгу ихтималы бар, ә мәзи чыгу тәһарәтне боза һәм нәҗес санала. «Бәдәиг әссәнаи» китабы авторы мәзигә түбәндәге билгеләмәне бирә:

وَالْمَذْيُ رَقِيقٌ يَضْرِبُ إِلَى الْبَيَاضِ يَخْرُجُ عِنْدَ مُلَاعَبَةِ الرَّجُلِ أَهْلَهُ (بدائع الصنائع في ترتيب الشرائع، ج١ ص٣٧، دار الكتب العلمية)

«Мәзи – назлаулар вакытында чыга торган куе булмаган ак төстәге сыеклык». Ирдән мондый сыеклык чыкса, тәһарәт бозылды дигән сүз, сыеклыкны тәннән яисә киемнән юып алырга кирәк. Әгәр назлар вакытында ир-атның бернинди сыеклыгы да чыкмаса, тәһарәт бозылмаган була.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

## Келәм чистарту

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм! Келәмнәргә нәҗес (сидек, косык) тисә, ул урынны өч тапкыр юеш чүпрәк белән сөртү җитәме?

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләмвә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Келәмне өч тапкыр юеш чүпрәк белән сөртү генә җитми. Нәҗеснең төренә карап, келәм чистартуның ике варианты бар:

1) Әгәр нәҗес (мәсәлән, сидек) кибеп, беленерлек эз калдырмаса. Келәм калын булып, аны сыгу мөмкинлеге булмаса яисә келәм идәнгә беркетелгән булса, сидек тигән урынга су бөркеп, аны чүпрәк белән сеңдереп, келәмне киптерү кирәк. Бу гамәлне өч тапкыр эшләү тиешле. Әгәр келәм юка булса, аны өч тапкыр юып, өч тапкыр сыгу җитә. «Әл-Фәтва Әл-Һиндия» китабында болай дип язылган:

وما لا ينعصر يطهر بالغسل ثلاث مرات والتجفيف في كل مرة

«Сыгып булмый торган әйберне өч тапкыр юып, өч тапкыр киптереп чистарталар».

2) Әгәр нәҗес (мәсәлән, кан) кибеп, аның эзе калса. Бу очракта таплы урынга тап бетәрлек кадәр су салырга кирәк. Әгәр беренче тапкыр-

дан бетсә, бер тапкыр да җитә; әгәр бетмәсә, беткәнче су салу кирәк. Гадәти ышкып юганнан соң тап бетмәсә, бу урын чистарган санала. Махсус чистарткычлар куллануның кирәге юк, бары теләк буенча гына, чөнки кан табының эзе бер дә матур түгел. «Әл-Фәтва Әл-Һиндия» китабында түбәндәгечә килә :

وإزالتها إن كانت مرئية بإزالة عينها وأثرها إن كانت شيئا يزول أثره ولا يعتبر فيه العدد

فلو زالت عينها بمرة اكتفى بها ولو لم تزل بثلاثة تغسل إلى أن تزول

وإن كانت شيئا لا يزول أثره إلا بمشقة بأن يحتاج في إزالته إلى شيء آخر سوى الماء كالصابون لا يكلف بإزالته

وكذا لا يكلف بالماء المغلي بالنار

«Күзгә күренеп торган нәҗес – нәҗеснең үзен яисә аның эзен бетерү белән (әгәр бетереп булса) чистартыла. Кулланылган су күләме әһәмиятле түгел. Нәҗес бер тапкырдан бетсә, шул да җитә. Өч тапкырдан да бетмәсә, тап беткәнче юу кирәк. Әгәр тапны бетерү өчен махсус чистарткычлар кирәк икән, аларны куллануның кирәге юк, ягъни махсус каты ышку кирәкми. Шулай ук суны җылыту да кирәк түгел».

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Үрнәк затлар

# Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат

Татар милли хәрәкәте һәм милләт идеологиясе буларак элеккеге әдәбият та бар нәрсәнең астын өскә китергән җимергеч елларда үтә куркыныч әшәкелек дип бәяләнә. Менә шул чорда татар әдәбиятына аклау сүзе булып, К.Насыйри исеме гөрләп торды. Казан да, Мәскәү дә аны яраста, үз итә иде. Вафатына егерме ел үтү уңаеннан «Каюм Насыйриның мәҗмугасы» (1922, 161 б.) исеме белән тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр җыентыгы чыгарыла. Шулай башланган җанлануларга 1925 елда 100 еллыгы тантаналары килеп кушыла. Күпсанлы мәкаләләр, истәлекләр, кичәләр, утырышлар… Шул уңайдан югары фәнни камиллектә әзерләнгән, иске әдәбиятыбызның кулъязма хәлендә калган ядкәрләре – «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» (1926, 135 б.) китабы басылып чыга. Колхозлаштыру еллары, 30 нчы еллар башбаштаклыклары җан әсәре саклаган бу иҗади чишмәне кабат туңдыра башласа да, сугыш елларында хәрәкәт кабат җанлана: 1942 елда, вафатына 40 ел уңаеннан, мәкалә белән искә алалар. 1945 елда, 120 еллыгына багышлап, тантаналы гыйльми сессия үткәрелә. Аның югары пафослы материаллары аерым җыентык итеп чыгарыла. Күләмле генә китап булып «Сайланма әсәрләр» китабының кабат-кабат басылып торуы (1945, 1953, 1956, 1971 һәм 1974-1975 еллардагы ике томлыгы), «Әбүгалисина»ның зур яшьтәге балалар өчен кыскартып эшкәртелгән вариантының кат-кат басылуларының әһәмияте (1947, 1950, 1953, 1957) К.Насыйрины популярлаштырып, совет укучысына якынайту белән генә чикләнми, көчле кыраудан соң борынгы әдәбиятыбыз гореф-гадәтләренең кабат баш күтәреп җанлануын да чагылдыра.

К.Насыйри иҗаты борынгы әдәбиятыбызны яклау миссиясен дә үз өстенә ала. Шул шартларда К.Насыйрины өйрәнүгә багышлап язылган мәкаләләр саны да аз түгел кебек… Тормышы һәм иҗатының өйрәнелүе

ягыннан шундый, гадәттән тыш игътибар шартларында ул башка язучыларыбыздан нык аерылып торырга тиеш иде кебек тә бит?.. Юк шул! Хәтта туган елы да, 100 еллыгына әзерләнү процессында, очраклы рәвештә әтисе күчергән «Әмин тәзәк» дигән китапта әтисенең бу хакта язмасына юлыгып кына, фәнни төгәллеккә китерелә. Аңа кадәр 1823 яки 1824 ел дип санап йөрткәннәр. Әтиләренең 1823 елда туган Габделкаюм исемле малайлары булган икән. Ул 1824 елда вафат була. 1825 елда тагын бер малай дөньяга килгәч, вафат сабыйлары истәлегенә, аңа да Габделкаюм дип исем куялар. Бу «Габделкаюм»нарны бутаудан туган җитешсезлекне әле, совет чоры гадәтенә ияреп, үткән заманның Каюм бабайга игътибарсызлыгы нәтиҗәсе дип тә аңлатып була. Ә менә башка шундый фактларны, әйтик, әнисе турында мәгълүмат буталчыклыгын ничек аңлатырга?

«Археология материаллары» (Зөя өязе авыллары буенча) дигән хезмәтендә әдип үзе сүз уңаенда, «әти 1812 нче елларда... Сәлим бабаның кызын никахлаган», дип күрсәтеп уза[1]. Тагын аның әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да нәсел шәҗәрәләрен төзегәне билгеле. Әмма хисапсыз күп исемнәр өермәләре эчендә шәҗәрәдә бу төп факт бөтенләй диярлек күмелеп кала. Шуңа күрә бу чыганак игътибардан читтә калып килә. Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...»ның II томында әнисе ягыннан карендәшләренә шактый игътибар күрсәтсә дә, анда әтисе ягы һәм әнисе турында мәгълүмат юк. Үзенең ерак бабалары да Шырдан ягыннан чыккан Ризаэтдин бине Фәхретдин К.Насыйрига игътибарлы һәм ихтирамлы галим. Әмма мәшһүр «Асар»ендә ул К.Насыйриның әнисе турында сәер хәбәр теркәп калдыра. Сәгыйд бине Әхмәт Шырдани биографиясендә ул Әхмәт хәзрәтнең тагын биш кызы, ике улының исемен китерә. Сәгыйдтән соң гаиләдә икенче бала кебегрәк күрсәтелгән Фазыйлә исемле кызы – Габденнасыйр бине Хөсәен никахында (К.Насыйри әтисендә ирдә) иде, ди. Әхмәт хәзрәтнең бабасы Габденнасыйр бабасы белән бертуганнар икән,

---

1 Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1975. – II т. – 19 б;

этисе дә, әнисе дә бер нәселдән (Габдеррәззак, Әлмөхәммәдләр нәселләре). Бу шик уятмый: К.Насыйри төзегән шәҗәрәдә дә ул шулай күрсәтелә. Сәер нәрсә шунда: Әхмәт хәзрәт 1750 елда вафат дип күрсәтелә. Шулай икән, соңгы бала булып, ул этисе вафатыннан соң туган булса да, 1812 елга бу Фазыйлә 62 яшьләрдәге карчык булмыймы соң? 25 яшьләрендәге Габденнасыйр мулла 62 яшьлек Фазыйләгә өйләнә дә, Фазыйлә 75 яшьләренә кергәндә Каюм бабайны дөньяга китерә булып чыга. 1831 елда 90 яшендә үлгән (димәк, 1741 елларда туган) Сәгыйд хәзрәтнең этисе Әхмәтнең XVIII йөз урталарындагы кеше икәнен бәхәссез итә.

Максатыбыз: К.Насыйри биографиясендә шундый каршылыклы хәбәрләрнең дә булуына игътибар бирү иде. Аның чишелешен бәян итүне икенче бер вакытка калдырып, тагын бер мәсьәләгә генә кагылып үтәбез. Ул – К.Насыйриның «йомыкыйлыгы». Безнең фәндә ул тик консерватор-фанатикларның һәм югары катлау-байларның аны үз итмәве, аның белән (сыйнфый) конфликтта яшәвенең нәтиҗәсе дип кенә аңлатыла. Тормыш булгач, табак-кашык шалтырамый булмый. Андый хәлләр дә, бәлки, булгандыр. Үзе дә моңа дәлил бирә кебек. Зарланган вакытларында, шундый хәлләргә үпкәләрен искәрткәләп куя. Сәед бистәсенә сәфәрен генә хәтерлик. Әмма мондый очраклар картлык көннәреннән генә сакланган. Алары да принципиаль идеологик каршы тору характерында түгел. Аны – күздән төшерелгән, мәкерле рәвештә игътибардан, тану-тәкъдирләүдән читләтелгән кеше дип булмый. Хөрмәт дигәнне яшьлек көннәрендә дә татымаган түгел: Петербург академиясе белән хәбәрләшүләр; Казан университеты, Тарих-археология җәмгыяте эшендә катнашулар; 60 нчы еллар башыннан, татарча гәзит чыгару хәрәкәте башында йөрүләре; 70 нче еллар азагында Г.Чокрый белән аралашулары; китап сату мәсьәләсендә Казаннан читтәге укымышлылар белән бәйләнешләре, хатлары. «Шура»дагы истәлекләрдән күренгәнчә, мулла булырга әзерләнүче татар яшьләре дә, урыс телен өйрәнергә дип, аның тирәсендә мыж килеп торалар. «Моңарчы

басылмаган әсәрләре» китабында Һ.Максудидан китерелгән хәбәргә караганда (181 б.), шәкертләрнең әдәбият түгәрәге 1891 елда Төркиянең «Тәрҗемане хакыйкать» гәзитендә әдипнең тормышы һәм иҗаты турында мәкалә бастыралар. Яшь, бунтарь Г.Исхакый хәтта өенә килеп, аның белән очрашкан, танышкан; вафатыннан соң ул да аның турында мәкалә язып, И.Гаспралының «Тәрҗеман» гәзитендә бастырган. 1905 ел революциясенә кадәр тагын кайсы татар әдибе, галиме җәмәгатьчелек белән мондый киң һәм күпьяклы бәйләнештә булган? Юк. Аның популярлыгы белән дә ул чорда һичкем ярыша алмаган.

Шулай да ул үзен татар җәмәгатьчелеге эчендә «ак карга» итеп сизгән. Бу хис һәрчак аңа үзен искәртә. Моның үз сәбәбе бар. һәм ул сәбәп, беренче чиратта һәм күбрәк, аның социаль чыгышы үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Истәлекләрен хәтерләсәк, татар җәмәгатьчелегеннән берникадәр аерымлану – аның нәселенең сыйфат билгесе булганын күрербез. Ул нәсел агачына нигез салган җиденче баба — Габдеррәззак Бираш улыннан ук башлана. Әдип үзе дә бу бабасына шундый зур әһәмият бирә ки, «Җәваһирел хикәят» (1882) китабында, мәсәлән, үзенең нисбә исемен «әш-Шырдани әр-Раззакый» дип атый. «Археология материаллары» хезмәтендә Габдеррәззак бабаның нык легендалаштырылган кыскача биографиясен китерә[1]. «Габдеррәззак мулла – казакълар нәселеннән, бу дәрәҗә Казан ханы тарафыннан бирелгән. Әтисе, күрәсең, Тау ягындагы шул, хан казакълары катлавының башлыкларыннан була. Казанга каршы яу башлаган Явыз Иван сәясәтчеләре «атаманның» яшь улы Габдеррәззакны (ихтимал, әтисенең ризалыгы белән) үз якларына аударалар һәм аның белән бергә урыс патшалары хезмәтенә үткән бу татар казакъларының башлыгы итеп билгелиләр. Явыз Иван һәм Федор Ивановичлар вакытында Габдеррәззак ул чакта татарлар арасында башка кабатланмаган карьера ясый.

1 Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. —Казан: Татар.кит.нәшр., 1975. –II т. – 14 – 17 б.

«Тирә-як халкы арасында (күрәсең бөтен Тау ягында хөкем итә, ашлык салымы җыя. – м.г.) түрә булган Габдеррәззакның каралты-куралары, йорты чирек авылны биләп тора. Ишегалдының егерме җирдән капкасы була (Ф.Бурнашның «Габделмән» поэмасына һәм Сембер мишәрләре арасында киң таралган «Габделмәнкәй купич» бәетенә шул Габдеррәззак турындагы легендалар нигез булганга охшый. – м.г.). Федор Иваныч заманында Габдеррәззак баба мәшһүр кеше булып, Федор Иваныч аны Тау як халкына баш итеп куйган, имана шикелле, халыктан җыя торган ясакларны, акчадан, иген-тарудан җыеп, Федор Иванычка җибәрер икән... Габдеррәззак мулла патшалар белән таныш булган...»; «Каршы тауда Габдеррәззакның салдырып куйган ашлык сарайлары (элеваторы) бар икән. Шуларны саклар өчен, үзенә хәрби көч казакълар һәм «шәхси гвардия» – атларының дагалары һәм иярләренең өзәңгеләре көмештән ничә батыр коллары бар икән, «чура коллары» дип әйтәләр икән. Аңар китергән игенне бушатырга нәүбәт тимичә, күбесе, кырда кунарлар икән». Яңа патша, (күрәсең, Борис Годунов) ханлыкка утыргач, ике углын военный киемнәр киендереп атлары, кораллары, киемнәре белән, тәмам баштанаяк военный кеше итеп бәхшиш[1] кылган. Алар әйләнеп кайтмаганнар, Митри (Ялган Дмитрий) сугышында һәлак булганнар. Чуалышлар заманы («Смутное время») Габдеррәззакның үзен дә ияреннән сугып төшерә. Бар милкен, дәрәҗәләрен җуеп, бик фәкыйрьлектә вафат булгандыр.

Аңардан соңгы дүртенче буын тагын өскә калка. Тагын урыс түрәләре белән хезмәттәшлектә. «Әлмөхәммәт (Мүкәй) баба үз замананында бик мәшһүр, гаярь кеше булган. Урыс халкы арасында мәкъбүл[2], сүзе үткән кеше булган». Кайда угрылар бар, һәммәсен шымчылап сизеп торадыр икән. Каюм бабай моны караклар дөньясы белән нык аралашкан, аларның башлыгы кебек кеше булган, дип шәрехли. Биредә сүз – ул заман терми-

1 Бәхшиш – бүләк.

2 Мәкъбүл – хуш күрелгән, яхшы кабул ителгән

нологиясе белән «вор» – патша хакимиятенә каршы көрәшүчеләр турында булырга тиеш. Мүкәй баба ул хәрәкәткә үзе дә аралашкан төс күрсәтә. Бер үк вакытта, шымчы, доносчы булып урыс арасында да мәкъбүл – бик мәшһүр кеше булып китә…

Һәм менә Каюм бабага иң якын буын – аның әтисе: «Габденнасыйр мулла үз заманында гаярь, үткен, бик зирәк адәм булган. Вә һәм урыс телен кәма һүә[1] яхшы белгән». Авыл мулласы булыр өчен генә урыс телен шулай өйрәнү XIX йөз башында бөтенләй соралмаган. Ул урыс телен игенче, һөнәрче, рухани кәсебен тәэмин итү өчен түгел, тормышын материаль тәэмин итүдә, нәсел гореф-гадәтләрен дәвам итә алыр өчен, билгеле, шулай камил үзләштергән. Аның улы Каюмның да урыс телен үзләштерүгә җитди игътибары, беренче чиратта, һәм башлыча, урыс теле аша Аурупа мәдәниятенә якынайыйм яки «прикладной» фәннәр нигезләрен үзләштерим дип түгел, ә нәсел гореф-гадәтләрен дәвам иттерү булган. Насыйрилар нәселенең урыс хакимияте белән бу керешүе милләт экологиясен саклауда бөтенләй башка юлдан барырга мәҗбүр ителгән татар җәмәгатьчелеген сискәндерә, үзләреннән читкә кага. Бу үзенчәлекләре белән алар гомумтатардан өстен; татарлар да боларның шул үзенчәлегенә үзгәрүсез оппозициядә икәнен беркайчан яшерми. Мондый мөнәсәбәтләр эзе биографиясе билгелерәк булган. К.Насыйри яшәешендә аеруча ачык чагыла. Миссионерлар мәктәбендә – Урыс духовное училищесы һәм Духовная семинариясендә ышанычлы һәм абруйлы татар теле укытучысы булу (1855—1871) аны аз гына да сискәндерми. Татарлар моңа нинди мөнәсәбәт күрсәтер икән дип борчылу да – гүя аның өчен ят нәрсә. Ул бу ике тарафның берсенең фикере белән дә хисаплашмый. Үз иманы какшамаслыгына ышанычы камил. Башкасында аның эше юк. Урыс белән ул үзен татарга караганда иркенрәк тота, иркенрәк сизә. Бер үк вакытта ул үзенең бар тырышлыгын, бар эшчәнлеген татар мәдәниятенең та-

[1] Кәма һүә – тиешлечә.

рих тарафыннан зур тотрыклылыкка китерелгән (традицион) юнәлешенә олы ихтирам белән талымсыз хезмәткә багышлый. Рус мәдәниятеннән берничә битле урыс теле грамматикасын, берничә битле «Русия тарихы»н гына ала. «Әнмүзәҗ»е генә түгел, җәгъръфия, хисап, һәндәсәләре, хәтта күбрәк Көнчыгыш чыганакларга ориентирлаштырылган. Төп һөнәре – матур әдәбият өлкәсендәге барлык хезмәтләре, әлбәттә, һәм эзлекле рәвештә, иң ерак гасырлардагы Якын Көнчыгыш әсәрләренә бәйләнгән булыр. XIX гасырның соңгы чирегендәге татар әдәбиятын 1080 елда язылган «Кабуснамә», 1135-1145 (580) елларда иҗат иткән Зәмәхшәри, VIII йөзнең ахырында язылган «Фихрист»ләр нигезендә төзелгән «Фәвакиһел җөләса...», XV йөз төрек әдәбиятыннан алынган «Әбүгалисина», «Кырык вәзир», 1505 елда үлгән Мисыр галиме имам Суютыйның «Әнисел җәлис» китабын татарчалаштырып «Җәваһирел хикәят»е белән татар әдәбиятын баета. Ихтимал, карт әдипнең үзенең соңгы чыгарган китабыдыр, 1902 елда аның нашир исеме белән басылган «Әлифба, Иман шарты белән» китабын ул «Яшәсен үзебезнең кадимебез!» дигән лозунг белән тәмамлый.

Әдип иҗатының мондый үзенчәлекләренә икенче бер мөһим сәбәп – гаиләви-социаль җирлек тә бар. К.Насыйри – Габдеррәззак нәселе генә түгел, күренекле абызагайлар нәселе дә. Абызагайлык XIX йөз башында шактый укмашкан, үз идеологиясе белән аерымланган гомуми иҗтимагый барыштан читләшкән экспрессив бер хәрәкәткә әйләнә. Абызагайлар – Диния нәзарәтенә буйсынудан, Указ алудан, имтиханга барудан баш тартучы демократик авыл руханилары, үз заманының укымышлылары (абызлары). Әнисе ягыннан якын туганнары, югарыда телгә алынган Сәгыйд бине Әхмәд һәм аның уллары күренекле абызлардан булганнар. Сәгыйд хәзрәтнең Г.Курсави белән туганлашуы, Г.Утыз Имәни кебек авылдан авылга туктаусыз күченүләре, авылда яшәү мөмкинлеге калмагач, 1810 елда Казанда төпләнүе – аның абызагайлар хәрәкәтендәге активлыгы белән бәйләнгән. К.Насыйриның әтисе Сәгыйд хәзрәтнең хас

шәкерте була. Остазы Казанга күчкәндә, «Сәгыйд хәзрәт белән Бәрәскәдән Казан шәһәренә килгән. Авылында имам булырга приговор җыеп Дини идарәгә җибәрсә дә, имтиханга бармаган, мулла булмаган – ясалган приговоры мөфти мәхкәмәсендә шулай ятып калган». Аның абызагайлар активлаштырган темаларга – «иҗтиһад заманы мөнкарыйз дигәнне рәд кылып, ошбу йиремездә җәй көннәрендә ястү намазы ... вөҗүбен» исбат кылып язган һ.б. рисаләләре бар. Һичбер риясыз, зиядә мөтәшәрригъ[1] адәм иде. Чыкылдап торган, сугышчан абызагай позициясендәге кеше. К.Насыйри үзе үк: «Әтиемнең балалары да хәзер шул мәзһәбтәдер», – дип, һич икеләнүсез белдерә. Ягъни Каюм бабабыз да, абызагайлар заманы күптән үткән булуга да карамастан, замана таләпләренә актив якын килгән кеше, үз заманы проблемаларын сугышчан абызагайлык стандартларына салып бирә. Гүя абызагайлар хәрәкәтенең яшәүчәнлек тамгасы итеп җанландырылган соңгы могиканы санитария-гигиена, үсемлекләр дөньясы, агрономия, кулинария, әйберләрне җизләү-алтынлау белемнәре буенча язган хезмәтләрендә, замандашлары – Көнбатыш Аурупада позитивизмны мәйданга китерүче О.Конт, Г.Спенсерлар белән бер практик планда сызыкка чыккан кеше, конкрет-практик иҗат эшчәнлегендә, шул ук вакытта гүя мөселман урта гасырчылыгы җимешләрен клонлаштыру белән, фантастик мәшәкатьләре белән мәш килә. Бу хәлнең нигезенә, яшәү тамырларына күз салсаң, шулай күзаллап, без үзебез әллә нинди, килбәтсез хыял томанында саташкандай бөтерелүебезне күрәбез. К.Насыйри эшчәнлегендә һичбернинди каршылык-чуалу, ике нарат арагында адашуга охшаш нәрсә юк. Аның иҗат эшендә борынгылыкларга мөрәҗәгате, нигездә, мәшһүр галимнәр Г.Курсави, Ш.Мәрҗаниләрнең Нәсифи фикһ белән мавыгулары – күп гасырлык ислам мәдәнияте синтезын эзләүләре белән бер үк күренеш. Бөтен дөнья гыйлем һәм фәнгә кызыксыну белән тулганда, берәр нәрсә аңлыйм, тормыш өчен файдасы

[1] Мөтәшәрригъ – шәригатьне яклаган.

булыр дип (яңа позитивизм позициясеннән), К.Насыйри татар халкын, үз традицион мәдәнияте нигезендә, гыйлем бабындагы тәнәззеленнән[1] заман югарылыгына күтәрү юнәлешендә конкрет практик эшчәнлек башлап җибәрә. Бу аның фикер каршылыгы түгел, олылыгы билгесе. Алар үз халкы мәдәниятен заман таләбенә якынайтуның татарча, мөселманча юлын булдыру эшенә алынганнар. Бу юнәлеш уңышсызлыкка юлыккан икән, моңа алар гаепле түгел. Революцияләр, җимерелүләр заманы татарны ул юлдан читләтә. Халкыбыз характерындагы бик күп негатив үзенчәлекләр – инертлыклар, пассивлыклар – кысылып калган мөселманнар арасында Ш.Мәрҗани, К.Насыйрилар башлаган юнәлеш үсеп китә алмауның нәтиҗәсе булып тора.

*Мәсгуд Гайнетдин,*

*«Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр» китабыннан*

1 Тәнәззеленнән – түбәнчелектән.

# Фән

# Суфичылык – рухи яктан камилләшү юлы

Безнең төбәктәге Ислам дине тарихы турыдан-туры тәсаввуф (суфыйчылык) белән бәйләнгән. Мөселманнар бер Аллаһыга булган ихлас иманнарын күп очракта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рухи дәвамчылары аша кабул иткән һәм саклап калган.

Тәсаввуфның Идел буенда бик күптәннән үк данлы тарихы, үзенчәлекләре бар. Идел буе Болгар дәүләтендә суфыйчылыкның төгәл кайчан барлыкка килүе турында әйтү кыен, ләкин, XII гасырда болгарлар арасында Ясәвия тарикате (ул Хуҗа Әхмәд Ясәви тарафыннан нигезләнә) тарала башлый. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы татар тарихчысы Хөсәмеддин бине Шәрәфеддин Болгариның «Таварихе Болгария» («Болгар тарихы») китабында бу тарикать тарафдарларының исемнәре китерелә. Суфилар татарлар арасында Ислам дине таратуга шактый зур өлеш керткәннәр.

Урта гасырлар татар әдәбияты тәсаввуф белән бик тыгыз бәйләнгән. Күпчелек татар шагыйрьләре суфилар булган. Алар үз әсәрләрендә рухи һәм әхлакый камиллеккә ирешү турында язып калдырган. Тәсаввуф – ислам фәннәренең берсе, ул күңелне пакьләргә һәм рухи яктан камилләшергә чакыра. Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларындагы татар-төрки язучылары, шагыйрьләре әсәрләрендә суфыйчылык образларын, принципларын очрата алабыз. Казан ханлыгы галимнәре Ясәвия тарикате тарафдарлары булган. Алар арасында иң зур ихтирамга лаеклыларның берсе – Кол Шәриф (туган елы билгесез). Тарихи чыганаклар буенча, ул 1552 елны руслар Казанны яулап алган вакытта һәлак булган. Кол Шәриф шигъриятендә Ясәвия гореф-гадәтләре ап-ачык күренә. Мәсәлән, аның күпсанлы шигырьләренең берсе Сөләйман Бакырганиның улы Хөбби

Хуҗага багышланган. Сөләйман Бакыргани (1111-1186) Әхмәд Ясәвинең (XI йөзнең ахыры –1166) шәкерте булган.

XVI гасыр урталарыннан, Казан ханлыгы яулап алынганнан башлап, мәчетләр, мәдрәсәләр җимерелә, мөселманнар үз ватаннарында дини белем алу мөмкинлегеннән мәхрүм кала, ислам гыйлеме алу өчен, алар Урта Азиягә, Бохарага йөрергә мәҗбүр була. Ул вакытта Урта Азиядә суфыйчылык киң таралган була, анда китүчеләрнең күбесе тәсаввуф юлына баса. Кайберләренә рухи тәрбия бирергә рөхсәт (иҗәзәт) бирәләр. Татарларда XVII-XVIII гасырларда Ислам күп очракта суфыйчылык идеяләре белән тиңләштерелә. Суфыйчылык, өстенлек итүче дини институт буларак, татарлар тормышының бар якларына да йогынты ясаган: гаилә мөнәсәбәтләреннән башлап, социаль-сәяси карашларга кадәр. XVII-XVIII гасырларда татарлар арасында, башка гореф-гадәтләрне (мәсәлән, Ясәвия гореф-гадәтләрен) алыштырып, Нәкышбәндия тарикате (ул Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1331-1389) тарафыннан нигезләнә) киң тарала. XVIII – XIX гасырларда күп кенә татар дин галимнәренең рухи остазлары Нәкышбәндия тарикатеннән булган. Мәсәлән, шагыйрь, дин гыйлеме белгече Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834) – шәех Фәезхан Әл-Кабулидан; мәгърифәтче, ислам галиме Габденнасыйр Курсави (1776-1812) – шәех Ниязкол Әл-Төрекмәнидән; олуг галимебез, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) – шәех Гобәйдулла бине Ниязкулидан, Габделкадыйр Әл-Фаруки Әл-Һиндидән, шәех Мәзһәрдән рухи тәрбия һәм белем алганнар. Алар барысы да шәригать нигезләрен өйрәнгәч кенә, тәсаввуф юлына басканнар. Үз хезмәтләрендә алар, мөселманның беренче бурычы – хак иманга ия булу, икенче бурычы – фикһ мәсьәләләрен өйрәнү, бары тик аннан соң гына – тәсаввуф юлына басу, – дип язганнар.

XX гасырның 17 елларыннан башлап, татар мәдрәсәләре Нәкышбәндия тарикатендә булган дин әһелләре тарафыннан контрольдә тотыла. Ул вакытларда имам сайланганда халык лаеклы остазы булган

намзәдкә (кандидатка) өстенлек биргән. Ягъни, суфи булмый торып, җәмгыятьтә абруй казанып булмаган. Ул чорларда  суфыйчылык татар халкының дини һәм милли үзенчәлекләрен саклап калырга хезмәт иткән.

XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап, Рәсәйдә суфыйчылык яңадан торгызыла башлады. Татарстанда традицион тарикать тарафдарларының саны арта бара. Традицион тарикатьләр Исламның гүзәллеген һәм югары әхлагын чагылдыралар, динебезнең әдәп принциплары таралыш алуга ярдәм итәләр. Тарикатьләр – экстремистик ислам агымнарына альтернатива.

Теләсә кайсы кешенең күңеленә ачкыч табарга була.  Бу аны үгетләүче кешенең күңел пакьлегенә, аның халәтенә бәйле. Тарикать остазларының ихлас кичерешләре, белемнәре Ислам диненең чын матурлыгын җиткерергә, Аллаһыга, Аның Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган чын сөюне тоярга ярдәм итә.

Шуңа күрә, безнең халыкның рухи гореф-гадәтләрен торгызу, аларны яшьләргә җиткерү – аеруча мөһим. Моның өчен бар мөмкинлекләр дә бар. Тәсаввуфның асылы – күңелләребезне сафландыру. XVII-XIX гасырларда халкыбыз тормышы җиңел булмаган, ә кайвакыт гаять дәрәҗәдә авыр булган. Суфыйчылык сабырлык, Аллаһы Тәгаләгә сыгыну, Аның рәхим-шәфкатенә өмет баглау кебек төшенчәләрне халык өчен бик әһәмиятле иткән. Алар безгә XVII гасырда яшәгән Мәүла Колый («Хикмәтләр»),  XVII гасыр ахыры XVIII башында яшәп, иҗат иткән Аллаһияр Суфи «Собател гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») китабы кебек суфи шагыйрьләр аша килеп ирешкәннәр.

Намаз уку, ураза тоту, Аллаһыга гыйбадәт кылуның башка төрләре безне яхшы якка таба үзгәртәләр, рухи яктан  баеталар. Тәсаввуф рухи-әхлакый яктан камилләшүнең өстәмә ысулларын тәкъдим итә, аларга өйрәтә. Гадәти булган тарикатьләр безне тыйнаклыкка, сабырлыкка, игелекле гыйлемнәр алуга омтылырга өйрәтә.

Шәех Вәгыйзь Кәшифи (куддисаллаһу сирруһу) болай дип әйткән: «Суфилар өч нәрсәдә башкаларга үрнәк булып торалар: кирәксез, урынсыз сүзләрдән тыелуда, файдасыз эшләргә алынмауда һәм Ахирәттә файдасы тиячәк эшләрне эшләүдә».

Тарикать остазларыбыз бервакытта да зөһедкә, бикләнеп ятуга өндәмәгәннәр, киресенчә, җәмгыятьтә яшәргә, гаилә корырга, гомуми проблемалар белән яшәргә, дөньяны яхшы якка үзгәртергә тырышырга, ләкин, шул ук вакытта һәрвакыт Аллаһы белән булырга чакырганнар. Шәех Баһаветдин Нәкышбәнди: «Күңел – Сөеклегә (Аллаһыга), ә куллар – эшкә», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә белән япа-ялгыз булуга караганда, Аллаһы белән һәрдаим җәмгыятьтә булу яхшырак.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*ТҖ МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы*

# Малдан зәкят чыгару

Зәкят, Исламның өченче баганасы буларак, милек гыйбадәте санала. Зәкят милекне һәм җанны чистартуга, мөселманнар арасында гаделлекне саклау, байлар белән ярлыларны бердәй күрүгә юнәлдерелгән булганлыктан, җәмгыятьтә бик мөһим урын тота.

Зәкят Коръәннең якынча 30 аятендә намаз белән бергә искә алына, бу исә зәкятнең никадәр дәрәҗәдә әһәмиятле булуын күрсәтә. «Гыйлем эстәү – һәр мөселманның бурычы», дигән хәдис тә гыйлем алырга өнди. Мөселман өчен иң мөһим гыйлемнәр фарыз гамәлләр белән бәйле, шунлыктан, галимнәребез зәкят һәм аны түләүгә кагылышлы гыйлемнәрне һәр мөселманга өйрәнүне тиешле саный.

«Зәкят» – лексик мәгънәсе ягыннан «чистарыну» һәм «үсү» дигән сүз. Шәригатьтә – нисап күләмендә милке булган кешенең хәләл юл белән табылган малыннан тиешле кешегә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бирелә торган өлеш (нисап күләменә җитеп яисә артып киткән малдан кырыктан бер өлеше, ягъни 2,5%) дигән сүз. Ислам динендә, тән һәм милек белән бәйле башка гыйбадәтләр дә булган төсле, кешегә, яшәү дәрәҗәсен исәпкә алып, үзе күтәрә алырдай зәкят бурычы да йөкләнгән.

### Зәкят түләүнең шартлары:

1. малның нисап күләменә җитүе;
2. нисап күләме малның әҗәтләрдән, тормыштагы азык-төлек, кием кебек кирәкле ихтыяҗларга булган чыгымнардан артып калган өлешеннән саналу;
3. малның чынлыкта артуы яисә арту мөмкинлеге булуы;
4. ай календаре буенча бер ел узгач, нисапка ия булу;
5. ай календаре буенча ел дәвамында малның бөтенләй юкка чыкмавы.

## Нәрсә ул нисап?

Нисап – ул шәригатьтә кешенең бай булганлыгының күрсәткече. Нисап күләме алтын белән 20 мыскалга (85 гр.), хайваннар белән булса, 5 дөягә, 30 сыер яисә 40 сарыкка тигез. Зәкятнең кемгә бирелергә тиешлеге Коръәндә («Тәүбә» сүрәсенең 60 нчы аяте), ә күләме хәдисләрдә (Сахих Әл-Бохари, «Зәкят», 32, 36, 38, 43) ачык аңлатылган. Шуларга таянып, нисапка җиткән малы булган кеше, әҗәтләреннән һәм асыл ихтыяҗларыннан калган милкеннән зәкятен чыгарырга тиеш.

## Зәкят кем өчен фарыз? Зәкятнең дөрес булуының шартлары нинди?

Зәкят гыйбадәтенә бәйле шартлар икегә бүлеп карала: зәкятнең кемгә фарыз икәнлеген күрсәтә торган шартлар һәм зәкятнең дөреслегенә кагылышлы шартлар.

Зәкятнең фарызлыгына шартлар: мөселман булу, акыллы булу, балигълыкка ирешү, азат булу, әҗәтләреннән һәм асыл ихтыяҗларыннан кала нисап күләмендә арткан яисә арту мөмкинлеге булган, ягъни керем китерә алырлык малы булу.

Болардан тыш, зәкят түләнергә тиешле мал ай календаре буенча бер ел эчендә бөтенләй юкка чыкмаска тиеш. Малның ел әйләнәсе артуы яисә кимүләре исәпкә алынмый. Зәкят вакытыннан алда да түләнергә мөмкин.

Зәкятнең дөреслегенә килгәндә, иң беренче чиратта нияткә игътибар итәргә кирәк. Зәкят нияттән башка дөрес булмый, чөнки зәкят бирү гыйбадәт булып санала. Моннан тыш, зәкятнең «тәмлик» дигән шарты бар, ягъни малны башка кешенең милегенә тапшыру процессы. Башка шартларын үтәмичә, ризык әзерләп, берәр мохтаҗның ашавына мөмкинлек кенә бирү зәкяттән китмәячәк.

## Балигълыкка ирешмәгән балаларның милкеннән зәкят түләү тиешме?

Зәкят түләү акыллы һәм дин буенча балигълыкка ирешкән кешегә тиешле. Хәнәфи мәзһәбе буенча, балигълыкка ирешмәгән балаларның, байлыклары булуга да карамастан, зәкят түләү бурычы юк. Әмма әгәр балигълыкка ирешмәгән баланың җиреннән уңыш җыела икән, бу уңыштан гошер садакасы бирелергә тиеш.

Исламда зәкят мәсьәләсендә милекнең шәхсилеге нигез булып тора. Шунлыктан, әгәр кешенең нисап күләмендә милке бар икән, ул, әтисе белән яшәсә дә, зәкят түләргә тиеш.

## Сатарга ниятләгән милектән зәкят ничек түләнә?

Мал сатуга ниятләгән милек булып саналсын өчен, ике шартның берсе үтәлергә тиеш:

1. киләчәктә сату нияте белән алынган булу;
2. сату нияте белән җитештерелгән булу.

Әгәр кеше милкен сату ниятеннән кире кайтса, бу мал сатуга ниятләнгән милек категориясеннән чыга. Зәкят түләгәндә, сатарга җыенган малның базар бәясе күздә тотылырга тиеш. Аның беренчел бәясе һәм киләчәктә артачагы исәпкә алынмый.

## Зиннәтле бизәнү әйберләреннән зәкят түләнәме?

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикеренчә, башка шартлары үтәлгәндә, алтын яки көмештән эшләнгән бизәнү әйберләреннән зәкят түләнә. Алар кулланылыштамы, юкмы – аерма юк. Имам Әбү Хәнифә (рахимәһуллаһ) болай дип әйткән: «Кемдә алтыннан яки көмештән бизәнү әйберләре булса, аны тагып йөрү өчен кулланса да, кулланмаса да, ул зәкят түләргә тиеш» (Әл-хүҗҗә галә әһлил-Мәдинә, 1/448). Алтын белән 85 грамм,

көмеш белән 600 граммга җитеп, бер ел узгач та нисап саклanса, бизәнү әйберләреннән зәкят түләү тиешле. Алтын белән көмештән кала башка кыйммәтле ташлардан яисә кыйммәтле металлдан эшләнгән әйберләрдән зәкят түләнми.

## Акцияләрдән зәкят түләнәме?

Нинди дә булса оешманың акцияләрен сатып алган кеше әлеге оешма карамагында булган биналарның, җиһазларның, үзендә булган акцияләренә бәрабәр рәвештә, уртак хуҗасына әверелә. Бу очракта акционер оешманың керем һәм чыгымнарын да уртак бүлә. Керем алган очракта, акционерга тиешле дивидент өлеше һәм аның башка милке нисапка җитә икән, бу кеше алардан зәкят түләргә тиеш.

Әгәр акцияләр дивидент алу өчен түгел, ә алга таба сату өчен алынган икән, алар сату өчен булган милек категориясенә керәләр. Аларның бәясе һәм калган башка милек бәясе нисапка җитсә, бу милекнең базар бәясеннән чыгып, зәкяте түләнә.

## Зәкят түләнергә тиешле милек бәясеннән нинди әҗәтләр чигерелә ала? (Аллаһы Тәгалә һәм кол хакы)

Зәкят түләргә тиешле кеше милкеннән билгеле бер физик һәм юридик затларга бәйле булган әҗәтләрен чигерергә тиеш. Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең киң таралган фикере буенча, әҗәтне түләү срогы җитсә дә, җитмәсә дә, аңа карата булган хөкем үзгәрми. Озак еллар буенча түләнеп килә торган кредит, ипотека, торак кооперативларына булган взнослар тулысы белән зәкят суммасыннан чигерелә.

## Әҗәтле кешенең әҗәте зәкяттән китә аламы?

Акча яисә милекнең ярлы (мохтаҗ) кешенең шәхси милкенә күчүе зәкят дөреслегенең шарты булып тора. Бу очракта милекне икенче кешегә тапшыру мәҗбүри. Азык әзерләп кенә мохтаҗга ашау мөмкинлеге бирү милек тапшыруга керми. Әмма әзерләнгән ризык зәкят нияте белән мохтаҗларга тапшырылса, зәкят дөрес була. Әгәр кеше әҗәткә акча биреп торып, алардан зәкят түләргә уйламаган булса, әмма соңрак зәкят түләү фикеренә килсә, бу әҗәт акчасы зәкяттән китми, чөнки акча зәкят нияте белән бирелмәде. Бу мәсьәләдә дүрт мәзһәб галимнәре дә уртак фикердә.

## Хәләл юл белән табылмаган малдан зәкят түләнәме?

Әгәр хәләл юл белән табылмаган акчаның хуҗасы билгеле булса, бу акча хуҗасына кайтарылырга тиеш. Әгәр билгеле булмаса, яисә ярлыларга өләшеп, яисә хәйрия фондларына биреп, бернинди савап өмет итмичә, бу акчалардан арыну тиешле. Димәк, хәләл юл белән кермәгән акчадан зәкят түләнми, чөнки андый акча кешенең милке булып саналмый һәм аннан тиз арада арыну кирәк.

*Татарстан Республикасы мөселманнары*

*Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды*

# Тарих

# Ватан вә милләт тарихы хакында

Һәр кеше иртә торып, бер гамәлгә керешмәк булса, үзенең үткән көннәрдә кылган эшләрен хәтеренә төшереп, берничә уйлап карый вә кыласы эшләрен үткәндә хасил иткән тәҗрибәсе буенча ничек мәгъкуль күрсә, шулай кылырга иҗтиһад итә[1]. Үткәндә күргән файда вә зарарларны хәтеренә төшереп, киләчәктә шул зарарларның тәкрар булуыннан саклана, файдасын үткәндәге кеби, бәлки артыграк та, булдырырга иҗтиһад вә гайрәт итә. Күп кешеләр эшләгән эшләрен вә кылган гамәлләрен ата-бабаларына ияреп, алар тәҗрибәсе буенча кылалар, падишаһлар һәм ушандак[2] хөкем вә низамнарын үткәндә булган падишаһларның гадәтенчә, яки, заманның хәленә күрә, бәгъзеләре үзгәртебрәк йөртәләр. Тәҗрибә өчен үткән тереклекнең кыяфәтен уйлау һәр кешедә табигый булган бер сыйфаттыр. Мәгърифәтле кешеләр һәрвакыт үзләренең тереклегендә булган гаҗәбрәк вакыйгаларны киләчәктә үзләренә яки балаларына гыйбрәт өчен язып куялар. Киләчәктә бу язулардан үткән заманның хәленнән хәбәр бирүче бер гыйлем хасил була (гыйльме тарих). Үткән заманның хәленнән, ата-бабаларының вә падишаһларының тереклегеннән хәбәрдар булу бик мактаулы сыйфаттыр. Тарих белгән кемсәләр артык тәҗрибәле вә тәдбирле[3] булалар. Дөньяның һәр заманда булган вакыйгаларын, үзләре шул заманнарда көн иткән кеби, белеп торалар. Тарих белмәгән кеше, үткән заманның хәленнән хәбәре булмагач, киләчәктә ни булачагын да аңламый, чөнки гыйбрәт алыр нәрсәсе һәм үлчәве юк. Бөтен галәмдә вакыйг[4] булган әхвальне вакыт вә заманы белән бәян итү тарихе гомуми вазифасыдыр. Һәр мәмләкәтнең үзенә махсус бер тарихы була. Ислам

---

1 Иҗтиһад итү – тырышу.

2 Ушандак – шулай ук.

3 Тәдбирле – уйлап эшләүчән.

4 вакыйг – хакыйкать.

дәүләтләрендә, хосусан, гарәпләр гыйльме тарих белән бик шөгыльләнеп, зур иҗтиһад сарыф иткәннәр һәм үзләреннән күп тарихи әсәрләр калган. Мәсәлән, X, XI, XII, XIII, XIV гасырларда гарәп мөәррихләре дөньяның һәр тарафында сәяхәт кылып, гүзәл-гүзәл сәяхәтнамәләр язып калдырганнар. Хосусан, Аурупада төрки таифәләреннән яхшы хәбәр биргәннәр. Мәсәлән, болгарлар, башкортлар, бортаслар, хәзәрләр вә гайреләр хакында. (Мәгълүмрәк мөхәррирләрнең бәгъзесен түбәндә йад ителде. Ибне Фазлан, Ибне Батутта, Мәсгуди, Әбү Хәмид Әл-Әндәлеси, Әл-Бәлхый, Ибне Хаукаль, Ибне Дастә, Зәкәрия бине Мөхәммәд Әл-Казвини, Әбү Исхак Әл-Истахрый, Якут Әл-Хәмәви, Ибне Әл-Әсир, Шәмсетдин Әд-Димәшкый, Мокаддәси, Идриси, Ибне Халликян, Ибне Хәлдун, Әбел-Фида, Әл-Бәкри вә гайреләр.)

Аурупа мөәррихләре Рәсәй дәүләтендәге төрки, фин, славян таифәләренең тарихи хәбәрләрен хәзердә һәм гарәп сәяхәтнамәләреннән алалар. Рәсәйнең мәшһүр мөәррихе Иловайский рус халкының асылы булган славяннар хакында иң ышанычлы хәбәрләрне гарәп мөәррихләренең әсәрләреннән алабыз, дип яза. Коръәнебездә тарихи хәбәрләр бик күп: пәйгамбәрләребезнең нәселе – гарәп таифәсе бу фәнгә шул кадәр иҗтиһад вә ригаять иткәннәр. Әмма без, Рәсәй мөселманнары бу гыйлемгә һичбер заманда мәхәббәт салып, тәхсиленә һиммәт иткәнебез юк. Шул сәбәпле, тарихтан һич хәбәребез юк. Ата-бабаларыбызның хәлен вә кем булганлыкларын да (татармы, болгармы яки башка бер таифәдәнме) яхшылап белмибез. «Сез татармы?» – дип, сораганда, «татар», – дип әйтәбез. Башкача җавабыбыз юк. Чөнки гайре таифәләр безне татар диләр. Үзебез дә шуңа күрә «без татардыр, ахры» дип гөман итәмез. Әдәбиятыбыз мең елдан мөкаддәм башланса да, үзебездән тарих язучылар булган юк. Мөхәррирләребез «Бәдәвам», «Ахырзаман», «Ярым алма», «Мәликә», «Йосыф», «Бакырган» китаплары язып калдырганнар, тарихтан һичбер әсәрләре калмаган.

Милләтебезнең бу кадәр гафил булуына һәр гасырда гаҗәпләнүчеләр булган, Хәрәземдә Әбелгазый хан төрки таифәләренең тарихын яздырырга лаек кеше таба алмагач, үзе тотынып «Шәҗәрәи төрки» исемендә бер тарих китабы язган. Өч йөз илле биш ел мөкаддәм хәзерге Спас өязендә Ташбилге каръясенең[1] Хисаметдин Әл-Мөслими берничә адәмнәрнең үтенече буенча «Тәварихы Болгар» исемендә бер рисалә язган. Тарих юк сәбәпле, халыктан ишеткән хәбәрләрне көллисен дә[2] язып, күп асылсыз вә дәлилсез хәбәрләр җыеп калдырган. Ушандак мөхтәрәм остазыбыз, Шиһабетдин Әл-Мәрҗани тарихыбыз юклыкка һәм гыйльме тарихта ихласыбыз булмавына төрлечә фикерләр йөртеп караган. Һәм күп иҗтиһад берлән эзләп, тикшереп «Мөстафадел-әхбар...» исемендә ватан вә милләтебезнең тарихыннан гүзәл бер китап язып калдырган. Безнең тарихыбызны Аурупа мөәррихләре үзебездән артыграк беләләр дип әйтергә мөмкин. Чөнки алар гыйльме тарихка бик иҗтиһад кылып, һәр телдән тарих китапларын үз телләренә тәрҗемә кылалар. Гарәп, фарсы вә төрки телләрдән дә күп китаплар тәрҗемә кылганнар. Ләкин Аурупа мөәррихләре арасында безнең асыл кайсы таифәләрдән икәнлегебез хакында ихтилаф бар: бәгъзесе монгол татары диер, бәгъзеләре болгар диләр. Унөченче гасырда Бату хан берлән килгән монгол татарлары болгарлар берлән катышып, шунда җыелган халык дип әйтүчеләр дә бар. Әлбәттә, һәркайсының үзенә дәлилләре бар. Үзебездән моңарчы шул ихтилафларны[3] да аерып бирерлек кеше чыкмады, гүя бер ташландык бала мисалында торабыз. Асыл нәсәбебезне белмәйбез. Бу көнгә кадәр белергә иҗтиһад та кылганыбыз юк. Әдәбияты булган милләтнең мәктәп вә мәдрәсәләрендә гыйльме тарихны, хосусан, үзенең милләт вә ватан тарихын зур фәннәрдән санап, бик иҗтиһад берлән укыталар,

1 Каръясенең – авылының.

2 Көллисен дә – барын да.

3 Ихтилаф – төрле фикер.

әмма безнең мәдрәсәләребездә бу гыйлемгә башка фәннәр арасында урын бирелгәне юк һәм мәдрәсәләребезгә кабул ителмәгән. Гыйльме тарихны куәтләү һәм арттыру өчен Рәсәйнең күп шәһәрләрендә, хосусан, җәмгыятьләр һәм музейлар бар. Мәсәлән, Петербургта, Мәскәүдә, Ташкентта, Казанда Асаре гатыйка җәмгыятьләре бар. Сембердә, Сарытауда, Пермьдә, Оренбургта һәм гайреләрдә архивный комиссияләр бар. Дәхи күп шәһәрләрдә статистика комитетлары һәм музейлар бар. Без – Рәсәй мөселманнары бу кыяфәтебездә үзебезгә махсус тарихи җәмгыятьләр вә музейларны тиз генә булдырыр хәлебез юк, чөнки алардан заруррак бик күп нәрсәләргә мохтаҗбыз, шул сәбәпле, гайре милләтләрнең иҗтиһады вә һиммәте берлән булган җәмгыятьләр вә музейлар берлән файдалану кирәк була, шул җәмгыятьләргә катышучыларыбыз булса (әгъза булыпмы яки башкачамы), милләтебезнең тарихы өчен күп файдалы хәбәрләр табарга мөмкин булыр иде. Казан дарелфөнүнендә[1] булган Асаре гатыйка җәмгыятенең хезмәте, хосусан, тузган Болгар, Хәзәр, Казан, Әстерхан дәүләтләренең асаре гатыйкаларын тикшерү вә боларның тарихы өчен хәбәрләр вә әсәрләр җыю, дәхи Вятка иделе берлән Агыйдел буендагы таифәләрнең асылын вә тарихын тикшерүдер. Бу җәмгыятьтә йөз иллегә кариб[2] әгъзалар бар: Казаннан, Петербургтан, Мәскәүдән, Финляндиядән, Кавказдан, Сибириядән вә гайреләрдән, дәхи чит мәмләкәтләрдән, мәсәлән, Франция, Алмания, Швеция һәм башкалардан. Күбрәге мөхәррир вә профессорлар, мөселманнардан да өч кеше бар. Бу җәмгыятьтә бездән әгъзалар күбрәк булса, бик яхшы булыр иде. Чөнки мөселманнар хакында күп тарихи хәбәрләр язып бастыралар (русча һәм мөселманча). Әгъза булып керү өчен тарихтан яңа хәбәрләр язу яки шул хосуста башкача иҗтиһадлар күрсәтү кирәк була. Мәсәлән, гыйльме тарихка тәгальлекъле асаре гатыйкалардан хәбәр бирү, тапкан җирдән алып җәмгыятькә тап-

[1] Дарелфөнүнендә – югары уку йортында, университетта.

[2] Кариб – якын.

шыру, яки җәмгыять файдасына акча сарыф итү кеби. Ләкин гыйльме тарихка мәхәббәт тотучыларыбыз бик аз, гыйлем вә мәгърифәтле дип йөртә торган кешеләребезнең дә күбесе тарих мәсьәләләрен вак эшкә санап, алар белән шөгыльләнүчеләрне дә эшсезлектән бала-чага эше белән шөгыльләнә дип гөман итәләр. Ун ел мөкаддәм Казан дарелфөнүнендә булган Җәмгыяте асаре гатыйка тарафыннан күндерелмеш (командировать ителмеш) идем. Чистай, Спас, Лаеш вә Тәтеш өязләренә Болгар заманыннан калган асаре гатыйкаларны тәфтиш кылып, шулар хакында халык арасында булган тарихи хәбәрләрне җыю өчен. Шул заман Тәтеш өязендә Олуг Болгар карьясенең мулласын күреп тарихи хәбәрләр сорашмак булдым (чөнки бу авыл халкы, үзләренең ата-бабаларыннан килгән хәбәр буенча, әүвәлдә шәһре Болгардан күчеп утырганнар, имеш). «Казанда дүрт малай укый, аларга икмәк ташудан бушап булмый, иске хәбәрләр тикшерергә вакыт юк», – дип көлеп җавап бирде. Дәхи Келәш карьясенең бер мулласыннан сораштым. Искерәк тарих китаплары хакында: «Ул язган китапларны, муллаларның сәке астында, әллә кайчан тузан басып бетергән», – диде.

Тәтеш өязендә Әлки карьясенең карт имамы Баһаветдин хәзрәт үзенең гыйльме тарихка мәхәббәтен вә иҗтиһадын хатыбызга каршы җавап язып, берничә аңлатты, һәм йөз егерме ел мөкаддәм язылган бер тәварих китабын да җибәргән иде, хатның бер-ике сәтыры шул: «Тәварих бабында иҗтиһадыгызны ишетеп, бик мәмнүн булдык, без һәм әтрафымыздагы асаре кадимәләрне тикшереп вә тәварих мәсьәләләре белән шөгыльләнеп, гомеребезне үткәрдек, Шиһаб хәзрәтнең тәварихында булган хәбәрләрнең күбесе безнең иҗтиһадыбыз белән булгандыр. Баһаветдин хәзрәт әтрафындагы асаре гатыйкаларны күрсәтү нияте белән үзебезне чакырыр иде. Мәсәлән, якыннарындагы чуаш авылларында Болгар заманнарыннан калган язулы ташлар кеби. Мәрхүм дамеллага Тәтеш өязеннән асаре гатыйкалар хакында күбрәк

хәбәрләр ул язган, имеш. Гыйльме тарихка мәхәббәт тотучыларыбыз, аз булса да, бар икән. Тарих өчен милләтебездә бер яхшы гадәт бар: искедән калган нәрсәләрне мөкаддәс санап, югалтмый, туздырмый саклау (төрле язулар, иске тәңкәләр, иске кораллар, язулы ташлар вә болардан гайре асаре гатыйкалары кеби). Мондаен нәрсәләрне бездән берәү дә толчокка чыгарып сатмый, бәлки үзендә саклый. Дәхи халык телендә ватан вә милләт тарихы өчен искедән килгән хәбәрләр бик күп. Мәсәлән, Болгар вә Казан дәүләтләре хакында төрки таифәләренең бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүләре хакында, бу хәбәрләрнең күбесе дөрес булмаса да, бәгъзеләре бик ышанычлы вә дәлилледер.. Дәхи халыкның гадәтләрендә, кәсепләрендә, телендә (исемнәр, мәкальләр, җырлар, бәетләр кеби) тарихе милләт өчен күп әсәрләр табарга мөмкин. Болай булганда «тарих юк» дип, зарланып кына уздыру исламияткә вә инсаниятькә дә һич муафыйк түгел, бәлки зур гафиллектер. Нәсел-нәсәпләребезне яхшылап белмәенчә, асылсыз вә дәлилсез, үзебезне татар санап яки татар булучылыкка разый булмай: «Без татар түгел, мөселман яки төрки», – дип, ачуланышып йөрү дә мәгърифәттән түгел. Асылыбызны яхшылап тикшереп, милләтебезнең тарихын барлыкка чыгару өчен үзебезгә тырышу лязем буладыр. Тырышмый, эзләми никадәр торсак та, безгә тарих китапларын бирүче булмас. Иҗтиһад итсәк, ин шә Аллаһ, үзебезнең кем икәнлегебезне белербез һәм гайре милләтләргә дә аңлатырбыз, дәхи ватан вә милләтнең тарихын да барлыкка чыгарырбыз.

*«Казан мөхбире» газетасыннан*

# Япониянең беренче мөселманнары: Нагоя шәһәре татар җәмәгатьчелегенең тарихы



**Татарларның Япониягә күченү тарихы**

Әлеге мәкалә Япониянең Нагоя исемле шәһәрендәге татар җәмәгатьчелегенең тарихына багышлана. Япониядә беренче татарлар якынча XX гасыр башында барлыкка килә, ә 1917 елгы инкыйлабтан (революциядән) соң аларның саны тагы да арта. Бирегә килүче татарларның күпчелеге тукыма һәм кием белән сату итүче сәүдәгәрләр була. Япония, Аурупа өчен ябык булганга, әмма Аурупа киемнәренең фасоны һәм тукымалар җирле халыкта зур кызыксындыру тудырганга күрә, әлеге эшмәкәрләргә монда сәүдәләрен үстерү өчен зур мөмкинлекләр ачыла.

Алга таба, сәүдә эшләрен җайга салгач, күченеп килүчеләр Япониягә, нигездә Маньчжуриядән булган башка татарларны да чакыра башлый. Шулай итеп Йокохамада, күпмедер вакыттан соң, Токио, Кумамото, Кобе һәм Нагоя шәһәрләрендә беренче татар җәмәгатьчелеге оеша. Ел саен

җәмәгатьчелектәге кешеләр саны артканлыктан, үзләренең мәчетләрен һәм мәктәпләрен ачу зарурлыгы туа. Әгәр дә баштан татар җәмәгатьчелеге әлеге максатларда аерым биналар арендалаган булса, соңрак, акча ягыннан ныгыгач, җирләр сатып ала һәм анда аерым мәчетләр, мәктәпләр төзи башлый. Әлеге татар-мөселман җәмәгатьчелекләре ярдәмендә японлылар беренче тапкыр якыннан Ислам дине белән таныша.

Нагоя шәһәре һәрвакытта да Япониянең порт шәһәре булып торган. Моннан тыш, Нагоя янында Кобе һәм Осако шәһәрләре кебек индустриаль үзәкләр урнашкан була. Мөгаен, нәкъ менә әлеге фактлар 1919 елда Нагояда кайбер татар гаиләләренең төпләнүенә сәбәп буладыр. Алар әлеге шәһәрдә төпләнеп, яши башлаучы беренче мөселманнар булалар. Шәһәр аралары якын булганлыктан, Нагоя татар җәмәгатьчелеге Кобедагы кардәшләре белән тыгыз элемтәдә тора. Бу зур булмаган, әмма бик тә бердәм җәмәгатьчелек була. 1919 елдан алып, 1945 елга кадәр татар җәмәгатьчелегендә, балаларны санамыйча, 30 дан алып, 60 ка хәтле кеше исәпләнгән.

Татарлар һәрвакытта да диндар булулары белән аерылып торганнар, шуңа күрә кая гына күченеп яши башласалар да, беренче эш итеп, мәчет төзергә тырышканнар. Ә җәмәгатьчелекнең иң укымышлы әһелен имам итеп билгеләгәннәр. 1931 елда җәмәгатьчелек «Нагоя мөселманнары җәмәгатьчелеге» дигән исем алып, рәсми рәвештә теркәлү уза.

Җитәкче буларак Әхмәд мулланы билгелиләр. Туган якларыннан читтә яшәгән балалар үз телләрен, мәдәниятләрен һәм диннәрен онытмасыннар, дигән фикерне алга сөреп, җәмәгатьчелек үз алдына балаларны укыту мәсьәләсен куя. Моның өчен 1933 елда җәмәгатьчелек әһелләре махсус биналар арендалый һәм укытучылар чакырта башлый. Шушы ук бинада (Бунка Киокай) татар мәдәнияте үзәге нигезләнә.

Елдан-ел балалар саны артканлыктан, күпмедер вакыттан соң, мәктәптә урын җитми башлый. 1935 елгы март аеның җәмәгатьчелек

җыелышында мәчет төзү турындагы карарны кабул итәләр. Мәктәп әлеге мәчет бинасында урнашырга тиеш була. Оештыручылар алдында, беренче булып, Япония хөкүмәтеннән рөхсәт алу бурычы тора. Хакимият органнарына җәмәгатьчелекнең мәнфәгатьләрен белдерер өчен тулы хокуклы вәкилләр билгеләнә. Бу вазифаларны үз өстенә Тимербай Хәмидулла һәм Хөснетдин Сәедгалиев ала. Шулай ук мәчет төзү өчен түбәндәге составта комитет оеша: Тимербай Хәмидулла – комитет рәисе; Хөснетдин Сәедгалиев – казначы; Мансура ханым – сәркатип; Сизган – рәис урынбасары; Хөсәен Кильки – комитет әгъзасы, шул ук вакытта җәмәгатьчелекнең җитәкчесе һәм имамы; Г. Шихатер – комитет әгъзасы.

Җир алыр һәм төзү эшләрен башлар өчен акча җыю эше оештырыла. Ул вакытта Нагоя шәһәрендә бары тик 12 мөселман-татар гаиләсе яшәгәнлектән, кирәкле сумманы җыю аларның көчләреннән килми. Җәмәгатьчелек әһелләреннән тыш, күпчелек финанс ярдәмне Япониянең һәм Маньчжуриянең башка татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, шулай ук һинд мөселманнары һәм Кобе гарәпләре күрсәтәләр.




1936 елның апрель аенда җәмәгатьчелек 16 Banchi 25, 3 Chrome, Chikusa-ku адресы буенча җир сатып алса да, төзү эшләрен башлар өчен акча җитми. 1936 елның гыйнвар аенда Нагояга, үзенең гаиләсе белән, Кобе шәһәре татар җәмәгатьчелегенең лидеры Гисмәтулла Эгерджи килә. Ул төзү эшләренә дип, ул вакыт өчен бик күп санал-

ган, 1 000 йен акча бүлеп бирә. Шул ук елның август аенда җәмәгатьчелек, ниһаять, төзү эшләрен башлар өчен, рәсми рәвештә рөхсәт алуга ирешә.

1936 елның 4 нче сентябрендә тәүге таш куюның тантаналы чарасы оештырыла. Чарада, җәмәгатьчелек әһелләреннән тыш, Кобе шәһәре имамы Мәдьяр хәзрәт Шәмгуни, Һиндстан мөселман дин белгече Мәүләнә Мөхәммәд Габдулалим Сыддыйк катнаша.

Мәчет тантаналы рәвештә 1937 елның 22 нче гыйнварында ачыла. Шунысы да игътибарга лаек: бу – Япониядә төзелгән икенче мәчет була (беренчесе Кобе шәһәрендә урнашкан). Кызганычка, бу вакыйгаларга куану озакка бармый. Япония, 1941 елның 7-8 декабрендә, Тын океанындагы (Перл-Харбор) Америка корылмаларына, Азиядәге (Гонконг) Бөекбритания корылмаларына һөҗүм итеп, Икенче Бөтендөнья сугышына кушыла.

1945 елның март аенда Нагоя татарлары шәһәрдән китәргә һәм Кобедагы кардәшләренә күченергә мәҗбүр була. Җәмәгатьчелек әһеле Рөстәм Арсланов сүзләре буенча, бу күченү мәҗбүри рәвештә эшләнә һәм Япония җитәкчелегенең таләп итүе белән бәйле була. Ул вакытта Япония белән Кушма Штатлар арасында киеренке сугыш бара. Нагоя янында хәрби заводлар урнаштыралар, шулай ук гаскәрләр һәм авиация туплана. Мөгаен, японлылар, татарлар дошманга әһәмиятле



1998 елда ачылган мәчетнең бүгенге көндәге күренеше

мәгълүматлар тапшырырга мөмкин, дип уйлагандыр. Биредәге татарлар инде күптәннән японлыларга кушылган булуга карамастан, Япония җәмгыяте аларны элеккеге Рәсәй империясе кешеләре итеп кабул итә. Империя варисы – Советлар Союзын, Япония хөкүмәте, дошман һәм Кушма Штатлар союздашы дип исәпли.

Билгеле булганча, америкалылар тарафыннан һөҗүм ясалган вакытта, Нагоя мәчетенә бомба төшә һәм ул тулысынча янып бетә. Соңрак, 1950 елларда, авыр экономик шартлар аркасында Япониянең күпчелек татарлары Төркия, АКШ, Канада һәм Австралиягә күченә.

Нагоя җәмәгатьчелегенең бүгенге көн мөселманнары 1998 елның июль аенда яңа мәчет ачу бәхетенә ирешә. Зур булмаган әлеге дүрт катлы мәчет дөньяның иң үзенчәлекле мәчетләренең берсе булып тора. Мәчеттән тыш, бинада ислам үзәге эшләп килә.

*Мөхсин Нурулла язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Япониянең беренче мөселман мәктәбе – «Исламия Мәктәбе»нең тарихы

Идел-Урал татарларының революцион Рәсәйдән массакүләм рәвештә күченүләреннән соң, аларның бер төркеме Ерак Көнчыгышта (Маньчжурия) төпләнә. Чама белән 1919 елда Маньчжурия мөселманнарының бер өлеше Япониягә күченергә уйлый. Күпмедер вакыттан соң Япония башкаласы Токио качкын мөселманнарның төп үзәкләренең берсенә әйләнә.

Япония мөселман җәмәгатьчелеге темасы бик кызыклы. Токио мөселман җәмәгатьчелегенең күпчелеген татарлар тәшкил иткән. Һәм шулай ук берничә башкорт һәм уйгыр гаиләләре булган. Бу сорауга ачыклык кертү өчен, бүгенге көндә Төркиядә яшәүче, Токио җәмәгатьчелеге вәкиле Фазыл Агишның сүзләрен китерәбез: «Җәмәгатьчелекне татарларга һәм башкортларга аерып карау бик кыен. Без Токио җәмәгатьчелегендә Габделхәй Корбангали, Насыйбулла Хәлиуллиннарның башкорт икәнлекләрен белә идек, Җәлил Сабиҗан хакында йә типтәр, йә башкорт, дип әйтәләр иде. Хакыйкый күпчелекне Пенза татарлары тәшкил итә, әмма барысы да диярлек үзләрен Идел-Уралның төрки-татарлары яки мөселманнар дип атый. Шуңа күрә татарлар, башкортлар һәм хәтта уйгырларны да үзара аерып карамыйлар».



مکتب اسلامیه شاگردلاری اویله نمازی اوقیلار. ١٩٣٦ - مارت.

本校生徒の礼拝（校内一九三六年三月）

**1936 елның март ае.**
**«Исламия мәктәбе» укучылары өйлә намазын укый**

Ислам дине һәм татар мәдәнияте

җәмәгатьчелекне берләштерүче төп фактор булып тора. Татарлар юкка гына Токионы сайламыйлар. Башкалада японияле бик күп аристократлар, хәрби хезмәткәрләр һәм чит ил халкы яши. Бу рәвешле шәһәр, татарларның төп эшчәнлеге булган сәүдә – тукымалар, кием сату сәүдәсе белән үзенә җәлеп итә. Токиода төрки-татарлар сәүдә өлкәсендә генә түгел, хәтта Япониянең тышкы сәясәтендә дә зур роль уйный.

Токиода татар җәмәгатьчелеге 1919-1921 елларда урнаша башлый. 1919-1940 елларда, төрек-татар җәмәгатьчелегенең актив эшчәнлеге чорында, вәкилләрнең саны 350-450 кешегә җитә.

Татар җәмәгатьчелеге тарихы һәм бөтен мөселман дөньясы өчен – Токиода «Исламия Мәктәбе»нең барлыкка килүе мөһим вакыйга булып тора. Япония империясенең күпгасырлык яшәеше тарихында ислам тәүге тапкыр әлеге борынгы дәүләт территориясенә «аяк баса».

«Исламия мәктәбе» барлыкка килгәнче, Ерак Көнчыгышта ачылган татар мәктәпләрендә укыту әсбаплары һәм Коръәни Кәрим белән тәэмин итүдә проблемалар була. Бу хәлне җайга салыр өчен Харбинның (хәзерге Кытай, Маньчжуриянең тарихи территориясе) имамы типография ача, әмма аның үлеме белән бу эш туктатыла.

Шул ук вакытта Советлар Рәсәендә татар алфавитына кагылышлы реформалар (1920 елда алфавитның гадиләштерелгән варианты – яңа имлә ысулына күчү) аркасында: эмигрантларга кайсы юлдан үтәргә дигән сорау туа. Алфавитның яңа кагыйдәләре гарәп һәм фарсы сүзләренең күптәннән килгән язылу принципларын боза. Бу – татарларны исламнан һәм язуның элеккедән килгән күпгасырлык гореф-гадәтләреннән аера. Шуның өчен соңгы чиктә Маньчжурия, Япония, Финляндия һ.б. илләрдәге татар эмигрантлары яңа алфавитны кабул итмичә, искечә язуны дәвам иттерә.

Иң баштан күпсанлы проблемалар аркасында, мигрантлар чит илдә үз балаларына гыйлем бирү соравын читкә куеп торырга мәҗбүр

була. Тик бу хәл балаларны диннән, милләтләреннән һәм үзләренең тамырларыннан ерагайта башлый. Биредәге мәктәпләрдә балалар бары кытай, япон һәм рус телләрендә сөйләшүгә күчә. Япониядә туучы балалар, үзара гына түгел, әти-әниләре белән дә япон телендә аралаша башлап, татар телләрен оныта төшә. Хәтта кайбер татар гаиләләре, безгә татар теле һәм исламны өйрәнү нигә кирәк, дигән сүзләр әйтә башлый.




**№2 фото «Исламия мәктәбе» бинасы (мәктәп бинасы күп кенә вакыт мәчет буларак кулланылган).**

Дини һәм милли үзаңнарын югалтмаган кайбер ата-аналар үзләренең балаларын, диннән, телдән һәм мәдәнияттән аерылып үсмәсеннәр өчен, Токиодан Харбинга җибәрә. Ә Токио белән Харбин арасы 3100 чакрымнан да артып киткән ераклык. Моннан тыш, бу ата-аналардан зур чыгымнар таләп итә. Шул рәвешле, Япониягә күченүнең башлангыч этапларында качкыннарның балалары дини тәрбия алудан һәм туган телләрендә гыйлем эстәүдән мәхрүм була.

1920 елда токияле төрки-татарлар Мәхәллә-и Исламия җәмәгатьчелегенә берләшеп, җомга намазлары үткәрә башлый. Җомга вәгазьләре һәм нәсыйхәтләре татарларның дини һәм милли бердәмлеккә җыя. Җәмәгатьчелек балаларына дини һәм милли тәрбия бирү турында тагын да күбрәк уйлана башлый.

1927 елны Корбан мәҗлесе вакытында җәмәгатьчелек әһелләре Токиода үзләренең дини-милли мәктәпләрен ачуның кирәклеге ас-




**№3 фото Укучылар «Исламия Мәктәбе» каршында уйныйлар**

сызыклый. Имам һәм укытучы Габделхәй Корбангалиев (чыгышы белән башкорт кешесе, киләчәктә мөселманнарны берләштерүдә зур роль уйнаучы) бу мәсьәлә буенча Япония хөкүмәтенә мөрәҗәгать итә.

1927 елның 2 нче октябрендә Токионың Шин-Оукубо районында Хакунин Чу 266 адресы буенча урнашкан йортта, Япония хөкүмәтенең рөхсәте белән, мөселман башлангыч мәктәбе – «Исламия Мәктәбе» үз эшчәнлеген башлый. Укытулар татар телендә алып барыла, аеруча да зур игътибар ислам диненә һәм балаларга дини гыйлем өйрәтүгә бирелә.

«Исламия Мәктәбе»н Япония мәгариф министрлыгы таләпләренә тәңгәлләштергәннән соң, 1936 елның 5 декабрендә мәктәп рәсми статуска һәм моның белән бергә Япония дәүләт мәктәпләре хокукларына һәм өстенлекләренә ия була. Мәктәпнең директоры итеп Габделхәй хәзрәт Корбангалиевны билгелиләр.

***(Дәвамы бар)***

*Мөхсин Нурулла,*

*islam-today сайтыннан тәрҗемә*

# И, туган тел!

# Тел саклау хакында

«Нур» газетының 8 нче номерында Исхаков Гаяз әфәнденең тел хакында язган мәкаләсен укып, гаять сөендек. «Афәрин!» Без бу фикерне күп еллардан бирле башыбызда йөртә идек. Хәзер дә мәдрәсәләргә телебезнең сарыф вә нәхүн дәрес итеп укылмавына да бик эчебез поша, чөнки әдәбияты булган һәр милләт мәктәп вә мәдрәсәләрендә, башка фәннәр белән бәрабәр, бәлки артыграк та, үзенең телен укыйлар, әмма без моннан бик гафилбез. Телебезне сакламасак вә гыйлемен дә укымасак, телебез дә бетәр, динебезгә дә зарар килер. Польша татарлары мисалында калырбыз, һич шөбһәсез. Моңарчы бу хәвефне халыкка ничек аңлатырга да чара булмады. Унбиш-егерме ел гыйлем тәхсил иткән шәкерт вә имамнарыбыз үзләрен гыйлем вә мәгърифәтен күрсәтү өчен хатларын күп вакытта гарәп, фарсы вә төрек (госманлы) гыйбарәләре белән тутыралар. Кулыбызда күп хәзрәтләрнең вә шәкертләрнең хатлары бар. Бәгъзесенең яртысы вә бәгъзесенең өчтән бере гарәпчә, калганы татарча, төркичә вә чыгытайча, күбесенең гыйбарәләре дә дөрес түгел. Мондый хатларны әлбәттә, һәркем күргән вә укыган. Бу мөселманнар язган китапларында һәм сүзләрендә һич урынсыз вә кирәксез гарәп вә фарсы, төрек сүзләрен катыштыралар.

Бу тел мәсьәләсен Истанбулдан укып вә күреп кайткан кемсәләр белән дә күп мәртәбә сөйләшкәләп караганыбыз бар. «Ник сез ата-бабаларыбызның теленнән нәфрәтләнеп, китапларыңызны төрекчә (госманлыча) язасыз», – дип сораганыбыз бар. Бу әфәнделәрнең максатлары төрек телен бөтен Рәсәй мөселманнарына аңлатып, гомуми бер әдәби тел итеп калдыру икән, ләкин бу бик мөшкел. Урысча укыган яшьләребез, белем күрсәтү өчен, телләрендә күбрәк урыс сүзләрен йөртәләр һәм хатларын да урысча язалар. Без боларның һәркайсын татарча язабыз, бәлки наданлык сәбәпле шулай яза дип тә уйларлар. Телебезгә һич зарурсыз гарәп

вә фарсы, төрек вә урыс сүзләре кереп, үземезнең шулар бәрабәрендәге сүзләребез һаман югала вә онытыла бара. Бу сүземнең дөреслегенә кечкенә генә бер мисал китерермен: Иван Грозный заманында нәсрани булмыш татарлардан, Алабуга өязендә бер керәшен белән сөйләштем, үзенең мәхкәмәдә булган эшләреннән берничә сүзләр сөйләде. Үз ягымнан ике танык алып бардым, диде, әмма мин ул «танык» дигән сүзне аңламаенча, бераз уйлап тордым, сезнеңчә гуаһ, дип әйтәләр, диде. Танык дигән сүз урынына мин, әлбәттә, фарсыча «гуаһ» яки гарәпчә «шаһит яки урысча «свидетель» дип әйтәчәк идем. Мин мөгаллим булсам да, бу керәшен миннән татарча остарак вә тел гыйлемендә гыйлемлерәк икән дип, гаҗәпләнеп калдым, чөнки танык дигән сүз асыл татар сүзе булып чыкты. Без аны бөтенләй онытканбыз, имеш.

Польша вә Литва татарларының тарихлары бик ачык беленмәсә дә, татарлык вә мөселманлыклары кай дәрәҗәдә икәне һәркемгә мәгълүмдер. Алар әүвәлдә Алтын Урдадан чыгып, үз ихтыяҗлары белән Литва кенәзләренә ялланып, атлы гаскәр булып хезмәткә кергәннәр. Күбесе яшь кенәзләр вә морзалар булып, теләсәләр, Литва вә поляк кызларын алырга ихтыяр булган, шул рәвешчә катышкалап, Литва вә Польша халкы арасында калып, телләре тәмам югалган вә күбесе мөртәт булып та беткәннәр. Шул сәбәпле, хәзер дә мөселман фамилиясе белән урыс алпавытлары вә кенәзләре күп. Вятка губернасының Глазов өязендә арлар арасында «бәчермән» исемендә бер халык бар, урысча «бисермән» диләр. Үзләре урыска һәм арга да башка, бәгъзесе дине исламда, бәгъзесе нәсрани булганнар, телләре арча (вотяк). Бу халык безнең тәҗрибәбез буенча, әүвәлдә башкорт булса кирәк, чөнки якыннарындагы Алабуга вә Сарапул өязләрендә башкортлар бар. Үзләре аз халык булып, ар таифәсенең уртасына кереп утырганнар да, шул арларның әсәре белән үз телләрен аз-аз онытып, арча сөйләшә башлаганнар. Мәгәр исемнәрендә вә бәгъзе бер гадәтләрендә вә авыл

исемнәрендә генә мөселман исемнәре калган. Күбесе хәзер дә насара, бик азы мөселман булып калган, мөселманлыклары да шул Польша татарлары мисалында гына. Шулай итеп, әүвәлдә мөселман булган башкортлар хәзер дә бәчермән булып калганнар. Дунай буендагы болгарлар, асылында, төрки таифәсе казакъ кеби күчмәле халык булып, Гайсә галәйһиссәламнән соң бишенче вә алтынчы гасырларда Волга (Идел) буендагы болгарлардан аерылып киткәннәр. Дон вә Днепр суларын үтеп, үзләренең мал-туарлары белән сахрадан-сахрага күчеп, Дунай суы буена барып, күп славян таифәләрен үз кулларына төшереп, аларның уртасында калганнар. Әүвәл үзләре мәҗүс булып, соңыннан славяннар белән катнашып, юнаннарның әсәре белән насара динен кабул итеп, үз телләрен тәмам оныткан-нар. Хәзер дә асылы төрки икәнлекләренә күп галәмәтләр бар. Һәм башка славян таифәләреннән аермалары бар. Мәсәлән, буйда, төстә, бәгъзе гадәтләрендә, авыл вә шәһәр исемнәрендә һәм телләрендә бәгъзебер төрки сүзләре калган (госманлы лөгатендә юк сүзләр). 1783 елда императрица Екатеринаның әмере белән Петербургта Российская академия ачылган. Рәсәйнең шул гасырда булган мәшһүр мөхәррирләре – барчасы бу академиягә әгъза булганнар. Мөхәррирләрнең өстенә лязим[1] булган: урыс телен саклау, лөгать вә нәхү китаплары язып, телнең кагыйдәләрен җыю. Бу академия соңыннан Академия наукка кушылып, шунда урыс теле өчен махсус бер бүлек булган. Бу бүлектәге мөхәррирләр хәзер дә һәм хезмәт вә иҗтиһадлары шул тел бабындадыр[2]. Тимер юл, паровоз, пароход, самовар кеби яңарак чыккан нәрсәләргә үз исемнәрен бирергә тырышканнар.

Шул сәбәптән, Ак диңгез буендагы урыс белән Кара диңгез буендагы вә Амур буендагы урыс белән Петербургтагы урыс бер йорт җәмәгате кеби бер-берсен аңлап, яхшы сөйләшәләр.

1 Лязим – бурыч.

2 Бабында – өлкәсендә.

Без – Казан мөселманнары, Кырым вә Кавказ мөселманнары белән бер-беребезне аңлап, үз телебездә сөйләшер хәлебез юк. Ике татар урысча сөйләшәбез яки бер тәрҗеманга мохтаҗ булабыз.

Мөселманнар өчен һәртөрле китаплар чыгып тора. Үз телебездә газеталар да чыга башлады. Үзебезнең махсус басмаханәләребез дә булды, язучыларыбыз да бар. Бу иркенлек заманында, мөселман кардәшләр, иҗтиһад вә гайрәт итсәк булмасмы? Телебезне сакларга вә төзәтергә һәм бу көннән балаларыбызга үз телебезнең нәхү вә сарыфын укыта башларга!

*«Казан мөхбире» газетасыннан*

# Тәфсир

# Нух галәйһиссәлам кыйссасы

Нух галәйһиссәлам кешелекнең икенче атасы дип санала. Ул әдәп-әхлакны югалткан халыкка пәйгамбәр итеп җибәрелә. Нух галәйһиссәламнең халкы потларга табына, кешеләргә явызлыклар эшли һәм иң авыр гөнаһларны кыла. Әлеге җәмгыятьнең әдәпсезлегенә карамастан, Нух галәйһиссәлам кечкенәдән хак юлдан бара, бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кыла. Ул су сибә, авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә, көтүче, балта остасы һәм төзүче була.

Нух галәйһиссәламгә илле яшь тулгач, Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек бирә һәм ул тугыз йөз илле ел дәвамында пәйгамбәрлек кыла.

Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай дип әйтә:

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَىٰ قَوْمِهِ فَلَبِثَ فِيهِمْ أَلْفَ سَنَةٍ إِلَّا خَمْسِينَ عَامًا فَأَخَذَهُمُ الطُّوفَانُ وَهُمْ ظَالِمُونَ ﴿١٤﴾

**«Тәхкыйк, Нухны кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек, ул кавеме эчендә аларны дингә өндәп тугыз йөз илле ел торды, кавеме исә иман китермичә залим булды һәм аларны Туфан суы тотты».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:14

Асылда, кешелек яшәешенең беренче чорында, потларга табыну булмаган. Ул вакытта бер илаһка гыйбадәт кылу тарала, әмма вакытлар узу белән дингә инану бозыла. Һәм Нух галәйһиссәламнең халкы да туры юлдан читкә тайпыла.

Кайчандыр бу халыктан биш кеше чыккан: Вәдд, Сува, Йәгус, Йагук һәм Нәсыр. Алар үзләренең тәкъвалыклары белән билгеле булалар. Риваятьләр буенча, әлеге биш кеше Идрис галәйһиссәлам сәхабәләре булганнар. Аларның бер-бер артлы вафат булулары халыкка зур кайгы

китерә. Һәм алар турында истәлекне саклап калу өчен, кардәшләре бу кешеләрнең сыннарын ясый башлый. Кешеләр вакытлар узган саен әлеге сыннар янына йөри башлый һәм хак кешеләрдән ишеткән нәсыйхәтләрне бер-берсенә сөйлиләр.

Әмма берничә буын алышынгач, кешеләр әлеге сыннар ни өчен ясалганлыкны оныта һәм аларны Аллаһыга ширек кыла башлый. Вакытлар узгач, сыннарга табыну әлеге халыкның рәсми диненә әверелә. Ялган дин киң таралыш алгач, Аллаһы Тәгалә кешеләргә Нух галәйһиссәламне җибәрә. Коръәндә моның хакында болай дип әйтелә:

إِنَّا أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَىٰ قَوْمِهِ أَنْ أَنذِرْ قَوْمَكَ مِن قَبْلِ أَن يَأْتِيَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿١﴾

**«Һичшиксез, Без: «Тилмерткеч газап аларга килгәнче, кавемеңне кисәт!» – дип, Нухны кавеменә җибәрдек».**

«Нух», 71:1

## Үзсүзле һәм дингә ышанмаучы халык

Нух галәйһиссәламнең көрәшенә һәм берничә гасырлар дәвамында дингә чакыруына карамастан, аның халкы көферлектә нык торуын дәвам итә. Бу халык бик тә үзсүзле була. Берничә кешене санамаганда, аларның берсе дә хак юлга басмый. Нух галәйһиссәлам үз халкын ун гасырга якын дингә чакыра, ягъни бу вакыт эчендә кешеләр генә түгел, хәтта ташлар яки агачлар да иман китерә алган булыр иде. Әмма озак вакыт дәгъват алып баруга да карамастан, бу халыкның нибары берничә дистәсе генә иман китерә. Мөфәссирләрнең аңлатма бирүләренә караганда, Нух галәйһиссәлам халкыннан бары сиксән кеше генә динне кабул итә. Кайбер

мөфәссирләр исә, Нух галәйһиссәламнең чакыруы белән сигез кеше генә Аллаһыга инанган дип саный.

Пәйгамбәрнең сүзләрен инкяр итү белән генә чикләнмичә, кешеләр Нух галәйһиссәламнең дошманнарына әвереләләр, аның тырышлыкларына һәм дәгъват эше алып баруына каршы киләләр.

Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

كَذَّبَتْ قَبْلَهُمْ قَوْمُ نُوحٍ فَكَذَّبُوا عَبْدَنَا وَقَالُوا مَجْنُونٌ وَازْدُجِرَ ﴿٩﴾

**«Мөхәммәд галәйһиссәламнән элек Нух кавеме, Безнең колыбыз – Нух пәйгамбәрне ялганга тоттылар вә: «Нух мәҗнүн, дивана», – диделәр. Кяферләр Нухны артык җәберләүләре сәбәпле, ул аларны дингә өндәүдән тыелды, туктады».**

«Камәр / Ай», 54:9

Башка бер аятьтә түбәндәгечә язылган:

قَالُوا لَئِن لَّمْ تَنتَهِ يَا نُوحُ لَتَكُونَنَّ مِنَ الْمَرْجُومِينَ ﴿١١٦﴾

**«Әйттеләр: «И Нух! Әгәр дә ваз кичмәсәң, таш атылганнардан булырсың».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:116

Әмма Нух галәйһиссәлам аларның янауларына бер дә игътибар итми. Бу басым һәм янаулар аның рухын сындырмый, ихтыяр көчен бетерми, ул кешеләргә Аллаһы Тәгаләдән алынган ачышны җиткерергә омтыла. Ул халыкны дингә чакырып өйдән өйгә йөри. Ишек аша:

– Кем бар? – дип сорыйлар.

Нух галәйһиссәлам:

– Бу – Нух. Аллаһыдан башка бүтән хак илаһ булмаганга һәм мин – Аның илчесе булуына иман китерегез, – дип әйтә.

Бу сүзләрне ишеткәч, күп илаһка ышанучылар Нух галәйһиссәламне мыскыллый торган булалар. Әмма, моңа да карамастан, Нух галәйһиссәлам төшенкелеккә бирелмичә, йорттан йортка йөрүен, халыкны һидаять юлына чакыруын дәвам итә.

Потларга табынучылар Нух галәйһиссәламнең үз дәгъватыннан баш тартмавын күреп, аңа ташлар аталар. Пәйгамбәргә атылган ташлар шулкадәр күп була ки, хәтта зур булмаган калкулык барлыкка килә һәм Нух галәйһиссәлам әлеге ташлар астында кала. Күп илаһка табынучылар: «Мөгаен, ул үлгәндер. Ниһаять, без аннан котылдык», – дип уйлап, өйләренә таралышалар.

Әмма Аллаһы теләмәсә, кеше кемне дә булса үтерә аламыни? Берникадәр вакыт узганнан соң, Нух галәйһиссәлам аңына килә, ташлар өеменнән чыгып, үзенең дәгъват эшен – тагын йорттан йортка йөрүен дәвам итә. Шулай итеп Нух галәйһиссәлам ару-талуны белмичә күп гасырлар дәвамында кешеләрне иманга һәм дингә чакыра. Кайвакыт күңеле төшеп Аллаһыга ялвара: «И Раббым! Һичшиксез, мин көне-төне кавемемне дәгъват кылдым. Әмма минем дәгъватым аларның ачуларын гына арттырды. Дәгъват иткән саен, алар колакларын капладыр, киемнәренә төренделәр, үҗәтлек күрсәттеләр һәм масаеп, тәкәбберләнделәр», – дип әйтә.

Ләкин Нух галәйһиссәлам, аның халкы иман китермәсә дә, башка буын вәкилләре иман китерәчәгенә ышана. Әмма яңа буын вәкилләре тагын да ныграк монафикълык һәм дингә ышанмаучанлык күрсәтә. Алар хакыйкатьне кабул итмичә, потларга табынуларын дәвам итә. Берничә гасыр дәвамында исламны аңлатуына һәм халыкны иманга чакыруына карамастан, Нух галәйһиссәлам үз халкында иман билгеләрен һәм күңелләре йомшаруны күрмәгәч, Аллаһыга ярдәм сорап дога кыла. Кавем халкы исә: «Әгәр син дөресен сөйлисең икән, безгә илаһыңның нәрсә белән янавы турында әйт», – диләр. Нух: «Теләсә, аны сезгә Аллаһы гына

китерә ала. Ул – Раббыгыз. Һәм Аңа гына кайтарылачаксыз», – дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә бу кавемнең тәкәбберлеге өчен җәзалар җибәреп тора: берничә ел рәттән корылык булып, аларның барлык мал-мөлкәте, терлекләре һәлак була, бакчалары кибә, кисәк кенә туучылар саны кими. Алар мохтаҗлык кичерә һәм ярлылыкта яши башлый. Әмма барыбер иман китермиләр, буйсынмаучанлыкларын тагын да арттыралар. Хәтта Нух галәйһиссәламне үтерү белән куркыталар.

## Нух галәйһиссәлам көймә төзү эшенә керешә

Нух галәйһиссәлам үз кавеменең иман китермәячәген аңлый. Шул чакта ул кулларын күккә күтәреп, үзенең дога кылу хокукын файдалана. Ул моңа кадәр килгәннәрнең берсе дә кылмаган дога кыла. Бу бәддога була. Нух галәйһиссәлам җирдәге кяферләрнең барысын да юкка чыгаруны сорый. Бу хакта Коръәндә түбәндәгечә бәян ителә:

وَقَالَ نُوحٌ رَّبِّ لَا تَذَرْ عَلَى الْأَرْضِ مِنَ الْكَافِرِينَ دَيَّارًا ﴿٢٦﴾ إِنَّكَ إِن
تَذَرْهُمْ يُضِلُّوا عِبَادَكَ وَلَا يَلِدُوا إِلَّا فَاجِرًا كَفَّارًا ﴿٢٧﴾

**«Нух әйтте: «И Раббым! Җир йөзендә кяферләрдән яшәү урыннарында беркемне дә исән калдырма! Чөнки Син аларны калдырсаң, Синең колларыңны адаштырырлар. Алар кяфер һәм гөнаһлы кешеләрдән башка беркемне дә тудырмаслар».**

«Нух», 71:26-27

Аллаһы Тәгалә бу доганы кабул итә, кяферләрнең юкка чыгуын тели, һәм Нух галәйһиссәламгә кирәкле күрсәтмәләр бирә:

وَاصْنَعِ الْفُلْكَ بِأَعْيُنِنَا وَوَحْيِنَا وَلَا تُخَاطِبْنِي فِي الَّذِينَ ظَلَمُوا ۚ إِنَّهُم مُّغْرَقُونَ ﴿٣٧﴾

**«Безнең саклавыбыз белән һәм вәхиебез белән көймә яса. Золым кылган кешеләр өчен исә Миннән сорама. Һичшиксез, алар суга батырылачаклар».**

«Һуд» 11:37

Шулай итеп, Нух галәйһиссәлам, иман әһелләре белән бергә, көймә төзү эшенә керешә. Әлбәттә, Нух галәйһиссәлам көймәне ничек төзергә кирәк икәнлеген белми. Аны Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәлам аша өйрәтә.

Ул вакытта агачлар бик күп булган, чөнки әйләнә-тирәдә зур һәм биек урман үскән. Нух галәйһиссәлам урманга киткән һәм көймә төзү өчен агачлар кисә башлаган. Нух галәйһиссәлам киселгән агачларны ботаклардан һәм кайрылардан чистарткан, һәм әлеге көймәне җыярга керешкән.

Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Нух галәйһиссәлам көймәнең тышкы ягын юка такталар белән тышлый. Аннары көймәнең эчен һәм тышын яхшылап сумала белән эшкәртә.

Өч катлы көймәнең зурлыгы киңлеккә илле аршын, озынлыкка өч йөз аршын һәм биеклеккә утыз аршын була. Иң аскы катта хайваннар, уртадагы катта кешеләр, ә иң өске катта кошлар урнаша. Нух галәйһиссәлам көймә төзелешенә бар көчен һәм вакытын бирә. Халкын үгетләүдән туктый, әмма халык үзе аны тынычлыкта калдырмый, мыскыллы караш белән болай дип әйтәләр:

– И Нух! Сиңа ни булды? Хәзердән син безнең белән сөйләшмисең һәм Раббыңның әмерләрен аңлатмыйсың. Син урманда агачлар кисәсең

һәм көймә төзисең. Синең өчен хәзер пәйгамбәрлек вазифасы авыр була башлады һәм син хәзер балта остасы булдыңмы?

Кайберәүләр: «Кем инде көймәне тау башында төзи? Аны яр буенда төзиләр. Мөгаен, ул акылдан шашкандыр», – диләр. Ахыр чиктә, Нухны мыскыллап, көймәгә килеп үз хаҗәтләрен үтиләр.

Әмма Аллаһы тарафыннан әлеге кавемгә бирелгән вакыт кимегәннән-кими барган һәм җәза мизгелләре тагын да якынлашкан.

Көймә бик тиз төзелә. Мөэмин-мөселманнарны мыскыллаган әлеге имансыз халыкка Аллаһы Тәгалә авырулар җибәрә, аларның тәннәрендә җәрәхәтләр һәм яралар барлыкка килә. Табиблар һәм дәвалаучылар әлеге авырудан дару таба алмыйлар, нинди генә дару кулланып карасалар да, ул шифа китерми. Әлеге яра һәм җәрәхәтләрдән бердәнбер дәва булып кешеләр үзләре көймәне пычраткан нәҗес торган.

Галәмәт хәл! Әлеге бозык халык өчен Аллаһы Тәгалә көймәне үзенчәлекле дарухanә итә, алар барысы да әлеге көймәгә барырга омтылалар, көймәгә килеп, үз нәҗесләрен яраларына сөртәләр, шулай итеп көймәне яхшылап чистарталар.

## Су басу

Көймәне төзү эшләре төгәлләнгәч, Аллаһы Тәгаләдән әмер килә:

حَتَّىٰ إِذَا جَاءَ أَمْرُنَا وَفَارَ التَّنُّورُ قُلْنَا احْمِلْ فِيهَا مِن كُلٍّ زَوْجَيْنِ اثْنَيْنِ
وَأَهْلَكَ إِلَّا مَن سَبَقَ عَلَيْهِ الْقَوْلُ وَمَنْ آمَنَ ۚ وَمَا آمَنَ مَعَهُ إِلَّا قَلِيلٌ ﴿٤٠﴾

**«Әмеребез килгәч һәм тандыр кайнап чыккач, Без: «Һәрбереннән икешәрне һәм, сиңа каршы сүз әйтелгәннәрдән тыш, гаиләңне һәм иман китергән кешеләрне керт», – дидек. Аның белән исә бик аз гына кеше иман китерде».**

«Һуд» 11:40

Әлеге әмер дә үтәлеп бетә, көймәгә утырту тәгәлләнә. Билгеләнгән сәгать җиткәч, җирдән сулар бәреп чыга, шулай ук күктән көчле яңгырлар ява башлый. Моңа кадәр күрелмәгән коточкыч көчле яңгырлар яуганда күк капусы ачылган кебек була. Бар җирдә чишмәләр бәреп чыга. Җир һәм күк сулары бергә кушылалар, су бик нык күтәрелә башлый.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَفَتَحْنَا أَبْوَابَ السَّمَاءِ بِمَاءٍ مُّنْهَمِرٍ ﴿١١﴾ وَفَجَّرْنَا الْأَرْضَ عُيُونًا فَالْتَقَى الْمَاءُ عَلَىٰ أَمْرٍ قَدْ قُدِرَ ﴿١٢﴾

**«Без күкнең су коелган капкаларын ачтык. Җирне ярып, аннан чишмәләр аттырдык, шулай итеп сулар тәкъдир ителгән бер эш өчен кушылдылар».**

«Камәр / Ай», 54:11-12

Су биеклеге тау очына җитә, күпләгән таулар су астында кала. Бер риваять буенча, су тирәнлеге иң биек таудан сиксән миль биеклеккә югары күтәрелә, дип әйтелә. Шулай итеп, әлеге су басу бөтен дөнья буенча булган, хәтта бер уч та коры җир калмаган.

Нух галәйһиссәламнең дүрт малаеның өчесе – Хам, Сам һәм Йәфис үз әтисенә иман китерә һәм алар белән көймәгә керә. Әмма дүртенче улы – Кенан (Ям) иман китерми. Нух галәйһиссәлам мөэминнәр белән көймәгә кергәч, Кенан читтә калган. Нух галәйһиссәлам аны чакыра:

وَهِيَ تَجْرِي بِهِمْ فِي مَوْجٍ كَالْجِبَالِ وَنَادَىٰ نُوحٌ ابْنَهُ وَكَانَ فِي مَعْزِلٍ يَا بُنَيَّ ارْكَب مَّعَنَا وَلَا تَكُن مَّعَ الْكَافِرِينَ ﴿٤٢﴾

**«Ул таулар кебек дулкыннар эчендә алар белән кузгалып киткәч, Нух аерым бер җирдә булган улына: «И улым! Безнең белән бергә утыр, кяферләр белән бергә булма», – дип эндәште».**

«Һуд» 11:42

Ул үз улына көймәгә керергә куша. Бу әти кешенең һәм пәйгамбәрнең үтенече була, чөнки ул соңыннан ни буласын, көймәгә менүчеләрдән тыш, бар халык та батып үләчәген һәм Ахирәттә алар мәңгелек җәһәннәмдә яначагын яхшы аңлаган. Шуңа күрә хәтта иң соңгы мизгелдә дә Нух галәйһиссәлам үзенең имансыз улын дингә чакыра һәм көймәгә керергә тәкъдим итә. Әмма ул динсезлегендә нык тора һәм тәкъдимне кире кага. Ул бер коры җирдә калып котылып булыр дип уйлый. Әмма су басу алты ай дәвам итә. Мөэминнәр раҗәб аеның унынчы көнендә көймәгә керәләр. Һәм алты ай йөзгәннән соң, мөхәррам аеның унынчы көнендә (Гашурә көнендә) су кими башлый, һәм көймә Җуди тавында туктап кала.

Әлеге су басу Нух галәйһиссәламнең догасы сәбәпле барлыкка килә. Әмма әлеге халык үзе дә җәзага лаек була, чөнки алар мең елга якын чакыруларны һәм нәсыйхәтләрне кабул итмиләр, алар динсезлектә үзсүзле булуларын дәвам итәләр, пәйгамбәрләренә төрле авырлыклар китерәләр.

Су басудан көймәгә кереп исән калган кешеләр саны буенча төрле риваятьләр бар. Шуларның берсе буенча, көймәгә кырык ир-ат һәм кырык хатын-кыз, ягъни сиксән кеше кергән. Башка риваять буенча, көймәдә бары сигез кеше булган. Алар Нух галәйһиссәламгә иман китергәннәр һәм хак динне кабул иткәннәр, аннары су басуны кичереп, иминлеккә ирешкәннәр. Шулай итеп, кешеләрнең яңа буыны Нух галәйһиссәлам өммәтеннән килеп чыккан һәм җир шары буйлап таралган. Бер риваять буенча, кешеләрнең яңа буыны Нух галәйһиссәлам улларыннан дәвам иткән:

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَنَجَّيْنَاهُ وَأَهْلَهُ مِنَ الْكَرْبِ الْعَظِيمِ ﴿٧٦﴾ وَجَعَلْنَا ذُرِّيَّتَهُ هُمُ الْبَاقِينَ ﴿٧٧﴾

**«Аны да, гаиләсен дә олы хәсрәттән коткарган идек. Без аның нәселен калучылардан иттек».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:76-77

Әлеге аятьне укып, Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм сакланган буыннар турында Хам, Сам, Йәфисны күздә тотуы хәбәр ителә.

Раббыбыз бер аятьтә болай дип әйтә:

وَلَقَد تَّرَكْنَاهَا آيَةً فَهَلْ مِن مُّدَّكِرٍ ﴿١٥﴾ فَكَيْفَ كَانَ عَذَابِي وَنُذُرِ ﴿١٦﴾

**«Без аны (ул көймәнең истәлеген бик озак вакыт) бер билге буларак калдырдык, ләкин үгет алучылар бармы? Минем газабым һәм кисәтүләрем нинди булды соң?!»**

«Камәр / Ай», 54:15-16

«Без аны бер билге буларак калдырдык», дигән сүзләр шушы су басуның эзләре калачагын һәм кешеләргә аннан гыйбрәт алырга кирәклеген кисәтеп куя. Шуңа бу аятьтә су басуны өйрәнү өчен археологик эзләнүләр алып барылырга тиешлеге хакында да әйтелә. Аның төгәл датасы безгә билгеле булмаса да, сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрнең берсендә болай дип әйтелә:

«Адәм галәйһиссәлам белән Нух галәйһиссәлам арасында ун кам (буын, гасыр, чор) үткән».

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

## 88. Әл-Гашия (Каплап алучы) сүрәсе

Мәккә чоры, 26 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем! Кешеләрне авырлыклар белән) **Каплап алучының хәбәре сиңа ирештеме?**
2. **Чырайлар ул көнне кимсетелгән хәлдә.**
3. (Җәһәннәмдә) **Эшлиләр һәм** (балчыкка баткан дөяләр кебек утка кереп) **алҗыйлар.**
4. **Кызу утка керәчәкләр.**
5. **Кайнап торган чишмәдән эчереләчәкләр.**
6. **Аларга даригътан** (үләксәдән дә шакшырак, уттан да кызурак чәнечкеләрдән) **башка бер ашамлык юк.**
7. **Ул тамак та туйдырмый, ачлыктан да файда бирми.**
8. **Башка йөзләр ул көнне сөенечле.**
9. (Дөньядагы) **Тырышлыкларыннан канәгать.**
10. **Югары җәннәттә.**
11. **Алар анда буш нәрсә ишетмәячәкләр.**
12. **Анда агып торган чишмә бар.**
13. **Анда югары тәхетләр бар.**
14. (Алларына) **Куелган кадәхләр дә.**
15. (Өсләренә утырылсын, таянылсын дип тирә-якка) **Тезелгән ястыклар да.**
16. **Таратып җәелгән келәмнәр дә.**
17. (Мөшрикләр) **Дөяләргә карамадылармы,** (биек итеп, һәр үсемлекне ашый һәм ун көннән артык сусыз тора алырлык итеп) **ничек яралтылдылар.** (Менә дөяләр үзләренә атландырыр өчен чүккәннәре кебек, тәхетләр дә мөэминнәр өчен шулай итәчәкләр)
18. **Күккә дә** (карамадылармы)**, ничек ул** (терәксез бер шәкелдә) **күтәрелде.**
19. **Тауларга да** (карамадылармы)**, ничек беркетелде.**

20. **Җиргә дә** (карамадылармы)**, ничек түшәлде.**
21. (Расүлем! Аларның бу аятьләрне уйлауларына йә уйламауларына карамастан) **Үгет бир, чөнки син – хәтерләтүчесең генә.**
22. **Син алар өстендә хаким түгелсең.**
23. **Ләкин кем дә кем** (синең бу үгетләреңнән) **йөз чөерә һәм инкяр итә.**
24. **Аллаһ аны каты газап белән җәзага дучар итәчәк.**
25. **Һичшиксез,** (үлемнәреннән соң) **кайтулары – Безгә.**
26. **Шуннан соң** (мәхшәрдә) **хисапларын да Без алачакбыз.**

## 89. Әл-Фәҗр (Таң) сүрәсе

Мәккә чоры, 30 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Иртән агарып килгән) **Таң белән ант итәмен!**
2. (Зөлхиҗҗәнең башындагы) **Ун төн белән дә** (ант итәмен)**!**
3. **Җөп һәм так белән дә** (ант итәмен)**!**
4. **Һәм үтеп барган төн белән** (ант итәмен)**!**
5. **Акыл иясе булганнар өчен бу антлар җитәрлек түгелме?**
6. (Расүлем!) **Күрмәдеңме, Раббың** (Һудның (галәйһиссәлам) инкяр итүче кавеме булган) **гадне нишләтте.**
7. (Биек-биек биналарда) **Баганаларга ия** (мәһабәт биналарның хуҗасы булган халык) **Ирәмне.**
8. **Шәһәрләрдә аларга тиң** (көчтә һәм зурлыкта бер халык та) **яралтылмаган иде**[1]**.**

---

1 Риваятьтән күренгәнчә, Гаднең Шәддад һәм Шәдид исемле ике улы булган, алар залимнәрчә хакимлек иткәннәр. Шәдиднең үлеменнән соң дөнья хөкемдарлыгы Шәддадка калган. Ул җәннәт турында ишеткәч: «Мин дә шундый бер урын ясаячакмын!» – дип, Гадән сахраларының берсендә өч йөз елда шундый бер зур шәһәр төзеткән ки, манаралары – алтыннан һәм көмештән, колонналары – зөбәрҗәттән һәм якуттан, эчендә төрле-төрле агачлар һәм елгалар булган. Шәһәр төзелеп беткәч, Шәддад мәмләкәтенең халкы белән бергә анда барырга дип юлга чыккан, бер көн һәм бер төнлек юлны

9. (Шам тирәсендәге Кура дигән) **Үзәнлектә кыяларны уйган** (бозык) **сәмудне** (Раббың нишләткәнен күрмәдеңме)**?**

10. (Гаскәренең күплеге сәбәпле сансыз чатырларга) **Казыкларга ия** (булган, җәфалыйсы кешеләрне кул һәм аякларыннан казыкка бәйләгән) **фиргавенне дә.**

11. **Алар шәһәрләрдә** (бозыклык кылуда) **чиктән ашканнар иде.**

12. **Анда бозыклык** (көферлек һәм золым) **арттырдылар.**

13. **Шул сәбәпле Раббың аларга** (төрле-төрле) **газаплар** (яудырып) **койды.**

14. **Һичшиксез, синең Раббың** (урыннан пакь булган хәлдә, колларының гамәлләрен) **яшерен күзәтеп тора.**

15. **Әмма** (кяфер) **кеше** (Раббысының күзәтүе астында булуын һич уйламыйча) **Раббысы аны сынап** (күп мал биреп) **хөрмәтләгән һәм нигъмәт биргән чакта** (шөкер итәсе урында масаеп һәм Аллаһының нигъмәтен дөнья малының күплегендә күреп)**: «Раббым миңа хөрмәт күрсәтте** (чөнки мин моңа лаекмын)**!» – дип әйтә.**

16. **Әмма аны сынап, ризыгын тарайткан чакта: «Раббым мине хур итте!» – дип әйтә.**

17. **Юк! Сез ятимгә хөрмәт күрсәтмисез** (һәм аңа мирастан өлеш чыгармыйсыз)**.**

18. **Бер-берегезне мескенне ашатырга өндәмисез.**

19. (Хәләл-харам димичә, мал җыеп) **Комсызланып, мирасны ашыйсыз.**

20. **Малны чиксез яратасыз.**

21. **Юк!** (Бу гамәлләрегез бер дә яхшы түгел!) **Җир тузанга әйләнгәч** (һәм өстендә калкып торган берни дә калмагач)**.**

22. **Раббың ирадәсе һәм** (һәр кат күктәге) **фәрештәләр саф-саф**

---

узгач, Аллаһы Тәгалә күктән җибәргән көчле тавыш белән барысы бергә һәлак булганнар (Нәсәфи, Бәйдави, Хазин).

(тезелгән) **хәлдә** (мәхшәргә) **килгәч.**

23. **Шул көнне җәһәннәм** (һәрбереннән җитмеш мең фәрештә тоткан җитмеш мең тезген белән тартып) **китерелер. Ул көнне кеше** (дөньяда кылган гөнаһларын) **хәтерләячәк. Әмма ул хәтерләү аңа нигә кирәк?**
24. **Ул: «Аһ, мин бу** (мәңгелек) **тормышым өчен** (дөньяда изге гамәлләр белән) **әзерләнсә идем!» – диячәк.**
25. **Ул көнне Ул җәзаландырган кебек беркем дә** (беркемне) **җәзага дучар итә алмаячак.**
26. **Һәм Ул салган кебек беркем дә** (беркемгә) **богау сала алмаячак.**
27. (Аллаһы Тәгалә хисап тәмамланган вакытта мөэмин колларына әйтәчәк) **И** (Мине искә алып, башка бернигә дә ихтыяҗ тоймаган) **тынычланган нәфес!**
28. (Нигъмәтләрдән) **Разый булган һәм** (Раббың хозурында гамәлләре кабул ителерлек булып) **разыйлык алган буларак Раббыңа кайт!**
29. **Кер** (изге) **колларым арасына!**
30. **Кер җәннәтемә!»**

## 90. Әл-Бәләд (Шәһәр) сүрәсе

Мәккә чоры, 20 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Шушы** (кагылгысыз) **шәһәр** (Мәккәи Мөкәррәмә) **белән ант итәмен!**
2. **Син бу шәһәрдә торучы.**
3. **Ата һәм ул тудырган кешеләр белән дә** (Адәм (галәйһиссәлам) һәм аның нәселе белән ант итәмен)**!**
4. **Һичшиксез, Без кешене михнәт эчендә яралттык.**

5. (Кяфер кеше) **Аңа беркемнең дә көче җитмәс дип уйлыймыни**[1]**?**
6. **Ул: «Мин** (Мөхәммәдкә дошманлык юлында) **исәпсез мал бетердем!» – дип әйтә.**
7. **Ул аны беркем дә күрмәде дип уйлыймыни?**
8. **Без аңа ике күз бирмәдекме?**
9. **Тел, ике ирен дә.**
10. **Янә аңа ике юл күрсәтмәдекме?**
11. **Әмма ул текә үргә менә алмады.**
12. (Расүлем!) **Текә үрнең ни икәнлеген син каян белә аласың?**
13. (Ул әсирлек бавы белән бәйләп куелган) **Муенны** (коллык бавыннан) **чишү.**
14. **Яки ачлык көнендә ашату.**
15. **Туганнардан булган ятимне.**
16. **Яки туфракка ябышкан бер мескенне.**
17. **Шуннан соң иман китергән, бер-берләрен сабырлыкка һәм** (Аллаһының колларына карата) **мәрхәмәтле булырга өндәүчеләрдән булырга кирәк.**
18. **Болар** (дәфтәрләрен уң кулларына алачак) **уң як кешеләре.**
19. **Әмма Безнең аятьләребезне инкяр иткән** (дәфтәрләрен сул кулларына алачак) **сул як кешеләре.**
20. **Аларның өсләрендә** (эченә һич һава кермәслек һәм аннан бер тавыш чыкмаслык) **Ут гөмбәзе булачак.**

---

1 Аяте кәримә Әбү әл-Әшүдд исемле бер кяфер хакында иңгән. Ул аягы астына бозылмаган, яхшы тире кисәге сала торган булган, ун кеше аны тарткалауга карамастан, аяклары астындагы тире теткәләнеп аягы баскан кисәк кенә калганчы, аны беркем дә урыныннан кузгата алмаган. Менә шушы көченә ышанып, ул Расүлуллаһка (саллəллаһу галәйһи вә сәлләм) бик күп дошманлыклар кылган һәм, Кыямәт куба калса да, беркем дә аңардан үч алу көченә ия түгел дип санаган (Алуси).

## 91. Әш-Шәмс (Кояш) сүрәсе

Мәккә чоры, 15 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Кояш һәм аның балкышы белән ант итәмен!**
2. **Аңа ияргән ай белән дә** (ант итәмен)**!**
3. **Аны чагылдырган чактагы көн белән** (ант итәмен)**!**
4. **Аны каплаган чактагы төн белән** (ант итәмен)**!**
5. **Күк һәм аны** (терәксез) **бина итүче** (чиксез кодрәт иясе булган Зат) **белән** (ант итәмен)**!**
6. **Җир һәм аны түшәүче** (тиңсез куәт иясе булган Зат) **белән** (ант итәмен)!
7. (Адәмнеке (галәйһиссәлам) булган) **Җан һәм аны** (сөйләшү, ишетү кебек сәләтләргә ия сурәттә) **төзек кылучы** (Зат) **белән** (ант итәмен)**!**
8. **Һәм аның күңеленә бозыклыкны һәм тәкъвалыкны салучы** (Зат белән)**.**
9. (Шушындый әһәмиятле нәрсәләр белән ант итәмен, нәфесен яхшы якка үзгәртеп, гөнаһлардан ерак тотып) **Аны арындырган кеше уңышка ирешкән.**
10. **Аны** (фасикълык баткаклыгы эчендә) **яшергән кеше зарар күргән.**
11. (Салихның (галәйһиссәлам) кавеме булган) **Сәмуд, чиктән ашканлыклары сәбәпле,** (кыядан чыгарган дөя аятен) **ялган дип санады.**
12. **Менә иң яманнары** (булган Кудар бине Салиф дөяне үтерү нияте белән) **хәрәкәткә күчте.**
13. **Аллаһының расүле аларга: «Аллаһының теше дөясенә, аның эчәсе суына** (кагылмагыз)**!» – диде.**
14. **Әмма алар ялган дип санадылар һәм аякларын кисеп, аны бугазладылар. Гөнаһлары сәбәпле Раббылары** (газапны) **алар өстенә каплады һәм ул урынны** (алар белән бергә) **тигезләде.**
15. **Моның нәтиҗәсеннән курыкмаган рәвештә.**

## 92. Әл-Ләйл (Төн) сүрәсе

Мәккә чоры, 21 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Көнне) **Каплаган вакыттагы төн белән ант итәмен!**
2. (Кояшның чыгуы белән) **Яктырган чактагы көн белән дә** (ант итәмен)**!**
3. **Ир һәм хатын җенесен яралтучы** (бөек кодрәт иясе булган Зат) **белән дә** (ант итәмен)**!**
4. **Һичшиксез, сезнең омтылышларыгыз төрле.**
5. **Кем дә кем** (зәкят кебек хакларны мохтаҗларга) **бирә һәм** (харамнардан) **саклана.**
6. **Һәм күркәм булганны** (җәннәтне, кәлимәи тәүхидне) **таный.**
7. **Без аны иң җиңел булганга** (эчендә мәңге рәхәтлеккә калачак җәннәтне казандырасы эшләргә) **җиңел генә әзерләрбез.**
8. **Кем дә кем саранлана һәм** (байлыгы сәбәпле) **үзен ихтыяҗсыз саный.**
9. **Кем күркәм булганны** (җәннәтне, тәүхид кәлимәсен һәм Исламны) **ялган дип саный.**
10. **Без аны иң авыр булганга** (һәм эчендә мәңге газап күрәчәк җәһәннәмгә дучар итәсе бозыклыкларга) **җиңел генә әзерләрбез.**
11. **Һәлак булгач исә малы аңа файда китермәячәк.**
12. (Пәйгамбәрләр җибәреп халыкны хакка ирештерү һәм) **Һидаять итү – Безнең Үзебездән генә.**
13. **Соңгы да, Әүвәлге дә Безнеке бит.** (Шуңа күрә Без ике җиһанда да теләгәнебезгә теләгәнебезне бирәбез.)
14. (И, коллар! Раббыгыз буларак) **Мин сезне ялкынлы уттан кисәтеп куямын.**
15. **Аңа иң начар булганнар гына** (мәңге калыр өчен) **керәчәкләр.**
16. **Шулар ки, кемнәр** (пәйгамбәрләрне һәм алар алып килгәннәрне) **ялган дип санийлар һәм** (гыйбадәттән) **йөз чөерәләр.**

17. (Ширектән һәм гөнаһлардан сакланып) **Тәкъва булган кеше** (җәһәннәмдә мәңге калу түгел, аңа һич кермәячәк һәм) **аңардан ерак тотылачак** (ул аның тавышын, хәтта сулышын да ишетмәячәк)**.**
18. **Ул малын** (гөнаһлардан) **арыну өчен бирә.**
19. **Ул игелекне беркемгә дә** (үзенә эшләнгән игелеккә түләү) **җавап буларак кына эшләми.**
20. **Бары** (ул бу игелекне) **Олуг булган Раббысына омтылыр өчен** (эшли)**.**
21. **Һәм ул канәгать булачак**[1]**.**

## 93. Әд-Духәә (Иртә) сүрәсе

Мәккә чоры, 11 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Кояш күтәрелә торган) **Иртә белән ант итәмен!**
2. **Һәм куерган вакыттагы төн белән** (ант итәмен)**!**
3. **Раббың сине ташламады һәм** (сиңа) **ачуланмады да**[2]**.**
4. **Һичшиксез, соңгы** (тормыш) **синең өчен әүвәлгесеннән яхшырак.**
5. **Раббың сиңа** (дөньяда да, Ахирәттә дә) **бирәчәк, һәм син канәгать булачаксың.**
6. **Раббың синең ятим калганыңны күреп сыендырмадымы?**
7. **Сине** (балачагыңда) **югалган килеш табып,** (дин хөкемнәре биреп) **һидаять итмәдеме?**

1 Бу аяте кәримәләрдә әйтелгән «иң бәхетсез кеше» – йә Әбү Җәһел, йә Үмәййә ибне Хәләф. «Иң тәкъвалык иясе зат» исә – Әбү Бәкер (радыйаллаһу ганһ). Монда аның мөшрикләр тарафыннан җәфа күргән фәкыйрь сәхабәләрне, бигрәк тә Билалны (радыйаллаһу ганһ), бернинди шәхси мәнфәгать көтмичә, фәкать Аллаһ ризалыгы өчен сатып алып, азат итүе турында сүз бара. (Бәйдави, Нәсәфи)

2 Риваятьтән күренгәнчә, Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) мөшрикләрнең кайбер сорауларына иртәгә җавап бирәчәген әйткән, ләкин вәхинең килүе озакка сузылгач, алар: «Раббысы Мөхәммәдне калдырды һәм аңа ачуланды!» кебек сүзләр әйтә башлаганнар. Бу аяте кәримәләрне иңдереп, Аллаһы Тәгалә Хәбибен юаткан. (Бәйдави, Нәсәфи)

8. **Янә сине фәкыйрь буларак табып,** (Хәдичәнең малы белән) **бай итмәдеме?**
9. **Шулай булгач,** (көчсез булуы сәбәпле, малы өчен) **ятимне җәберләмә.**
10. (Кул сузып) **Сораучыны куып җибәрмә.**
11. **Әмма Раббыңның** (биргән Коръән һәм башка хөкемнәре кебек) **нигъмәте турында сөйлә.**

## 94. Әш-Шарх (Ачылу) сүрәсе

Мәккә чоры, 8 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем!) **Без синең** (дәгъват кылу кебек вазифаны күтәрә алуың өчен) **күкрәгеңне киңәйтмәдекме?**
2. **Һәм синнән авыр йөгеңне алмадыкмы?**
3. **Ул бит аркаңны баскан иде.**
4. **Без синең исемеңне күтәрдек.** (Шул сәбәпле, кәлимәи шәһадәт, азан, камәт, хотбә, тәхият кебек бик күп җирдә Минем белән бергә телгә алынасың)
5. **Һичшиксез,** (чиккән һәр) **авырлыктан соң җиңеллек бар.**
6. **Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар.**
7. **Шулай булгач,** (ирештерү һәм намаз кебек вазифаларыңнан) **бушаган чагыңда** (игелек кылырга) **тырыш.**
8. **Һәм Раббыңа омтыл.**

## 95. Әт-Тин (Инҗир) сүрәсе

Мәккә чоры, 8 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Бихисап файдалары булган) **Инҗир һәм зәйтүн белән ант итәмен!**
2. **Һәм** (Мусаның (галәйһиссәлам) Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү урыны булган мөбарәк) **Синадагы Тур** (тавы) **белән** (ант итәмен)**!**
3. **Һәм шушы имин шәһәр** (булган Мәккәи Мөкәррәмә) **белән** (ант итәмен)**!**
4. **Без кешене иң күркәм сурәттә ералттык.**
5. **Шуннан соң** (бу шәкелдә күркәм яратылыш нигъмәтенә шөкер итмәгәне өчен) **аны** (җәһәннәм әһеленнән итеп, күрер күзгә) **түбәннәрнең иң түбәне булганга кайтардык.**
6. **Бары иман** (шартларының барысына да шиксез иман) **иткән һәм** (намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек) **изге гамәлләр кылучылар булмасалар гына. Аларга исәпсез әҗер бар.**
7. (И, кяфер кеше!) **Моннан соң нәрсә сине** (Ахирәттәге) **Җәза көнен ялган дип саната ала?**
8. **Хөкем бирүчеләрнең иң дөрес хөкем биргәне Аллаһы түгелме?** (Эш болай икән, Кыямәт көнендә коллар арасында тиешле хөкемне Ул бирәчәк.)

# Ураза

# Уразага кагылышлы мәсьәләләр

**С.:** Ислам динендә уразаның хөкеме нинди?

**Җ.:** Рамазан аенда ураза тоту һәрбер балигълыкка ирешкән мөселманга – фарыз. Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

> **«И мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

**Р**амазан аеннан тыш башка айларда уразаны үз теләгең белән тотып була. Әгәр инде нәфел уразасына ният кылсаң, аны тотып бетерү вәҗиб.

**С.:** Телдә вә шәригатьтә уразаның мәгънәсе нинди? Ураза кайчан башлана һәм кайчан тәмамлана?

**Җ.:** Телдә «ураза» сүзе («әс-саум») «нәрсәдән дә булса тыелып торуны», ә шәригатьтә, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, таңнан алып кояш батканчыга кадәр ашаудан, эчүдән, якынлык кылудан тыелып торуны аңлата.

**С.:** Рамазан аенда кемгә дә булса ураза тотмаска рөхсәт ителәме?

**Җ.:** Әгәр дә кеше мосафир хәлендә булса яки, авыру булып, ураза сәбәпле авыруы көчәюдән курыкса, ураза тотмаса да ярый. Тик соңыннан калган уразаларны каза итеп тоту вәҗиб. Әгәр мосафирга ураза тотудан зыян килмәсә, ураза тоту хәерлерәк.

**С.**: Әгәр дә мосафир яки авыру уразасын каза кылмыйча үлеп китсә, алар өчен нинди дә булса юл белән түләү кирәкме?

**Җ.**: Юк, кирәкми.

**С.**: Тагын кемнәргә Рамазан аенда ураза тотмаска рөхсәт ителә?

**Җ.**: Авырлы, бала ашатучы хатыннарга, әгәр дә алар сәламәтлекләренә яисә балалары сәламәтлегенә зыян китерүдән курыксалар, ураза тотмаска рөхсәт ителә. Ахырдан шулай ук каза кылу вәҗиб була.

**С.**: Кемгә Рамазан аенда ураза тоту тыела?

**Җ.**: Күрем күргән, нифаслы хатыннарга ураза тоту тыела. Пакьләнгәч, шул көннәр өчен каза кылырга тиеш булалар.

**С.**: Кемгә Рамазан аенда ураза тотмаган өчен каза вәҗиб булмый, ә фидия түләргә вәҗиб була?

**Җ.**: Ураза тотарга көченнән килмәгән карт кешегә фидия түләү – вәҗиб.

**С.**: Әгәр дә кеше мосафир яки авыру хәлендә булып, уразасын калдырса, каза кылырга вакыты булып та, каза кылудан әүвәл үлеме якынлашса, аңа бу вакытта нишләргә?

**Җ.**: Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенергә һәм үзенең вәкиленә һәр уразасын калдырган өчен 0,5 сагъ бодай яисә 1 сагъ хөрмә яки арпа бәясе кадәр акча биреп, мескеннәрне ашатырга васыять итәргә тиеш.

**С.**: Рамазан көнендә сабый балигъка ирешсә, кяфер ислам кабул итсә, аларга нишләргә?

**Җ.**: Аларга шул көнне һәм Рамазан аеның калган көннәрен тотып бетерергә кирәк.

**С.**: Алар калган көннәренә каза кылырга тиешләрме?

**Җ.**: Юк, тиеш түгел.

**С.**: Әгәр дә кеше ураза вакытында аңын югалтса, нишләргә?

**Җ.**: Әгәр берәү Рамазан аеның бер көнендә ураза тотарга ниятләп, бу көндә аңын югалтса, бу көнне каза кылырга кирәкми, ләкин ул аңында булган көннәрендә ураза тотарга тиеш.

**С.**: Әгәр мәҗнүн кеше Рамазанның бер көнендә акылына килсә, нишләргә?

**Җ.**: Калган көннәрендә уразаны тотып бетерергә, тотмаган көннәрен каза кылырга тиеш.

**С.**: Әгәр мосафирның сәфәре Рамазан көнендә бетсә, әмма ул бу көндә ураза тотарга ниятләмәгән булса һәм шулай ук хатын-кызның хәезе тәмамланса, нишләргә?

**Җ.**: Көннең калган өлешендә ураза тотарга кирәк.

**С.**: Рамазан аеның башы ничек билгеләнә?

**Җ.**: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Яңа ай күренү белән уразагызны тота башлагыз һәм яңа ай күренү белән уразагызны тәмамлагыз, әмма ай күренмәсә, ул чакта шәгъбан аен 30 көнгә кадәр тутырыгыз»[1].

**С.**: Ничә кеше яңа айны күрергә тиеш?

**Җ.**: Күк йөзе аяз булганда бер гадел кеше күрсә җитә, ир кеше яки хатын-кыз булса да – барыбер. Әгәр күк йөзе болытлы булса, ул чакта яңа айның тууын бер төркем кеше шаһитлык кылырга тиеш.

**С.**: Әгәр берәү яңа айны күрсә, ләкин имам аңа ышанмаса, нишләргә?

**Җ.**: Әгәр бу Рамазан башы икән, ул чакта үзенә генә ураза тотарга, әгәр Рамазан ахыры икән, кешеләр белән уразаны дәвам итәргә кирәк.

## Ниятләү шартлары

**С.**: Уразаны ниятләүнең мәгънәсе нидә?

**Җ.**: Ният – ул Аллаһы Тәгалә каршында нинди дә булса бер төр ураза тотуга калеб белән вәгъдә бирү.

Уразаның төрләре:

1. Рамазан аендагы фарыз ураза;
2. нәзер ителгән ураза;
3. кәффарәт уразасы (ант бозылган, кеше үтергән һәм башка очракларда);
4. Рамазан аенда тотмаган уразаларны каза кылу;
5. башка уразаларны каза кылу (нәфел уразаны бозган очракта);

1 Имам Әл-Бохари һәм имам Әл-Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

6. нәфел уразасы.

Рамазанда билгеле бер көндә вәгъдә ителгән уразаны, нәфел уразаны тотуга ниятләнгәндә ураза көненең киченнән алып өйләгә кадәр ният кылырга мөмкин. Билгеләнмәгән көндә, каза һәм вәгъдә ителгән кәффарәт уразалары өчен, кичен ниятләргә кирәк.

## Уразаны боза торган очраклар

**С.**: Кайчан ураза бозыла?

**Җ.**: Әгәр дә берәү нәрсә дә булса йотса (хәтта бик кечкенә күләмдә булса да), үпкән һәм назлаганда мәни чыкса (ләкин төш күргәндә түгел), әгәр борынына яки колагына дару тамызса, таң ата башлагач ашаса яки кояш баеган дип уйлап, ифтар кылса, соңыннан кояш баемаганлыгы ачыкланса, ураза бозыла һәм каза кылырга кирәк булачак.

**С.**: Әгәр женси әгъзада берничә тамчы сыекча күренсә, ураза бозыламы?

**Җ.**: Әбү Хәнифә һәм Мөхәммәд фикеренчә, юк, әмма Әбү Йосыф фикере буенча, бозыла.

**С.**: Гадәти яки мәҗбүри косканда ураза бозыламы?

**Җ.**: Әгәр мәҗбүри косык авызны тутырса, ураза бозыла, әмма гадәти косу булса, ураза үз көчендә кала.

**С.**: Кайсы очракларда ураза каза кылына һәм кәффарәт түләнелә?

**Җ.**: Алдан уйлап, җимагъ кылса, ашаса яки дару эчсә, каза кылына һәм кәффарәт түләнелә.

**С.**: Кәффарәт ничек түләнелә?

**Җ.**: Әгәр мөмкин булса, кол азат итәргә, моны булдыра алмаса, тоташ ике ай рәттән ураза тотарга, әгәр моны да булдыра алмаса, 60 мескенне ашатырга кирәк.

**С.**: Рамазан аеннан башка айлардагы ураза бозылса, кәффарәт түләнеләме?

**Җ.**: Юк.

### Ураза үз көчендә кала торган очраклар

Әгәр ураза тотучы үзенең ураза тотуын онытып, ашаса, эчсә, җимагъ кылса, поллюция күренеше булса, хатынына карап, мәни чыкса, мазь белән сөртенсә яки берәр нәрсәсе киселсә, сөрмә тартса, хатынын үпсә, ураза бозылмый.

### Ураза тотучыга мәкруһ гамәлләр

Ураза тотучыга, үзенең теләкләрен тотып тора алуына ышанмаса, үбешү – мәкруһ. Шулай ук берәр нәрсәнең тәмен татып карау, сагыз чәйнәү, порошок яки паста белән теш чистарту, берәр нәрсә белән алыштырып булганда, хатын-кызның баласына ризык чәйнәп бирүе – мәкруһ.

### Уразаны каза кылу

**С.**: Рамазан аеның каза уразаларын Рамазан ае беткәч үк каза кылырга кирәкме?

**Җ.**: Бу шарт булып килми, кайчан теләсә, шунда каза кылырга мөмкин.

**С.**: Әгәр кеше каза кылуын икенче Рамазан ае башына кадәр сузып килсә, аңа нишләргә?

**Җ.**: Әүвәл башланган Рамазанның уразасын тотарга, аннан соң калдырган көннәре өчен каза кылырга тиеш.

**С.**: Бер кеше үлгәннән соң, Рамазан аеннан каза уразалары калган булып, үзенең милкеннән кәффарәт түләргә васыять итеп калдырган булса, аның вәкиленә нишләргә?

**Җ.**: Мондый васыять үлгән кешенең милкеннән 1/3 өлешен алып түләнелә. Һәрбер калдырган көн өчен ярты сагъ бодай яки бер сагъ арпа, хөрмә белән бер мескенне ашатырга кирәк.

*Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни,*

*“Әт-тәсһил әд-дарури ли мәсәил*

*Әл-Кудури” китабыннан*

# Нәсыйхәт

# Үлем куркынычы һәм катылыгы бәяны

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе әйтүенчә, Мөхәммәд бине Фазыл үзенең иснәде белән Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Берәү Аллаһы Тәгаләгә юлыгуны, ягъни Ахирәт йортына кайтуны сөйсә, Аллаһы да аның белән очрашуны сөяр, аңа мәрхәмәтле булыр, аны күпсанлы нигъмәтләре белән бүләкләр. Ә инде Аллаһы белән очрашуны теләмәгән кеше белән Аллаһы Үзе дә очрашырга теләмәс. Дөреслектә, кяфер кеше үзенә әзерләнгән җәзаларны күргәннән соң, адашуда булганы өчен үкенер. Аллаһы аны Үзенең рәхмәтеннән һәм нигъмәтләреннән ераклаштырыр».

Имам Нәвәви радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Хәдиснең мәгънәсе: аларның Аллаһыга юлыгуны сөюе түгел, ә бәлки Аллаһы Тәгаләнең сөюенә сәбәптер. Янә аларның кәраһәте (нәфрәт тойгысы), ягъни мәкруһ күрүләре Аллаһының мәкруһ күрүенә сәбәп түгел, бәлки максат аларның сыйфатының бәяныдыр. Хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә аларга юлыгуны сөйгән вакытта, алар шуның белән Аллаһыга юлыгуны сөярләр». Имам Нәвәвинең сүзе шушында тәмам булды. Ул сүзнең ачыграгы шул, дөреслектә мәхәббәт – ул Аллаһы Тәгаләнең сыйфатыдыр. Колның Аллаһы Тәгаләгә булган мәхәббәте – ул Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәтенә иярүче стенага су күләгәсенең төшүе кебек, Аллаһының мәхәббәтеннән каршы төшкән күләгәдер. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән риваять ителгән нәрсә моны куәтле кыла. Ул болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә бер колын сөйсә, ул колны сөю белән күләгәләндерер. Коръәндә «йүхиббүһүм» дигән сүзне «йүхиббүнәһү»гә тәкъдимдә булучыдыр. Моңа ишарә, Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең сөюенә юлыгуны татытыр, безне сөю белән хөрмәтләр». Моннан соң сәхабәләр: «Әй Аллаһының Илчесе, без барчабыз

да үлемне мәкруһ күрәбез», – дип әйттеләр. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Бу мәкруһ күрү түгел, алай булса да мөэмин һәркайчан үлемгә әзерләнсә, Аллаһы Тәгаләдән ул кешегә изгелектән Аңа кайта торган нәрсә белән сөендерүче килер. Аның өчен Аллаһыга юлыгудан да сөеклерәк һич нәрсә булмас һәм Аллаһы Тәгалә дә ул кешегә юлыгуны сөяр», – дип әйтте. Шулай ук Расүлуллаһ галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Дөреслектә фәҗир яисә кяфер үлемгә әзерләнсә, ягъни аның үлем вакыты җитсә, кяфергә яки фәҗиргә куркытучы шул нәрсә белән килер, ул нәрсә аңа явызлыктан ирешүчедер. Ул кяфер яисә фәҗир Аллаһыга юлыгуны мәкруһ күрер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Мөхәммәд бине Фазылдан, ул үзенең иснәде белән Габдулладан, ул Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять итә. Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Бәни Исраилдән сөйләделәр, мәшәкать юк, тәхкыйк, ул кавемдә гаҗәп нәрсәләр булды». Моннан соң үзе сөйли башлады һәм: «Бәни Исраилдән бер төркем чыкты, бер каберлеккә килделәр һәм: «Әгәр без намаз укысак, соңыннан үлек кешеләрнең кайберләре безгә чыкканга кадәр Аллаһыбызга дога кылсак, ул безгә үлем турында хәбәр бирер», – дип әйттеләр. Алар намаз укыдылар Һәм Раббыларына дога кылдылар. Болар мондый хәлдә булганда, бер ирнең башы кара кабердән ак белән кара арасында чыкты һәм болай дип әйтте: «Әй кешеләр, ни телисез? Аллаһы Тәгалә белән ант итеп әйтәмен, туксан елдан бирле мин мәет булып килдем, миннән үлем ачысы китмәде, хәтта мин хәзерге вакытта да шул хәлдәмен. Мине үз халәтемә кайтаруны сорап, Аллаһы Тәгаләгә дога кылыгыз». Ул кешенең ике күзе арасында сәҗдә әсәре бар иде».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Мөхәммәд бине Фазылдан, ул үзенең иснәде белән Пәйгамбәребездән риваять итә. Ул: «Үлем катылыгының микъдары, янә мөэмин өчен үлемнең кайгысы кылыч белән өч йөз сугу кадәрдер», – дип әйткән.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бер кеше үлемне анык һәм хакыйкатьтә үлем аңа һичшиксез иңәчәк икәнен белсә, аңа үлем өчен изге гамәлләр кылу һәм яман эшләрдән саклану белән әзерләнүдән чара юк, чөнки ул кеше кайчан үлем ирешәчәген белми. Тәхкыйк, Расүлебез галәйһиссәлам үзенең өммәтенә үгет йөзеннән, үлемгә әзерләнсеннәр һәм дөньяның катылыкларына түзсеннәр өчен үлемнең катылыгын һәм ачылыгын бәян кылды. Дөреслектә, дөньяның катылыкларына түзү үлем катысыннан җиңелрәктер, Ахирәт газабы дөнья газабыннан катырактыр».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үлем өчен әзерләнүне бәян кылды: «Хакыйкатьтә үлемгә әзерләнү гыйлемнең башыннандыр, үлемгә әзерләнү белән мәшгуль булу – беренчедер».

Габдулла бине Әл-Мөсәүвир Әл-Һәшими риваять итте. Габдулла радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу аятьне укыды: «Аллаһы Тәгалә бер кешене туры юлга күндерүне теләсә, ул кешенең күкрәген Ислам өчен ачар. Бер кешене аздырырга теләсә, аның күкрәген тар һәм мәшәкатьле кылыр». Моннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр күңелгә Ислам нуры керсә, күңеле киң булып ачылыр». Аннан: «Моның өчен галәмәт булырмы?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез: «Алдау йортыннан ерак булу һәм мәңге кала торган йортка ышану, үлем ирешкәнгә кадәр үлемгә әзерләнү», – дип әйтте.

Җәгъфәр бине Бәрканнан, ул Мәймүн бине Мәһраннан риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез бер ирне вәгазьләп, болай дип әйтте: «Биш нәрсәдән әүвәл биш нәрсәне: картаймастан әүвәл яшьлегеңне, авырганнан әүвәл сәламәтлегеңне, шөгылеңнән әүвәл буш вакытыңны, фәкыйрьлегеңнән әүвәл байлыгыңны, үлемнән әүвәл тереклегеңне ганимәт дип бел». Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу биш нәрсәдә күп гыйлемне җыйды, чөнки ир картайган хәлдә кодрәтле булмаган нәрсәгә егет булганда кодрәтлерәк була. Яшь кеше гөнаһ кылуга гадәтләнсә, кар-

тайганнан соң ул гөнаһтан тыелырга көче җитмәс. Егет кеше картлык көнендә үзенә җиңел булсын өчен яшь вакытында изгелекләрне кылырга гадәтләнергә тиеш. «Авырудан әүвәл сәламәтлегеңне», дигән сүз шуның өчендер, сау кешегә үзе һәм малы белән эшне үтәү тиешле була. Сәламәтлекне ганимәт дип белү, изге гамәлләрдә үзенең малы һәм тәне белән тырышу, чөнки ул кеше авырса, аның тәне тәгатьтән зәгыйфьләнә, малыннан кулы кыскара, мәгәр өчтән бер өлешендә генә. «Шөгылеңнән әүвәл буш вакытыңны», дигән сүзнең мәгънәсе, ягъни кичен буш, көндезен шөгыльле бул. Кичләрен намаз укырга, көндезен шөгыль вакытында ураза тотарга тиеш була, бигрәк тә кыш көннәрендә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Кыш мөэминнең ганимәтедер. Кышның кичендә торса, ул озын булды. Көндезен ураза тотса, аның көндезе кыска булды».

Икенче риваятьтә килә: «Кич озындыр, син ул озын кичне йокың белән кыскартма. Көндез яктыдыр, син үзеңнең гөнаһларың белән аны каралтма, ягъни төсен бозма».

«Фәкыйрьлегеңнән әүвәл байлыгыңны ганимәт дип бел», дигән сүзнең мәгънәсе шул, әгәр син Аллаһы Тәгалә азыктан биргән нәрсәгә разый булсаң, моны ганимәт дип бел, кешеләрнең кулында булган нәрсәне теләмә.

«Үлемнән әүвәл тереклекнең», дигән сүзенең мәгънәсе шул, кеше исән вакытта гамәл кылуга кодрәтле була, әгәр үлсә, гамәле киселер. Мөэмингә фани көннәрне бушка үткәрмәү һәм мәңгелек Ахирәт көннәрен ганимәт дип белү тиеш булыр.

Хаким әйтте: «Сабый булсаң, сабыйлар белән уйнарсың. Егет булсаң, уен-көлке белән гафил булырсың. Карт булсаң, зәгыйфьләнерсең». Кайчан Аллаһыга гамәл кылырсың, ягъни үлгәннән соң Аллаһыга гыйбадәт кылырга көчең җитмәс, бәлки исән вакытыңда гына тырышырга көчең

җитәр. Үлем фәрештәсе килгән вакытка әзерләнерсең, һәр вакытта үлемне искә төшерерсең, чөнки ул үлем фәрештәсе синнән гафил булмас».

Гали радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер ансар кешесенең баш турысында үлем фәрештәсен күреп, «минем иптәшемә йомшак бул, дөреслектә ул кеше мөэминдер», – дип әйтте. Фәрештә болай дип җавап бирде: «Әй Мөхәммәд, сөенеч бир, дөреслектә, мин һәр мөэмингә йомшаклык кылучымын. Әй Мөхәммәд, Аллаһы белән ант итеп әйтәм, дөреслектә, мин адәм баласының җанын алам. Шулвакытта ул адәм баласының әһеленнән бер кычкыручы кычкырыр, моны кычкыручы дип әйтермен. Валлаһи, ул кешегә золым китермәм, ул кешенең әҗәлен элек кылмадык, аның тәкъдирен ашыктырмадык. Безгә аны алуда гөнаһтан ни булыр? Аллаһы Тәгалә эшләгән нәрсәгә разый булсагыз әҗерле булырсыз, кайгырсагыз яки сабырсызлык кылсагыз, гөнаһлы булырсыз. Безнең каршыда, сезнең өчен шелтәдән башка, һичнәрсә юк. Дөреслектә, безнең өчен сезнең хозурыгызга аңсызлык һәм кайтмау булучыдыр. Йорт әһелләреннән йон яки тузан пәрасе кырда, кирәк диңгездә булса һич нәрсә юк, камил саклану белән сакланыгыз, мәгәр мин һәр кич һәм көндезен биш мәртәбә аларның йөзләренә сугармын, хәтта мин аларның үзләрен кечкенәләрен һәм олугларын беләм. Әй Мөхәммәд! Аллаһы белән ант итеп әйтәм, әгәр мин чебен җанын алырга теләсәм, Аллаһы Тәгалә ул рухны алу белән Үзе боеручы булганга, минем моңа көчем җитмәс».

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән Әбү Сәгыйд Әл-Хөдри радыяллаһу ганһе риваять итә. Пәйгамбәребез көлүче кешеләрне күреп, болай дип әйтте: «Әгәр үлемнән зикерне күп кылсагыз, мин күргән нәрсәдән шөгыльләнүегез өчен сезгә ни булыр?» Аннан соң: «Ләззәтләрне сындыручы зикерне, ягъни үлемне күп искә алыгыз», – диде. Шулай ук: «Дөреслектә кабер – ул җәннәт бакчаларыннан бер бакча яки ут чокырларыннан бер чокырдыр», – дип әйтте.

Хәтим Әл-Гасыйм болай дип әйткән: «Дүрт нәрсәнен кадерен мәгәр дүрт кеше генә белер: егетлек яшьлек кадерен белмәс, мәгәр картлар гына белер. Кайгысызлык кадерен мәгәр башына бәла-каза төшкән кешеләр генә белер. Саулык кадерен мәгәр авырулар гына белер. Тереклек кадерен мәгәр үлекләр генә белер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бу хаким зикер иткән нәрсә без зикер иткән хәбәргә муафыйк. Ул хәбәр «биш нәрсәне биштән элек ганимәт дип бел» дигән сүз».

Шәкыйкъ бине Ибраһим болай дип әйткән: «Кешеләр миңа сүз белән дүрт нәрсәдә муафыйк кылдылар һәм дүрт нәрсәдә гамәл белән каршы килделәр. Беренчесе, ул кешеләр: «Без Аллаһы Тәгаләнең коллары», – дип әйттеләр, ә үзләре азат кешеләрнең гамәлләрен кылалар. Икенчесе, алар: «Безнең ризыкларыбызга Аллаһы Тәгалә Кәфил (ышаныч Бирүче)», – диделәр. Аларның күңелләре мәгәр дөньяда булган әйбер белән генә тынычлык таба. Өченчесе, алар: «Дөреслектә, Ахирәт дөньядан изгерәк», – диделәр, әмма үзләре малны дөнья өчен җыялар». Дүртенчесе, алар: «Үлемнән безгә чара юк», – диделәр, үзләре исә, үлмибез, дигән кавемнең гамәлләрен кылалар».

Дөреслектә Гайсә галәйһиссәламнән зикер ителә. Ул Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән үлекләрне тергезә торган булды. Ышанмаучы кешеләрнең кайберәүләре аңа: «Хакыйкатьтә син тергезәсең, тәхкыйк үлеме яңа килгән кешене тергездең, бәлки ул үлек булмагандыр. Безгә күптән үлгән кешене тергез», – дип әйттеләр. Гайсә галәйһиссәлам аларга: «Теләгән кешегезне сайлагыз», – дип әйтте. Алар: «Безгә Сәм бине Нухны тергез», – диделәр. Гайсә галәйһиссәлам Сәм бине Нухның каберенә килеп, ике рәкәгать намаз укыды, Аллаһы Тәгаләгә дога кылды. Аллаһы Тәгалә Сәм бине Нухны тергезде, шулвакыт ул Сәмнең башы һәм сакалы агарган иде. Аннан: «Бу ни? Синең заманыңда картлык юк иде», – дип сорадылар. Сәм болай дип әйтте: «Тавыш ишеткәннән соң Кыямәт килде

дип уйладым. Дөреслектә, куркудан чәчем һәм сакалым агарды». Аннан: «Синең үлгәнеңә күпме вакыт узды?» – дип сорадылар. Сәм: «Үлгәнемә дүрт мең ел, әмма үлем исереклегенең миннән әле дә киткәне юк», – дип җавап бирде.

Үлем хакында Коръәни Кәримдә бик еш искә алына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

قُل لَّن يَنفَعَكُمُ الْفِرَارُ إِن فَرَرْتُم مِّنَ الْمَوْتِ أَوِ الْقَتْلِ وَإِذًا لَّا تُمَتَّعُونَ إِلَّا قَلِيلًا ﴿١٦﴾

**«(Расүлем!) Әйт: “Әгәр үлемнән яки үтерелүдән качсагыз, (әҗәлегез җиткән булса) бу качу сезгә файда китермәячәк. (Әмма әҗәлегез җитмәгән булса) Ул вакытта (әҗәлегезгә кадәр) бик аз (гына дөнья тормышыннан) файдаланырсыз”.**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:16

Ягъни һәр мөселманга үлемнең иңүеннән әүвәл аңа әзерләнү вәҗибтер.

قُلْ إِن كَانَتْ لَكُمُ الدَّارُ الْآخِرَةُ عِندَ اللَّهِ خَالِصَةً مِّن دُونِ النَّاسِ فَتَمَنَّوُا الْمَوْتَ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴿٩٤﴾

**«(Расүлем! Әйт: “(И яһүдиләр!) Әгәр Аллаһы хозурындагы Ахирәт йорты (җәннәт) башка кешеләр өчен түгел, фәкать сезнең өчен генә икән, (бу сүзегезгә) тугры булсагыз, үлем теләгез (чөнки җәннәт әһеленнән булачагын төгәл белгән кеше тизрәк үлеп, анда керергә теләмәсмени)”.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:94

Янә Аллаһы Тәгалә бәян итте:

«Дөреслектә, садыйк кеше үлемне тели. Алдаучы кеше исә гамәлләренең явызлыгы сәбәпле үлемнән качар, чөнки садыйк мөэмин, тәхкыйк, үлем өчен әзерләнде. Ул кеше үлемне зәвыкланып, Аллаһы Тәгаләгә баруны теләр».

Әбү Дәрдә риваять иткәнчә: «Раббыма итагать өчен ярлылыкны яратамын. Гөнаһларыма кәффарәт булсын өчен авыруны яратамын, Раббыма баруны теләгән өчен үлемне яратам».

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Изге яисә яман нәфестән һич нәрсә булмас, мәгәр булды исә, үлем – ул нәфес өчен изгедер. Әгәр ул нәфес изге булса, тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

لَـٰكِنِ الَّذِينَ اتَّقَوْا رَبَّهُمْ لَهُمْ جَنَّاتٌ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا نُزُلًا مِّنْ عِندِ اللَّهِ ۗ وَمَا عِندَ اللَّهِ خَيْرٌ لِّلْأَبْرَارِ ﴿١٩٨﴾

**«Ләкин Раббыларыннан курыккан кешеләр өчен, Аллаһыдан сый-хөрмәт буларак, (сарайлары һәм агачлары) асларыннан елгалар агып торган җәннәтләр бар. Алар анда мәңге калачак. Аллаһы хозурында булганнар (чиксез-хисапсыз бүләкләр) исә (иман китереп, яхшылык кылган) игелекле коллар өчен яхшырак».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:198

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үлем мөэминнең рәхәтедер».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Расүлебездән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребездән: «Кайсы мөэминнәр артыграк?» – дип соралды. Ул: «Холык йөзеннән иң күркәме», – дип җавап бирде. Аннары кабат:«Кайсы мөэминнәрнең янчыклар тулырак?» – дигән сорау бирелде.

Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Үлемне күп зикер итүчесе һәм ул үлем өчен әзерләнү йөзеннән аларның күркәмрәге», – дип әйтте.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Зирәк кеше үзен таныган һәм үлемнән соң булган нәрсәгә гамәл кылган кешедер. Фәҗир (гөнаһлы) кеше – ул нәфесенә һәм нәфес теләкләренә иярер, Аллаһы Тәгаләдән котылуны, ягъни ярлыкауны теләр».

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

# Олы гөнаһлар

## Хәмер куллану

يَسْأَلُونَكَ عَنِ الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ ۖ قُلْ فِيهِمَا إِثْمٌ كَبِيرٌ وَمَنَافِعُ لِلنَّاسِ وَإِثْمُهُمَا أَكْبَرُ مِن نَّفْعِهِمَا ۗ وَيَسْأَلُونَكَ مَاذَا يُنفِقُونَ قُلِ الْعَفْوَ ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ لَعَلَّكُمْ تَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١٩﴾

**«(Расүлем!) Синнән хәмер (һәм акылны томалый торган башка нәрсәләр) һәм отышлы уеннар (кебек малга зарар китерә торган нәрсәләр) турында (Аллаһы Тәгаләнең хөкемен) сорыйлар. Әйт: «Аларның икесендә дә (сүз көрәштерү, бозыклык һәм ялган кебек афәтләр, зиһенне чуалту кебек зарарлар булганлыктан, куллануда) зур гөнаһ, әмма (икесендә дә) кешеләр өчен (кәеф һәм рәхәтлек, кыюландыру һәм җиңел акча эшләү кебек аз гына) файда да бар[1]. Әмма һәр икесендә дә гөнаһ файдаларына караганда (бермә-бер) күбрәк». Янә (байлар) синнән (моңа кадәр малдан кемгә сарыф итәргә кирәклеген сораганнар иде, бу юлы) нәрсәне сарыф итәргә кирәклеген сорыйлар. Әйт: «(Ихтыяҗдан) Артыкны (бирегез һәм үзегезне мохтаҗ**

[1] Җаһилият дәверендә гарәпләр исерткеч эчемлекләр эчәргә һәм отышлы уеннар уйнарга яраталар. Мөселманнарга Ислам дине кануннары буенча яшәргә бер киртә булганлыктан, боларның кинәт берьюлы харам кылынуы белән, бу начар гадәтләрнең акрынлап кына тыелуына өстенлек бирелә. Шулай итеп, иң элек «Нәхел» сүрәсенең 67 нче аяте кәримәсендә «хөрмә һәм йөзем җимешләреннән исертә торган эчемлек» гыйбарәсе «яхшы ризык» сүзеннән алда килеп, хәмернең Аллаһы тарафыннан хуп күрелмәгәненә ишарә ясала. Соңрак, хәзер тәфсир кылына торган аяте кәримә иңдерелеп, күпмедер әһәмиятсез һәм үтеп китә торган файдаларына караганда, зарарының күбрәк булганы ачыктан-ачык белдерелә. Тагын бераздан, «Нисә» сүрәсенең 43 нче аяте кәримәсенең иңүе белән, исерек чакта намазга якын килү тыела, шул рәвешчә, биш вакыт намаз йөкләнгән мөэминнәр тормышыннан исерткеч шактый ераклаштырыла. Соңгы адым булып «Мәидә» сүрәсенең 90 нчы һәм 91 нче аяте кәримәләре иңү белән исерткеч һәм отышлы уеннарның шәйтан эшләреннән булганы белдерелеп, бу мәсьәләгә нокта куела.

**хәлгә төшермәгез)!» Аллаһы (сорауларыгызга җавап булган) аятьләрен сезгә шулай бәян итә, – бәлки, сез (дәлилләрне һәм хөкемнәрне) фикерләп карарсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:219

**«И, иман китерүчеләр! Хәмер, отышлы уен, (табыну өчен) тораташлар һәм фал уклары – шәйтан гамәлләреннән булган шакшылык. Болардан ерак торыгыз, бәлки, сез (Аллаһының газабыннан котылып) уңышка ирешерсез. Шәйтан хәмер (һәм исерткеч эчемлекләр) һәм отышлы уен белән арагызга дошманлык һәм нәфрәт салырга, сезне Аллаһыны искә алудан һәм намаздан тайпылдырырга тели. Сез (болардан) ваз кичмисезме әллә?»**[1]

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: «Исерткеч эчемлекләрне тыя торган аять иңгәннән соң кайбер сәхабәләр башкаларга: «Моннан соң хәмер куллану ширеккә тиң булачак», – дип әйттеләр.

Габдулла бине Гомәр хәмер куллануны иң олы гөнаһ дип санаган. Чыннан да, исерткеч эчемлек – бөтен яманлыкларның да башлангычы. Моннан тыш, Аллаһы Тәгалә эчкечене ләгънәт кылган.

Габдулла бине Гамр Расүлебез галәйһиссәламнең мондый хәдисен тапшырган. Ул: «Әгәр кем дә булса исерек хәлендә булып, намазын калдырса, бу – аннан, бөтен булган нигъмәтләре белән бергә, җир йөзен тартып алган кебек булыр. Ә исереклеге аркасында дүрт намазны калдырган

---

[1] Гомәр бине Шурахбил радыяллаһу ганһе болай дип белдерә: Гомәр бине Хәттаб радыяллаһу ганһе: «И Аллаһы! Безгә исерткеч хакында ачык хөкемеңне белдер,» – дип әйткәч, «Бәкара» сүрәсендәге «Синнән хәмер һәм отышлы уеннар турында сорыйлар» аяте кәримәсе иңә. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһене чакыртып, бу аяте кәримәне укыгач, ул шул ук догасын янә кабатлый. Шуннан «Нисә» сүрәсендәге «И иман китерүчеләр! Исерек чакта намазга якын килмәгез!» аяте кәримәсе иңә. Бу аяте кәримә иңгәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөәзине камәт төшергәндә: «Исерекләр намазга якын килмәсен!» – дип әйтә торган була. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе бу аяте кәримәне укыгач, моның белән генә дә канәгатьләнмичә, кабат шул ук догасын кыла. Бу юлы «Мәидә» сүрәсенең шушы аятьләре иңгәч, ул: «Ваз кичтек, ваз кичтек!» – дип, канәгать булуын белдерә (Тирмизи, Тәфсир 6 №3049 5/253).

кешегә Аллаһының «Тинетүль-Хәбәл» эчемлеген эчерергә хакы бар», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Йә, Аллаһының Илчесе! «Тинетүль-Хәбәл» нәрсә ул?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – җәһәннәм әһелләренең үлекләре һәм каннары», – дип җавап биргән[1].

Җәбир радыяллаһу ганһе Расүлебез галәйһиссәламнең әлеге сүзләрен тапшырган:

«Аллаһының эчкече кешегә «Тинетүль-Хәбәл» эчемлеген эчерергә хакы бар». Сәхабәләр: «Тинетүль-Хәбәл» нәрсә ул?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – җәһәннәм әһелләренең тирләре», – дип җавап биргән[2].

«Кем бу дөньяда шәраб эчсә, ул кеше Ахирәттә аннан мәхрүм калыр»[3].

«Кем бертуктаусыз хәмер эчеп, шул халәтендә үлсә, Аллаһы Тәгалә каршына күп илаһларга табынучы буларак килеп басар»[4] [5].

## Тәкәбберлек, масаючанлык

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйткән:

فَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ أَنِ اصْنَعِ الْفُلْكَ بِأَعْيُنِنَا وَوَحْيِنَا فَإِذَا جَاءَ أَمْرُنَا وَفَارَ التَّنُّورُ ۙ
فَاسْلُكْ فِيهَا مِن كُلٍّ زَوْجَيْنِ اثْنَيْنِ وَأَهْلَكَ إِلَّا مَن سَبَقَ عَلَيْهِ الْقَوْلُ مِنْهُمْ
ۖ وَلَا تُخَاطِبْنِي فِي الَّذِينَ ظَلَمُوا ۖ إِنَّهُم مُّغْرَقُونَ ﴿٢٧﴾

---

1 Имам Әхмәд бине Хәнбәл, Мөснәд, 2/178, 189.

2 Китаб Әл-Әшрибә, 2002.

3 Әл-Бохари, Китаб Әл-Әшрибә, 5775; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшрибә, 2003.

4 Әхмәд бине Хәнбәл, Мөснәд, 1/272.

5 Тәрҗемәченең искәрмәсе: һәрбер исертә торган һәм наркотик (әфьюн) матдәләр – харам. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрбер исерткеч – шәраб һәм һәрбер исерткеч – харам», – дип әйткән (Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшрибә, 2003). «Әлеге хәдис кайсы гына төргә караса да, ул исерткеч эчемлекләрнең, күпме күләмдә булуына карамастан, харам булганлыгына дәлил булып тора» (А. Даудголу, Сахих Әл-Мөслим Тәрҗемәви Шәрхе, 9/924).

**«Без аңа: «Безнең күзәтүебез белән көймә яса. (Көймәгә утыру) Әмеребез килгәч һәм (Хәвва радыяллаһу ганһәдән) калган таш) мич (су ургылып һәм бик көчле итеп) кайнап чыккач, (суга батудан котылачак кешеләрнең һәрбереннән (анасы һәм атасы итеп) берәр пар һәм (мөселман булган хатының белән өч улыңның һәм аларның хатыннарыннан торган) гаиләңне аңа керт. Әмма (кяфер булган хатының, улың кебек) алар арасыннан (батып үләселәре турындагы) сүзем алдан әйтелгәннәрне түгел. Золым кылучылар хакында (догалар кылып) Миннән сорама. Һичшиксез, алар суга батырылачак».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:27

لَا جَرَمَ أَنَّ اللَّهَ يَعْلَمُ مَا يُسِرُّونَ وَمَا يُعْلِنُونَ ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْتَكْبِرِينَ ﴿٢٣﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы аларның ачык эшләгәннәрен дә, яшерен эшләгәннәрен дә белә. (Шуңа күрә аларга лаек булган җәзаларын бирәчәк). Һичшиксез, Ул тәкәбберләнүчеләрне сөйми».**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:23

أَيَحْسَبُونَ أَنَّمَا نُمِدُّهُم بِهِ مِن مَّالٍ وَبَنِينَ ﴿٥٥﴾ نُسَارِعُ لَهُمْ فِي الْخَيْرَاتِ ۚ بَل لَّا يَشْعُرُونَ ﴿٥٦﴾

**«Әллә (инкяр итүчеләр) Мин мал һәм ир балалар бирәм дип уйлыйлармы? Без аларны игелек белән нигъмәтләндерергә ашыгабыз (дип)? Юк шул! Белмиләр!»**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:55-56

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер кеше үз-үзенә масаеп, кигән киеме белән мактанып бара икән. Аллаһы Тәгалә җиргә аны йотарга әмер биргән һәм аның җиргә йотылуы Кыяматкәчә дәвам итәчәк»[1].

«Аллаһы Тәгалә залим һәм тәкәббер кешене Кыямәт көнендә вак кырмыскалар итеп кубарыр. Һәм аларны кешеләр таптап үтәрләр.»

Элеккеге буын кешеләренең кайберләре тәкәбберлек – ул Аллаһы Тәгаләгә белдерелгән беренче «баш күтәрү», дип әйткәннәр.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

وَإِذْ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا إِلَّا إِبْلِيسَ أَبَىٰ وَاسْتَكْبَرَ وَكَانَ مِنَ الْكَافِرِينَ ﴿٣٤﴾

**«Без фәрештәләргә (һәм җеннәргә): «(Шәрәфен икърар итүегезне күрсәтү һәм аны сәламләү өчен) Адәмгә (кыйбла буларак юнәлеп) сәҗдә кылыгыз!» – дип әйткәч, алар (һәммәсе) сәҗдә кылдылар, бары Иблис (киреләнде, сәҗдәдән) баш тартты, тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:34

Иблис кебек тәкәбберләнүченең иманыннан бернинди дә файда булмас.

Расүлебез галәйһиссәлам: «Тәкәбберлек – ул хакыйкатьне кабул итмәү һәм кешеләргә масаеп, өстән карау»[2], – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

---

[1] Әл-Бохари, Китаб Әл-Либас, 5790; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Либас, 2088; Эн-Нәсаи, Китаб-Уз-Зина, 8/206.

[2] Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман, 91.

وَلَا تُصَعِّرْ خَدَّكَ لِلنَّاسِ وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ كُلَّ مُخْتَالٍ فَخُورٍ

**«(Тәкәбберләр кылган кебек) Йөзеңне кешеләрдән чөермә, җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, Аллаһы һәр масаеп йөргән, үзен яратучы кешене сөйми (һәм аларның бу кыланышларыннан разый булмый)».**

«Локман», 31:18

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең мондый сүзләр әйткәнлеген бәян итә: «Бөеклек – Минем киемем. Кодрәт – Минем япмам. Минем белән ярышырга теләүчене утка ташлаячакмын»[1].

Икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Берьюлы җәннәт белән җәһәннәм үзара бәхәсләшә башлаган. Җәһәннәм: «Йә, Раббым! Ни өчен миңа көчсезләр һәм зәгыйфьләр генә керә?» – дигән. Җәһәннәм: «Мин тәкәббер һәм гаделсез кешеләрнең урынына әверелдем», – дип белдергән»[2].

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

تِلْكَ الدَّارُ الْآخِرَةُ نَجْعَلُهَا لِلَّذِينَ لَا يُرِيدُونَ عُلُوًّا فِي الْأَرْضِ وَلَا فَسَادًا ۚ وَالْعَاقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ ﴿٨٣﴾

**«Ул – (сиңа макталган) соңгы йорт. Без аны җирдә тәкәбберләнмәгән һәм бозыклык теләмәгәннәрнеке итәчәкбез. Ул (күркәм) нәтиҗә (әмерләрен тотып, тыюларыннан тыелып, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан сакланган) тәкъвалык ияләренеке (булачак)».**

---

1 Әл-Мөслим, Китаб Әл-Бирр Вәсилә; Әбү Давыд, Китаб Әл-Либас, 4090.

2 Әл-Бохари, Китаб Әл-Тәфсир, 4850; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Җәнаһ, 2846; Тирмизи, Китаб Әс-Сыйфатил Җәннәт, 2564.

«Касас / Хикәя», 28:83

Сәләмә бине Әл-Әквагъ болай дип сөйләгән:

«Берьюлы Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янында утыручы кеше сул кулы белән ашаган. Пәйгамбәребез аңа: «Уң кулың белән аша», – дип әйткән. Әлеге кеше: «Булдыра алмыйм», – дип җавап биргән». Аллаһы Илчесе: «Ничек инде булдыра алмыйсың? Бары тәкәбберлек кенә аны мондый итә алды», – дип әйткән.

Һәм аның кулы башка күтәрелмәгән»[1].

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам:

«Җәһәннәм әһелләре турында беләсегез киләме? Алар – рәхимсез дошман, саран һәм тәкәбберләнүче»[2], – дип әйткән.

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең мондый сүзләрен риваять итә: «Аллаһы Тәгалә тәкәбберләнеп, үз-үзе белән масаеп йөрүче кешене ачулы халәттә каршы алачак».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән:

«Тәмугка әлеге өч төркем кеше эләгәчәк: үзенең халкына зыян китерүче хаким, мал-мөлкәткә ия булып, аның белән тиешенчә эш итмәүче кеше, тәкәббер ярлы»[3].

Минемчә, тәкәбберлекнең иң югары дәрәҗәсе: гыйлемнәрең белән тәкәбберләнү һәм үзеңнең өстенлекләрең аркасында башкаларга карата тәкәббер мөнәсәбәттә булу. Андый кешегә булган гыйлемнәре бернинди дә файда китермәячәк. Ахирәт тормышы өчен туплаган гыйлемнәр кешене тыйнак итәр, йөрәген, нәфесен тынычландырыр һәм басынкы итәр, беркайчан да аны игътибарсыз калдырмас, бәлки, киресенчә, һәрдаим аны шелтәләп, дөресләп торыр. Әгәр ул моннан мәхрүм калса, юлыннан

1 Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшриба, 2021.

2 Әл-Бохари, 4918; Әл-Мөслим, Китабу Китаб Әс-Сыйфатил Җәннәт, 2853.

3 Хәким, Мүстәдрәк, 1/160.

язар һәм һәлак булыр. Тәкәбберлекнең иң югары дәрәҗәсе: гыйлемне алган вакытта аны башка мөселманнарга тапшырганда тәкәбберлек күрсәтүне, аларның абруйларын киметүне максат итеп кую. Бу очракта әлеге хәдисне кагыйдә буларак китерү мөһим: «Күңелендә тамчы кадәр генә тәкәбберлек булса да, ул кеше җәннәткә кермәячәк»[1]. Вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләһ.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

1 Әбү Давыд, Китаб Әл-Әкзийә, 3599.

# Бәхетеңә киртә корма

Кеше бәхетсезлегенең төп сәбәпчесе – аның бәхетле булырга теләмәве. Кызык яңгырый һәм аңлашылмый, билгеле. Әмма бу сүзләрнең мәгънәсе бар. Бу сүзләргә дин ягыннан игътибар бирсәк, аның нинди фикерләргә таянганын аңларбыз.

Еш кына кеше үз бәхетенә үзе каршы чыга, үзенең нинди бәхетле икәнен аңларга, танырга теләми. Бәхет төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый. Берәүләр өчен ул, байлык, икенчеләр өчен дәрәҗә, өченчеләр өчен матурлык, уңышка ирешү, танылган булу һ.б. Мондагы исемлекне тагы да тулыландырып була, әмма мин берсен генә мисал итеп китереп үтәм.

Әйе, бик күп кеше бәхетне материаль яктан җитеш тормышта яшәүдә күрә. Әмма бәхет – ул тотып карый торган материаль әйбер түгел. Кеше, тормышының билгеле бер этабында, материаль яктан авырлыкларда яшәсә дә, үзен бәхетле тоярга һәм җитеш тормышта яшәгән вакытта да күңеленә тынычлык, рәхәтлек тапмыйча яшәргә мөмкин. Күпләр тормышның мондый очракларында калганы бар. Килешәсезме, чыннан да, кеше бөтенләй дә бәхетле булырга «тиеш булмаган» вакытта бик бәхетле гомер кичерергә мөмкин һәм киресенчә.

Димәк, бәхет күпкә зуррак, мәгънәлерәк төшенчә. Бәхет – ул халәт, ул кешенең эчке дөньясыннан риза булып, канәгать йөрүе.

Шуңа да кайбер кеше бәхетне саулык-сәламәтлектә, күңел тынычлыгында, үзе яшәгән җирлектә иминлек-тынычлык хакимлек итүендә, өсте бөтен, тамагы тук булуда күрә. Менә шушы төшенчәләр бәхет хакындагы билгеләмәгә якынрак та инде. Тик монда да үз нечкәлекләре бар.

Динебез Исламда һәрбер сорауга җавап әзер.

Әгәр уйлансак, кеше тормышын, аның күзаллауларын, бу дөньяга карашын тәртипкә китерер өчен берничә аятьне һәм хәдисне үзеңә ши-

гар (девиз) итеп алу җитә. Тик бу, укыдым да – оныттым булырга тиеш түгел. Шуларның берничәсен карап үтик:

**1.**

إِنَّ اللَّهَ هُوَ الرَّزَّاقُ ذُو الْقُوَّةِ الْمَتِينُ ﴿٥٨﴾

**«Шиксез, Ул – Аллаһы барча мәхлүкатны ризыкландыручы вә бик олуг куәт Ияседер».**

«Зарият / Таратучы», 51:58

Кеше тормышында югарыга менү чорлары да, түбәнгә тәгәрәү вакытлары да була. Көчле рухлы мөэмин-мөселман һәрвакыт авырлыкларның вакытлыча гына булганын һәм Аллаһыдан сынау икәнлеген аңлый, сабырсызлык, ашыгучанлык күрсәтми. Хәтта Җир йөзендәге барлык кеше аңа каршы булган очракта да, Аллаһының рәхмәте булса, Ул колын ташламаячак, ризыксыз калдырмаячак.

**2.**

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ۚ ﴿٢٨٦﴾

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Тормышының иң авыр вакыты дип уйлап, төшенкелеккә бирелгән кеше Коръәндәге әлеге аятьне исенә төшерә. Әгәр дә сиңа берәр авырлык килде икән, бел: Аллаһы адәм баласына күтәрә алмаслык сынау бирми. Сорау бер: ул сынау аңа нәрсә өчен бирелде һәм аны лаеклы рәвештә үтәр өчен нишләргә?

**3.**

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾

**«Һичшиксез, (чиккән һәр) авырлыктан соң җиңеллек бар».**

«Инширах / Ачмак», 94:5

Булган борчу-мәшәкатьләреңнең очы-кырые күренмәгәндә, бу аятьне исеңә төшер. Һәр авырлыктан соң җиңеллек килә, яңгырдан соң салават күпере чыга.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләре кешенең бәхеткә, гомумән тормышка карата булган карашын уңай якка үзгәртә, уй-фикерләрен тәртипкә китерә.

Кайбер хәдисләрне карап үтик:

1. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия кеше кебек булыр», – дигән.

Гадәттә, адәм баласы иртә белән күзен ачу белән үк, көн дәвамында хәл итәсе проблемаларын, борчу-мәшәкатьләрен исенә төшерә. Еш кына әллә нәрсәләр уйлап, үзенчә фаразлап, үзен җир йөзендәге иң күп авырлыклары булган кеше итеп фикер йөртә башлый. Бер мизгелгә генә туктальйк әле. Без сау-сәламәт көе, иминлектә йокыдан уяндык. Ә йокыдан уяна алганбыз икән, димәк, безгә Аллаһы Тәгалә тагын бер көн гомер биргән. Һәм аны ничек үткәрүебез безнең бары үзебездән генә тора. Йокыдан уяну-уянмавыбыз Аллаһыдан торса, көнебезнең ни рәвешле узачагы бары үзебезгә генә бәйле. Көн дәвамында юкка-барга зарланып йөрибезме, әллә Аллаһыга булганына шөкер итеп, яңа туган көннең ямен күрергә тырышабызмы?! Һәркем үзенчә хәл итәчәк, билгеле.

2. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Үзегездән югары булганнарга түгел, ә түбән булганнарга карагыз. Бу сезгә Аллаһы сезгә биргән нигъмәтләрне ким итеп күрмәскә булышыр», – дигән.

Еш кына адәм баласы шөкерсезлек күрсәтә. Инсан дигән сүз дә гарәпчәдән «нәсийә», ягъни онытучы, дип тәрҗемә ителә. Кеше Аллаһының биргән нигъмәтләренең кадерен белми, ә кадерен белеп, рәхәтен күреп яшәгәндә авырлыклар килсә, бәхетле чакларын бик тиз оныта. Бүген җитеш, мул халәттә яшәп, иртәгә берникадәр авырлыклар белән очрашса, зарлана башлый, үзен иң бәхетсез кеше дип саный. Ә бәлки кеше, тормышының бу вакытларында аннан да авыррак хәлдә калучылар барлыгын истә тотарга тиештер?! Ә бәлки бүген кеше ия булган, әмма кадерен белмәгән нигъмәтләр турында берәүләр көн-төн Аллаһыга дога кылып ялвара, шуның хакта хыялланып яшидер? Бүгенге заман кешесенә нәкъ менә болар хакында уйлану җитми дә инде.

3. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Байлык – мал күплеге түгел, хакыйкый байлык – күңел байлыгы», – дигән.

Кем соң ул күңеле бай булган кеше? Ул нинди сыйфатларга ия? Аның өстенлеге нидә? Күңеле бай кеше – ул күркәм холыкка ия булып, тәкәбберлек, саранлык, икейөзлеләнү һ.б. кебек начар гадәтләрдән ерак булган, һәрдаим шөкер кылып яшәүче. Андыйларны фани дөньяның юк-бар борчулары, берәүләрнең уңышлары хафага салмый. Алар башка кешеләрдәге бәхетне үзенеке кебек итеп кабул итә, әйләнә-тирәдәгеләр өчен куана, кирәк вакытта ярдәм итә белә. Башкалар ярдәмгә мохтаҗ булганда, моннан үзләренә файда көтмичә, ихластан булыша. Үзләре авырлыкка төшкәндә ярдәмне Аллаһыдан гына сорап, сабыр була, сабырсызлык күрсәтеп, бөтен дөньясын гаепли башламый. Бу кешеләр, чыннан да бәхетле, чөнки моңа һәркем ирешә алмый. Чынлыкта, бу бик зур сабырлык, тырышлык таләп итә. Бу пәйгамбәрләр, изге кешеләрнең халәте. Һәм әгәр Аллаһының рәхмәте белән син әлеге сыйфатларны үзеңдә табасың икән, син бик тә бәхетле булырга тиеш.

Югарыда бәхет төшенчәсенә кагылышлы бары тик берничә аять, хәдис кенә китерелде, ә алар бихисап. Тормышыбызны яхшы якка

үзгәртергә теләсәк, боларны белү дә җитәдер. Үз бәхетебезгә үзебез киртә кормыйча, уйлана, нәтиҗәләр чыгара һәм бәхетле булырга өйрәнсәк иде.

Бәхет төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый, дидек. Килешерсез. Әмма, ничек кенә аңлатырга тырышсак та, кеше күңеле тыныч булганда гына тулаем бәхетле була ала. Ә нәрсә соң ул күңел тыныч булу? Ул – җаныңның синең кылганнарыңнан канәгать булуы, чөнки җан – ул кешенең нигезе, асылы. Җаннар без бу дөньяга җибәрелгәнче ук Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылганнар. Аларга да ризык кирәк. Җанның ризыгы – үзен яратучыга табынып, аңа шөкер итеп, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәве. Тән тәфескә ияреп хаталар кылып яшәгәндә җан моңа риза булмый, ә җан риза булмаган очракта күңел тынычлык таба алмый. Ә бәхет – күңел тынычлыгында дидек. Боларны кабул итү-итмәү һәркемнең үз эше. Әмма нәрсә генә дисәк тә, барыбызның да бәхетле буласы килә.

*Айсылу Юлдашева*

# Коронавирус таралуга бәйле рәвештә, Нәзарәт үз тәкъдимнәрен җиткерә

بسم الله الرحمن الرحيم

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, коронавирус таралуга бәйле рәвештә, түбәндәге тәкъдимнәргә буйсынырга киңәш итә:

1. Вирус йоктыру ихтималы югары булган илләргә сәфәр кылудан тыелып торырга. Имам Әл-Бохари җыентыгында килгән хәдистә түбәндәгеләр әйтелә:

عن النبي صلى الله عليه و سلم أنه قال: إذا سمعتم بالطاعون في الأرض فلا تدخلوها و إذا وقع بأرض و أنتم بها فلا تخرجوا منه.

(صحيح البخاري/٥٧٢٨)

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән тапшырыла, ул болай дигән:

«Әгәр берәр җирдә ваба (чума) таралуы турында ишетсәгез – ул урынга бармагыз; әгәр ваба авыруы хәзерге вакытта сезнең җирлектә таралыш алса, яшәгән урыныгызны ташлап китмәгез» (5728).

Шулай итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм 1400 ел элек үк эпидемияләр таралганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә нигез салган.

2. Чисталыкка һәм гигиенага зур игътибар бирергә. «Сахих» Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис бар: Әбү Мәлик Әл-Әшгари радыяллаһу ганһе тапшырганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

الطهور شطر الإيمان

«Чисталык (гигиена) – иманның яртысы» (223).

3. Төчкергәндә һәм йөткергәндә гигиена кагыйдәләрен үтәргә. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә түбәндәгеләр әйтелә:

أن النبي صلى الله عليه و سلم كان إذا عطس غطى وجهه بيده أو بثوبه (سنن الترمذي/٢٧٤٥

«Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм төчкергәндә кулы яки тукыма кисәге белән авызын каплаган» (Имам Әт-Тирмизи/2745).

4. Даими рәвештә бүлмәне дезинфекцияләргә, чөнки вирус һава белән тарала. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

تبخروا في بيوتكم باللبان و المر و الصعتر (المطالب العالية/٢٤٤٨

«Өегезне ладан (любан), мирра (мурр) һәм тимьян (хуш ис килә торган үсемлек) белән төтәсләгез, ягъни яндырып исен чыгарыгыз» (Әл-Маталиб Әл-Алия/2448).

Барлык дезинфекция ясау чараларын куллану рөхсәт ителә.

5. Якыннарыбыз: әти-әниләребез (бигрәк тә алар өлкән яшьтә булса) һәм балалар өчен безгә йөкләнгән җаваплылык турында онытмаска.

Без туганнарыбызга, якын кардәшләребезгә профилактика чаралары турында сөйләргә тиешбез.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

كلكم راع و كلكم مسؤول عن رعيته

«Сезнең һәрберегез көтүче, һәм һәркайсыгыз үзенең көтүе өчен җаваплы» (Имам Әл-Бохари).

6. Аллаһы Тәгаләдән дөньяның барлык мөселманнары өчен гөнаһларның гафу ителүен һәм иминлек насыйп булуын сорап дога кылырга.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дигән:

إن الله لا يغيِّر ما بقوم حتى يغيروا ما بأنفسهم (الرعد/١١

**«Һичшиксез, алар (кешеләр) үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый»**

«Рәгыд / Күк күкрәү», 13:11

7. Әбү Давыд хәдисләр җыентыгында килгән хәдистән доганы еш укырга:

اللهم إني أعوذ بك من البرص و الجنون و الجذام و من سيئ الأسقام (١٥٥٤)

«Раббым, мин Синнән махау (проказа) авыруыннан, акылсызлыктан, лепра (хроник инфекцион авыру) чиреннән һәм начар авырулардан саклавыңны сорыйм» (1554).

8. Әгәр кеше хәлсезләкләнсә, кичекмәстән табибларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَا مِن قَبْلِكَ إِلَّا رِجَالًا نُّوحِي إِلَيْهِمْ ۚ فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ ﴿٤٣﴾

**«Без синнән алда да (кешеләргә пәйгамбәр итеп) ирләр җибәргән идек, шуларга вәхи иттек. Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләренән сорагыз»**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:43

Шулай ук, хәлсезлек хисен тойган кеше башка кешеләрне вирус йоктырудан сакланырга тиеш. Шуңа күрә авыру кешегә халык күпләп җыела торган урыннарга барудан тыелып торырга кирәк.

## Имамнар өчен тәкъдимнәр

1. Азан белән камәт арасындагы вакытны мөмкин кадәр кыскартырга.

2. Мөселманнар өчен мәҗбүри булган җомга хотбәсе һәм башка дини бәйрәм чаралары вакытын мөмкин булганча кыскартырга: болар – Ураза һәм Корбан гаетләре.

3. Мәхәллә кешеләренә эпидемия таралганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйләргә.

4. Намаздан соң кул биреп күрешүдән тыелып тору тәкъдим ителә.

Аллаһы Тәгалә безне шушы сынаудан сакласын һәм өммәтнең хәлен төзәтсен!

*Татарстан Республикасы мөселманнары*

*Диния нәзарәтенең фәтвалар бүлеге*